КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 11
29 сентябрь
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

БҮГЕНГЕ САНДА:

10 *Әхсән БАЯН.* Бер генә уйны да белдермәүче бихисап шигырьләр, шигырьлеккә дәгъва кылган тезмәләр газета һәм журнал битләрен тутыра, эстрададан рәхәтләнеп «кычкыра, бии, шамакайлана».

11 *Илдар НИЗАМОВ.* Ана телендә укыту барышын, сыйфатын, нәтиҗәләлеген бөтен җәмәгатьчелек, бөтен халык хәстәренә, күзәтүенә алырга бик вакыт.

13 *Николай МАКСИМОВ.* Татарстаннан, татар мәдәнияте үзәгеннән читтә яшәп тә, үз баласына ата-бабасы телен, гореф-гадәт-йоласын өйрәтергә омтылган милләттәшләргә башка милләт вәкилләренең күбесе сокланып та, көнләшеп тә карый.

18 *Локман ЗАКИР.* Нигә дип әле безнең Татарстан самолеты чит илгә корал ташу белән шөгыльләнә?

19 *Язилә АБДУЛКАДЫЙРОВА.* Балаңны үз рухыңда, үз телеңдә тәрбияләргә хәлеңнән килмәгәч, ник башка милләт кешесенә өйләнергә?

Хатын кеше генә ачылмас сер,
Тылсым булып калыр асылында...

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

«Карт-коры һәм балаларның күз яше тамган илдә беркайчан да бәрәкәт булмаячак. Кызганыч ки, без яклауга мохтаҗлык турында, гадәттә, авыр көннәрдә генә зурдан кубып сөйләшәбез, ә игелек, мәрхәмәт, миһербанлык күрсәтү көн дә кирәк. Әйдәгез әле, безнең арада яшәүче әлгәрләребезне рәхим-ярдәмебездән ташламыйк, аларны Өлкәннәр көнендә генә түгел, ел буе, гомер дәвамында шәфкать канаты астына алыйк.

Мансуров

Зиннур МАНСУРОВ

МИН ӘЙТТЕМ

Рафаэль ХӘКИМ,
Татарстан Президентының дәүләт киңәшчесе

Гаага башлангычы һәм Татарстан

14-15 гыйнварда Гаагадагы Тынычлык сараенда элекке совет республикалары җитәкчеләре һәм вәкилләре җыелды. Грузия (Абхазия), Украина (Кырым), Молдова (Приднестровье, Гагаузия). Русия, Татарстан... Бу республикалар исемлеге үзе генә дә хәтердә бетмәс-төкәнмәс бәхәсләрне, митингларны, сугыш хәрәкәтләрен, сугыш корбаннарын, аннан соңгы озын һәм газаплы сөйләшүләр алып баруларны яңарта. Дубоссарлагы, Сухумидагы хәрби хәрәкәтләрне, Татарстандагы референдумны, Кырымдагы сайлауларны бөтен дөнья зур киеренкелек белән күзәтте. Мин безнең республикабызда дәүләт телләре мәсьәләсендә узган бәхәсләрне искә төшерәм. Алар Молдовадагы шуңа охшаш хәлләр белән параллель рәвештә барды. Архивта әле дә төрле республикаларның телләр турындагы проектлары һәм законнары ята. Ул вакытта молдовалылар бер генә телне дәүләт теле итү юлын сайладылар һәм шундук сәяси киеренкелек үсә башлады. Аннары сәяси аренада Румыния белән Молдованы берләштерергә теләүче көчләр пәйда булды. Һәм Молдова икегә бүленде. Сәяси картада өч дәүләт теле булган Приднестровье (молдован, украин һәм урыс телләре), Гагаузия (молдован, гагауз һәм урыс телләре) барлыкка килде. Кызу бәхәсләр низаг рәвешен алды, кешеләр кулларына корал тотты, кан коелды.

Татарстанда ике дәүләт теле кабул ителде, ә суверенитет этник принцип буенча төзелмәде. Киеренкелек кимеде...

Бездән еш кына, ни өчен Татарстан тышкы чикләре, армиясе булмауга һәм анда татарларның азрак өлеше яшәүгә карамастан, федераль хөкүмәт белән тигез хокуклы сөйләшүләр алып бара һәм Килешү төзи алды, дип сорыйлар. Моның сәбәбе шунда ки, республика җитәкчелеге позициясен халык яклап чыкты. Сөйләшүләр алып барганда халык фикере таяну ноктасы булды. Бервакыт Мәскәүдә югары дәрәҗәле түрәләрнең берсе үзләренең махсус рәвештә халыктагы төрле катлауларның республика җитәкчелегенә карата мөнәсәбәтләрен өйрәнгәнлекләре турында әйткән иде. «Нәрсә эшлисең инде, — диде ул, сүзен йомгаклап, — урыслар һәм татарлар Шәймиевне яклыйлар шул».

Күпләр, сәясәтчеләр кабул ителгән законнарга һәм декларацияләргә, халыкара йөкләмәләргә һәм конституциягә таянып эш итәләр, дип уйлыйлар. Кызганычка, бу гел шулай түгел. Русия делегациясе белән сөйләшүләр алып барган вакытта моңа бик күп тапкырлар инанырга туры килде. Сәясәтчеләр үз мәнфәгатьләрен күздә тотып эш итәләр һәм контрагентлар көче белән исәпләшәләр. Ә инде соңыннан гына юристлар нәтиҗәгә уңайлы форма бирәләр. Гадәттә, хокукка түгел, көч куллануга һәм башбаштаклыкка таянып эш итүче Русиянең сәяси культурасы өчен бу аеруча хас сыйфат. Татарстанның Русия белән мөнәсәбәтләрендәге көче аның халкының бердәмлегеннән, полиэтник, полимәдәниятле гражданнар җәмгыяте булудан гыйбарәт. Дөньяда этникара мәсьәләләрне уңышлы хәл итүнең үрнәкләре бик күп түгел. Яшь дәүләтләрнең күпчелеге низаглар аша уздылар. 1993 елның көзендә Казанга Көнбатышның этникара мөнәсәбәтләр буенча иң яхшы экспертларыннан берсе, Дюкс университеты (АКШ) профессоры Дональд Хоровиц килгән иде. Ул Татарстанда җитди низаг өлгереп килә дип уйлаган булган. Дөньяда бөтен җәмгыятьләр дә бүленгән, диде ул. Монда фәкать төрле халыклар арасындагы дуслык мөнәсәбәтләрен саклауда 100 еллык тәҗрибәгә ия булган Швейцарияне генә исәпкә алмаска мөмкин. Казанда ул, җәмгыятьнең бүленгәнлеген исбатлаучы билгеләр эзләп, республика җитәкчеләре, партияләр лидерлары, чиркәүләр һәм мәчеткә йөрүчеләр белән әңгәмә корды, урамда кешеләрне туктатып, аларга төрле сораулар бирде. Чиркәүдә бу профессор бик уңайсыз хәлдә калды. «Христианнарның мөселманнар белән нинди проблемалары бар?» дигән сорауга, настоятель кырыс кына итеп, мөселманнар белән проблемалар юк, ә менә Америкадан килүче сектантлар белән бар, дип җавап бирде. Кайтып киткәндә Д.Хоровиц: «Татарстанда кызыклы тәҗрибә үткәрелә», диде. Республикабыздагы хәлне өйрәнү аңа шулай ук Русия чынбарлыгының үзенчәлекләрен дә аңларга ярдәм итте. Халыкара форумнарның берсендә ул америкалыларга турыдан-туры АКШтагы федерализмны Русия җирлегенә күчерүнең ялгышлык булуын белдерде. «Аларның тарихлары бөтенләй башка төрле», — дип йомгаклады ул сүзен.

Безгә үзебезнең сәяси эшчәнлегебезгә читтән карар өчен вакыт җитми, без аны тарихи тәҗрибә буларак кабул итмибез. Ә кемгәдер ул низагларны булдырмауда ярдәм итәргә мөмкин. Күрәсең, шуңа күрә дә бер төркем элекке совет республикалары, шулай ук халыкара оешмалар һәм экспертлар безнең Гаагада түгәрәк өстәл оештыру турындагы башлангычыбызга бик тиз кушылганнардыр. Дөньяда низагсыз үсеш мәсьәләсендәге уңышлы тәҗрибәләр әллә ни күп түгел; аларны ныклап өйрәнергә кирәк. «Ахмак үз ялгышларында, акыллы башка кешеләр ялгышында өйрәнә...»

Кырым. Кемнеке ул? Берәүләр ул Украинаның бер өлеше һәм территориаль бөтенлекне бозарга ярамый, икенчеләре, Кырымны Украинага бирү гадел эш булмады, Кырым ул — Русиянең бер өлеше, диләр. Һәм бу бәхәсләр барышында Кырым татарлары гына түгел, бөтен Кырым халкы онытылып кала. Әйе, Кырым — Украинаның бер өлеше. Ул, чыннан да, Русиянең бер өлеше иде, чөнки заманында аны Русия яулап алды. Ә аңа кадәр ул Кырым ханлыгы иде. Шул ук вакытта Кырым татарлары — ярымутрауның заманында депортацияләнгән һәм әле үз Ватанына тулысынча кайтарылмаган төп халкы. Ул «тарихи дөреслек» торгызылуга өметләнә. Урыслар күпчелекне тәшкил итәләр, алар ягында энергетик һәм хәрби куәткә ия Русия тора. Украиннар исә «территориаль бөтенлек» принцибына таяна. Ә аларның киләчәктә дә чәчәк ату чыганагы Русия яисә Украина түгел, үз җирләре. Төрле этник группаларның мәнфәгатьләре балансына нигезләнгән гражданнар җәмгыятеннән башка Кырымда сәяси тотрыклылык булдыру һәм аны үстерү турында сүз дә алып бару мөмкин түгел.

Кырым шундый хәлдә калды ки, Киев белән булган мөнәсәбәтләрендә аның әлегә маневр ясарлык форсаты бар һәм монда Татарстан тәҗрибәсе модель ук булмаса да, ахыргы очракта үзәк белән мөнәсәбәтләрне көйләүдә башлангыч нокта була ала. Татарстан моделе дәүләт төзелешен үзгәртмичә, аерым килешү төзү нигезендә Кырымның статусын күтәрергә, шулай ук сәяси киеренкелекне генә түгел, Киевның кайбер икътисади проблемаларын да хәл итәргә мөмкинлек бирә. Сүз уңаеннан шуны искәртеп узасы килә: Испаниядә «федеральләштерү» нәкъ менә аерым килешүләр төзүдән һәм Баскларда, Каталониядә һәм башка җирләрдә референдум үткәрүдән башладылар. Фәкать шуннан соң гына 17 провинциягә автономия бирделәр.

Килешүләр нигезендә мөнәсәбәтләр урнаштыру Молдовадагы (Приднестровье) һәм Грузиядәге (Абхазия) низагларны көйләүнең бердәнбер хәрби булмаган юлы булып тора. Андагы хәл Татарстандагыдан һәм Кырымдагыдан бик нык аерыла. Монда сүз чынында бер-берсенә шикләнеп караучы мөстәкыйль дәүләтләрне берләштерү турында бара. Әмма бу очракта төп мәсьәлә — принцип сайлауда. Ассоциацияләшкән мөнәсәбәтләр урнаштыру вәкаләтләрне үзәккә яисә башка төрле уртак органнарга тапшыруны шактый уңайлы гына хәл итү мөмкинлеге тудыра. Шул ук вакытта Абхазиянең һәм Приднестровьеның үз суверенитетларын саклап калу гарантияләре булачак, ә Грузия белән Молдова дәүләтләренең территориаль бөтенлеге бозылмаячак.

(Ахыры 5 нче биттә).

Нәкъ әкияттәгечә...

Аптыраган үрдәк арты белән суга чума, диләр бит. Русия хөкүмәте дә Думага сайлаулар алдыннан нинди генә чаралар уйлап тапмый. Икә ятып бер төшенә керми, дигәндәй, төрки халыкларны да иске төшерәләр. Конгрессын җыялар. Әмма Татарстанның милли оешмалары анда делегация җибәрүне хупламый. Беренчедән, аларның вәкилләрен чакырмыйлар. Икенчедән, милли оешмаларның кул-аякларын бәйләп, җитәкчелекне үз кулларына алырга ниятләмиләрме, дигән шик тә туа. Шуңа күрә Дәүләт Советы депутаты Фәндәс Сафиуллин һәм аның белән фикердәш бер төркем депутатлар конгресска делегация җибәрүгә каршы булалар. Шулай да рәсми делегация китә. Аның составына Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ренат Харисов, Премьер-министр урынбасары Илгиз Хәйруллин, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе Индус Таһиров һәм чуваш, казакъ милли оешмалары җитәкчеләре керә.

Төрки халыклар конгрессының оештыру корылтаенда барлык милләт вәкилләре, шул исәптән бездән академик И.Таһиров та чыгыш ясый, һәркайсы үз милләтләренең ихтыяҗларын сөйли. Анда Татарстан белән Русия мөнәсәбәтләрен каралтып күрсәткән коткылы анкета да таратыла. Моңа Татарстан делегациясе шундый итеп кистереп җавап бирә ки, анкета сорауларын үз куллары белән әвәләүчеләр хәтта аңардан баш тарталар. Менә шуларны күреп-тыңлап торган Вячеслав Михайлов, ягъни РФнең милләтләр эше һәм төбәкләр сәясәте буенча министр, ашык-пошык әвәләнгән нотыгын укый да, Г.Тукайның «Кәҗә белән сарык» әкиятендәгечә, ашыгыч эш бар, дип, корылтайны ташлап ук китә. Аның белән килгән башка вәкилләр дә эзләрен суыталар. Ә инде башкарма комитетка әгъзалар сайлау чын афәткә әйләнә. Аңа Мәскәүдәге 30 лап оешмадан бер вәкил дә кертелми. И.Таһиров исә аңа әгъза булып керүдән баш тарта. Сайланачак әгъзалар арасында Русиянең башка төбәкләреннән килгән татар вәкилләренең күплеге башкортларның күңеленә тия, үз вәкилләре әгъза булып сайланмагач, Чувашстан делегациясе корылтайны ташлап чыгып китә.

Яңарыш, килешүчәнлек дип исемләнгән корылтай башланганда ук таркаулык китереп чыгара. Русия хөкүмәте бәлки төрки халыкларга матди ярдәм итәр, дигән өмет тә акланмый. Алай гына да түгел, шушы җыенны үткәрү өчен бу министрлык хәтта үзе, «Азатлык» радиосы хәбәр иткәнчә, Татарстаннан 100 миллион сум акча сораган икән, делегатларга командировка чыгымнарын түләүне таләп иткән. Монысы инде бернинди кысага да сыймыйдыр.

Мәскәү халык ихтыярына ревизия ясарга әзерләнә

РФ Президентының администрация башлыгы С.Филатов белдергәнчә, федерация субъектлары тарафыннан чыгарылган законнарга экспертиза ясау һәм аларның федераль законнар белән туры килү-килмәвен тикшерү өчен яңа структура булдыру турында Президентның фәрман проекты әзерләнгән. Шул ук Филатов әфәнденең әйтүенә караганда, РФ составындагы кайбер республикаларның конституцияләрендә «суверенитет» төшенчәсен аңлатуда федераль законнар белән каршылык бар икән. Андый республикалар рәтендә беренче чиратта Тува, Татарстан, Саха исемнәре атала.

Кыскасы, мәскәүләр суверенитет кебек изге төшенчәне үзләренә яраклаштырып, үзләренчә шәрехләргә җыена. Ә без, татарстанлылар, суверенитетны бары бер генә мәгънәдә аңлыйбыз, хөрмәтле Б.Н. Ул, французчадан тәрҗемә иткәндә, тулы бәйсезлек дигәнне аңлата.

Язучыларыбыз Русия гамен кайгыртырга ниятли

«Российская газета» Дәүләт Думасына депутатлыкка кандидат булып теркәлүчеләрнең исемлеген бастырып чыгара башлады. Алар арасында безнең ике язучыбыз да бар. Диас Вәлиев «Наше будущее» (җитәкчесе Сажи Умалатова) сайлау блогы аша теркәлсә, Ринат Мөхәммәдиев исә «Наш дом — Россия»не (җитәкчесе Виктор Черномырдин) якынрак күргән. Без аларга сайлау алды бәйгесендә уңышлар телибез. Ни әйтсәң дә, язучыларыбызның Жириновский партиясеннән депутат булырга теләмәүләре үзе үк хуплауга лаек иш.

«Шәрык» фестивальгә әзерләнә

Быелның октябрендә Иваново өлкәсендә Русия мәдәнияте көннәре уздырылачак. Шул уңайдан биредә «Шәрык» өлкә татар җәмгыяте дә бер атна дәвамында чыгыш ясаячак. Анда халкыбызның тарихы һәм мәдәниятенә кагылышлы кинофильмнар күрсәтү күздә тотыла. «Дуслык» фольклор ансамбле чыгышы да тамашачылар күңеленә хуш килер. Әлегә фестивальгә килү өчен Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты исеменә чакыру бар.

ӨЛКӘННӘРНЕҢ КӨЛӘЧ ЧАКЛАРЫ



...артаймыш көнеңдә ризык... калмасаң, кайгыртучыла... булса, шуңа рәхмәт әйтеп ... яшәрлек тә бит. Заманасы ...лып китте шул. Әмма сүзне ...акларга ашыкмыйк. Кай...типсә тимер өзәрдәй ир-ат...да өлкәннәрдән, аерып әйт...ә, пенсионер әби-бабайла... кенләшеп куя. Онытып бе...тәр өлкәннәрне, пенсия...дә тотрыклы биреп бара... һәрхәлдә, элек намус бе...хезмәт куйганнар картай...көнендә урамда хәер сора...утырмый.

...азан шәһәренең Совет рай...да яшәүче пенсионерлар өчен икеләтә шатлык. Аларга хезмәт күрсәтү хәзер заманча җиһазландырылган бинада алып барыла. Пенсионерлар турындагы барлык мәгълүматлар компьютерга салынган. Бу исә хезмәт күрсәтүне бик күпкә тизләтә. Районда 47 мең пенсионерны картотека буенча ничек эзләп утырыр идең әлә. Операторлар теге яки бу пенсионерга акчаның кайчан, күпме китүе хакында шунда ук әйтеп бирә. Шунысын да өстик, Өлкәннәр көне алдыннан, 28, 29 сентябрьдә Совет районы хакимияте ветераннарны «Комсомолец» кинотеатрына, Төзүчеләр мәдәният сараена концерт-очрашуга чакыра. Шунда ук пенсия бүлеге инспекторлары, юристлар, табиблар консультация бирәчәк. Түләүсез генә чәч ясатып, кыркытып алырга да мөмкин булачак. Анда сату-алу һәм «Ливади» шифаханәсе фитобары хезмәте дә күздә тотылган. Бу очрашу иртәнгә сәгать унда башлана.

● **Пенсия бүлеге оператор-хисапчысы Тәнзилә Полякова.**

● **Сиксән яшьлек Миңнегөлчирә Мөҗитованың да куанычлы чагы.**

Ә.ШӘФИГУЛЛИН фотолары.

Татар биюе алтынга тиң

...карада үткәрелгән төрки халыклар фестива...ә безнең Химиклар сараеннан барган «Яшь...» коллективы өч алтын медальгә лаек булды. ...лек»нең программасында дистәгә якын татар, ...орт, урыс биюләре бар иде. Ул Албания, Бол...я, Чехия, Төркия, Кипр кебек илләр биючеләре ...ән ярышта җиңде.

Ш.Бабич исемендәге бүләк

Башкортстан Министрлар Кабинеты яшь иҗатчылар өчен татар-башкорт шагыйрә, 1919 елда дошманнар тарафыннан җәзалап үтерелгән Шәехзадә Бабич исемендәге бүләк булдыру турында карар чыгарды.

Җомгадан — җомгага

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Татарстан Республикасының Дәүләт Советында Берләшкән Милләтләр Оешмасының 50 еллыгын билгеләп үтүгә әзерләнү уңаеннан документлар җыентыгы татар теленә тәрҗемә ителә һәм шул документлардан күргәзмә оештырылды. Тынычлык фондының Татарстан бүлеге стипендиясе булдырыла.

Берләшкән Милләтләр Оешмасының юбилеена багышланган айлык башланган көннә Казандагы М.Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркы янындагы каенлык аллеясенә БМОның 50 еллыгы хөрмәтенә агач утыртылды.

Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В.Лихачев Төркия илчелегендә бу илнең Русия Федерациясендәге гадәттән тыш һәм вәкаләтле илчесе Билгән Унан белән очрашып, Казанда Төркиянең генераль консуллыгы ачылуга бәйле мәсьәләләр турында сөйләште.

Татарстан Республикасы Премьер-министры Фәрит Мөхәммәтшин Һиндстан Республикасының Россия Федерациясендәге Миссиясе башлыгы урынбасары Припуран Сингх Хәәрне кабул итте.

Корылык фаш итә

Табигатьне күзәтеп, күрәзәлек итеп баручылар әйтүенчә, быелгыдай корылык күптән булганы юк икән. Моны үзебез үк күреп торабыз: кечкенә пароходлар йөреп торган Казансу аша хәзер, бераз шаяртып әйтсәк, чалбар балагын тез тиңентен күтәреп тә яланаяк чыгарга мөмкин. Елга түбән дә күрсәтте, ямь-яшел үлән баскан утрауларына мал-туарны утларга җибәрерлек. Казансу аша салынган күперне күтәреп торучы баганалардагы эз-билгеләргә күз салыгыз: су нәкъ ике метрга кимегән.

Шушы хәл тагын бер тарихи фаҗигабезне фаш итте. Зөя (Свияжски) утравы тирәсеннән су киткәч, елга төбендә йөзләрчә кешенең гәүдә, баш сөякләре аунап ятканын күреп, халык хәйран калды.

Зөя утравында Иван Грозный тарафыннан төзелгән монастырь һәм чиркәүдә шәхес культы чорында — 30 нчы елларда дүрт меңгә якын җинаятьче һәм сәяси тоткын төмуг газабы кичергән икән.

— Ул чакта монда кешеләрне, агач кебек, суга ыргыталар иде,— дип искә ала йөрәк әрнеткеч вакыйгаларны хәтерләгән бер карчык. Хәзер җирле властьлар аунап яткан кеше сөякләрен җыеп, күмү йоласын үткәрергә җыеналар, ди. Ул йола ничек үткәрелер: Рәсәйдә гадәткә кергән христиан тәртибе беләнме? Ә бит анда мөселман тоткыннары да булгандыр... Ә менә татарларның дәүләтчелеген бетерергә тәрәк булган, шәхес культы чорында төрле милләт кешеләренең ачык һавадагы, су астындагы каберлегенә әверелгән бу шәһәрчекне һәйкәл итәргә җыеналар. Әмма тарихны онытмыйк: анда һәйкәлнә бары тик кара таштан гына куярга мөмкин.

К.Тинчурин исемендәге театр бинасында Башкортстанның Стәрлетамак театры гастрольләре бара. Театр коллективы Казан тамашачыларына 15 спектакль күрсәтәчәк. Гастрольләр 8 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

● «Онытылган дога» спектакленнән бер күренеш.

Тарих биргән соңгы мөмкинлек

Русия Дәүләт Думасы утырышынна... ара-тирә телевидение аша өзек-өтек к... нә күрсәтелгән тапшыруларны карагач, ч... чләрең үрә тора: ир-ат депутатларның үз... ра сугышуы гына җитмәгән иде, хәзер к... күрмәгән, колак ишетмәгән маҗаралы т... машаның шаһиты булабыз. Ир-ат депута... моңарчы кул белән кагылу түге... ә тел-теш тидермәгән гүзәл затны — х... тын-кыз депутатны чәченнән тартып-йо... кып әрләшә. (Моны Америка телевидени... есе тәүлек дәвамында күрсәткән, д... Иман да, намус-оят та юк. Һәм акыл... утыртып та булмас. Алар урынына нам... лы, иманлы кешеләрне сайлап кына б... хәлдән котылырга мөмкин. Ә хәзер Рус... ядәге 20 миллион мөселманның мәнфә... тен Дәүләт Думасында кем кайгырта?

Шуны истә тотып булса кирәк, Дәүл... Думасына сайлауларга нәкъ 6 ай кала М... скәүдә Русия мөселманнарының ике па... тиясе (берсе — Русия мөселманнары б... леге, икенчесе — «Нур» исемле) бер... көннә теркәлә. Хәзер аларның депута... лыкка кандидатлар күрсәтергә тулы хо... кы бар. Мәскәүдә менә шуңа багышлан... корылтайлар булып узды. Анда Татарста... нан мәгълүм өч шәхес тә катнашты, шу... рның икесе — бер мандатлы 24 нче Чал... сайлау округыннан язучы-публицист А... дар Хәлим, шулай ук бер мандатлы фе... раль округтан җырчы Вафирә Гыйззәту... лина депутатлыкка кандидат буларак т... кәү өчен тәкъдим кылынды, дип хәбәр и... «Азатлык» радиосы. Бу уңайдан «Ит... фак» партиясе рәисе, язучы Фәүзия Б... рәмова фикере:

— Минем монда кунак-киңәшче була... катнашуым да гаҗәп тоелыр. Чөнки м... Русия империясенә җаным-тәнем бе... каршы. «Иттифак» партиясе Дәүләт Д... сына сайлауларда да катнашмый. Ә... шуны да әйтергә кирәк: Русиядәге 20 м... лион мөселманның, Татарстаннан чи... яшәүче 5 миллион татарның хокукла... кем яклар? Демократлармы? Коммуни... лармы? Юк, мөселманнар үзләре! Һәм т... рих тарафыннан бирелгән соңгы мөм... лек! 1905 елда мөселманнар I корылта... «Иттифак» партиясенә берләштеләр. Д... ләт Думасының өч чакырылышында да ... селманнар фракциясе була. Фракци... Гаяз Исхакый, Габдулла Баттал-Тай... Садри Максуди кебек күренекле та... язучылары, сәясәтчеләре яклый. Шун... соң 90 ел дәвамында мөселманнар власт... ка килә алмады. 20 нчы гасыр ахыры... кабат шундый мөмкинлек туды. Аны ку... дан ычкындырмыйк.

Йолдызлар йолдызны ерактан таный

16-23 сентябрьдә Мәскәүдәге Яшьләр сараенда «Иртәнге йолдыз» телевизион конкурсы булып узды.

7 турдан торган әлеге конкурста яшь җырчыбыз, 12 яшьлек Муса Маликов та катнашты.

БДБнең 24 шәһәреннән килгән яшь җырчыларның башкару осталыклары гаять югары һәм көч сынашу үтә дә кискен шартларда баруга да карамастан, безнең Муса вакытыннан элек финалга чыга алды.

Конкурста ул «Вернись в Сорренто!», «О, мое солнце!» дигән итальян җырларын һәм шагыйрь Җәүдәт Дәрзаманның «Сугыш кайтавазы» шигыренә үзе язган көйне башкарды. Валентина Леонтьева, Ангелина Вовк, Олег Газманов һәм Анастасия кебек йолдызлардан торган жюри әгъзалары бертавыштан өстенлекне Татарстан вәкиленә бирделәр. Шулай итеп, Муса конкурсның Гран-приена лаек булды.

Октябрь ахырында Муса Маликов «Телеутро» программасына төшәчәк, ә ноябрь һәм киләсе елның февраль айларында Мәскәүдә Осипов исемендәге халык уен кораллары оркестры белән чыгыш ясаячак. Ә декабрьдә аны Таллинда үткәреләчәк халыкара эстрада йолдызлары конкурсы көтә. Афәрин, Муса! Киләчәктә татар җырын барлык кыйтгаларда яңгыратырга язсын сиңа.

Багдад — байлар каласы

Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле Гыйрак Республикасына китте. Ул анда ел саен уздырыла торган халык иҗатының YII халыкара фестивалендә катнаша.

Багдад бик бай шәһәр, диләр. Бездә тиен-миенгә генә эшләүче артистларыбызның кесәләре бу юлы бераз гына булса да калынаер дигән өмет бар.

Айдар — Татарстан җырчысы да

1 октябрьдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Башкортстанның эстрада йолдызы Айдар Галимов концертлары башлана. Җырчының яңа программасы «Җырларым — канатларым минем» дип атала.

Айдар Галимов шулай ук Зеленодол, Саба, Балтач, Кукмара, Питрәч районнары мәдәният йортларында да чыгыш ясаячак. Җырчы белән әңгәмәне гәзитебезнең 8 нче битеннән укый аласыз.

Тукай клубында — Тукай авылдашы

Татарстан Язучылар берлегенең Тукай клубы тагын җанлы иҗади тормыш белән яши башлады. Аның беренче кичәсе Тукайның авылдашы, шагыйрь һәм язучы Әнәс Галиевнең иҗатына багышланды.

Аэробика остасы — халык артисткасы

Мәскәү өлкә филармониясенең балет солисты Сабитова Лилия Рәшит кызына Русия Федерациясенең халык артисты дигән мактаулы исем бирелде.

Коминың үз «Болгар»ы бар

Узган атнада башкалабызга Коми Республикасының Усински шәһәрендә эшләп килүче «Болгар» татар-башкорт иҗтимагый-мәдәни үзәге рәисе, бөтентатар Милли Мәҗлес депутаты Бибинур Прохорова килгән иде. Ул «Болгар» үзәге тырышлыгы белән узган ел Усинскида берничә урында татар телен өйрәнү курслары эшләвен, җирле радионың атнага бер тапкыр татарча ярты сәгатьлек программа белән эфирга чыгуын, җирле телевидениенең дә милли мәсьәләләргә битараф булмавын хәбәр итте.

Рухыбызның аумас манарас...

Мөхтәрә...
җәмәгат...
Хәтерегезгә...
төшерегез...
һәм исегезд...
калдырыгы...
нәкъ моннан...
5 ел элек...
26 сентябрь...
Сөемби...
манарасы...
алтын...
куелд...
Нә...
исмәгы...

…аль ХӘКИМ

Гаага башлангычы һәм Татарстан

(…ары Башы 2 нче биттә).

…е ассоциацияләшкән Пу… дәүләте» дигән рәсми …түче Пуэрто Рико АКШ …нәсәбәтләрен 1975 елда …ган ике яклы килешү ниге… Бу ике төрле граждан… …нен дәрәҗәле органнары …катнашу, сайлаулар үткә… …аль бюджетка түләүләр, …мәсьәләләре кебек тулы …м катлаулы мәсьәләләрне …файдалы итеп хәл кылуның …р мисалы булып тора. …ветеру өчен диалогны ике …кызыксындырган һәм ике …файдалы нәрсәдән баш… …Куперләрне тотышты… …лыкта бу – яңа сугышка …мөмкин, дигән уй гума… …теле бер дәрәҗәдә сак… …саклана. Киеренкелек …ган саен мөнәсәбәтләр …лешү нигезендә гагын да …булырга мөмкиннәр. …матбугатында Русиянең …киттерәчәк асимметрик …лар тәнкыйтьләнә. Әм… …СССР һәм хәзерге Русия …булган мондый этник, …климатик, икътисади …федератив мөнәсәбәт… …симметрик Прокруст ята… …дырып булыр микәнни? …камил, бу мөмкин түгел. …көч куллану юлы белән ге… …ның да бертөсле яшәве… …рә була. Ә иң мөһиме …кирәге дә юк. Күп кенә …асимметриялелек норма …яшәп килә һәм беркемне …тмый. Искә алган АКШ… …Испаниядән кала, Алма… …федерация субъектлары …бер статуска ия. Бавария …нчиянен үз конституция… …лар (земля) дип түгел, …дәүләтләр» дип аталуы …ның күп кенә халыкара …рне мөстәкыйль рәвеш… …беркемне дә гаҗәпләп… …Дания составындагы Грен… …мондый зур хокукларга ия. …Аурупа Союзына керүдән …тты. Юкса, Дания үзе …хокуклы әгъзасына әве… …

…т Канадада хокуклар …риялелеген сәяси тотрык… …мисалы сыйфатында … Чынында исә монда …киресе күзәтелә – Кве… …туция белән беркетелгән …укларга ия булу аркасы… …дә Канада составында … Сүз уңаеннан шуны ис… …ик, 1973 елда Квебекка …беркетелгән иде. Ул елны …ларын гомумфедераль …тәңгәл итмәкче булган… Нәтиҗәдә Канадада го… …кризис башланды һәм …ниянен аерым бер ста… …булуы белән килешергә … Канаданың башка …ләре дә үз хокукларын… …ча файдаланалар һәм …риялле мөнәсәбәтләр бар… …рәләр. Мәсәлән, Онта… …үз полициясе бар. Шул ук …башка провинцияләрдә …полиция тәртип саклый. …һәм мәдәни аерымлыкла… …һәрбер илдә асимметри… …тылгысыз Кырымның үз тарихы, анда халыкның этник составы да үзенчәлекле. Шуңа күрә дә аның сәяси статусы да үзенчәлекле булачак. Мөстәкыйль дәүләт буларак яшәүче Абхазия, әлбәттә, инде. Грузиянең аны үз провинциясе итәргә теләве белән килешмәячәк. Ана ныклы гарантияләр кирәк. Үз валютасын чыгаручы һәм бәйсез дәүләт структураларына ия булган Приднестровье да провинция булырга теләмәс. Мин ышанам, асимметриялелек күчеш стадиясе булу белән бергә, тормыш төрлелеген чагылдыручы норма да була ала. Нәрсә генә булмасын, бу аномалия түгел.

Грузиннарның һәм абхазларның Гаагадагы халыкара суд казыйлары утыра торган залда бер-берсен гаепләүләрен тыңлаганда, мин хәерчелек һәм җимереклек хәленә килгән элекке Тбилиси, Кахетия, Сухуми, Гаграны күз алдына китерә алмадым. СССРда Грузия бай тормыш һәм югары милли мәдәният символы иде. Хәзер ул хәерчелектә һәм гуманитар ярдәм хисабына яши. Ышануы авыр, әмма нәкъ менә Грузиядә Китовани һәм Каркарашвили кебек әшәке шәхесләр пәйда булды. Күренә ки, нинди зур абруйлы Шеварднадзе да илне тулы контрольдә тота алмый. Без Гаагада низагларны көйләү юлларын эзләгән вакытта Китовани боевиклары автобусларга тоялеп «абхазлыларны акылга утыртту» өчен чик буена юнәлделәр. Дөрес, бу юлы аларны туктата алдылар. Абхазия сугышта җиңеп чыкты, әмма бу җиңү аңа бик кыйммәткә төште. Аңлаешсыз халыкара статус, качаклар, бушап калган курортлар. Артта һәлак булган дусларның, туганнарның, ватандашларның күләгәләре басып торганда сөйләшүләр алып баруы кыен шул. Алар үч алырга чакыралар. «Күз өчен күз, без барыбыз да сукыр калачакбыз», — дигән иде Махатма Ганди. Грузиннар һәм абхазлар тарихка, конституциягә һәм халыкара хокукка ишарә ясап үзләренең хаклы булуларын исбатларга тырышалар. Бәлки аларның бәхетсезлеге тегге якның да, бу якның да хаклы булуындадыр?

Русия белән сөйләшүләр алып барганда Татарстан делегациясенә прагматлылык һәм центристлык ярдәм итте. Мәскәүнең һәр аргументына Казанның үз контраргументлары булды. Һәм, киресенчә, безнең дәгъваларга алар үзләренең дәгъвалары белән җавап бирделәр. Бәлки, бигүк гадел дәгъвалар белән дә түгелдер, әмма алар Русия өчен сәяси яктан әһәмиятле иделәр. Безгә чарасызлыкка барып җитмичә, үзәккә республика мәнфәгатьләрен куя алу осталыгы кирәк иде. Аек акыл күзлегеннән караганда, яхшы аңлашыла торган мондый позицияне төрле стереотиплар булу аркасында гамәлгә ашыру бик авыр. Сөйләшүләр уңай нәтиҗә бирсен өчен гаять зур сәяси ихтыяр көче кирәк иде. Татарстан Республикасы, килешү төзергә ашкынып тору белән бергә, өч ел буена әллә ни зур үзгәреш кичермәгән команда составына да ия иде. Шул ук вакытта Русия делегациясе составында Геннадий Бурбулис, Валерий Тишков, Сергей Шахрай, Юрий Яров һәм, ниһаять, Борис Ельцин булырга өлгерделәр. Даими рәвештә алышынып торган Русия делегациясе белән чагыштырганда без сәяси мәсьәләләрне тирәнтен уйлап хәл итәргә һәм катлаулы дискуссияләр алып барырга мөмкинлек бирүче өстенлеккә ия булдык. Сөйләшүләрнең уңышлы гәмамлануы шулай ук аларның төрле дәрәҗәдә алып барылуларына да бәйле иде. Иң югарысында – ике Президент һәм ике хөкүмәт җитәкчеләре очрашканда, килешүләр пакетына кул кую өчен сәяси килешүне хәзерләү буенча рәсми делегацияләр очрашканда, шулай ук министрлыклар дәрәҗәсендә конкрет мәсьәләләрне хәл итү максатында очрашулар үткәрелгәндә. Шул рәвешле, республика тормышы өчен мөһим мәсьәләләр хәл ителү белән бергә, Русиянең үз башкарма хакимияте структураларында булган каршылыклар җиңеп чыгылды.

Заманында А. Сахаров, СССР дип аталган бер империя урынында кечкенә империяләр барлыкка килергә мөмкин, дип кисәткән иде. Сәяси мәсьәләләрне көч кулланып хәл итү теләгеннән баш тарту һәм халыкларның мөстәкыйль үсешкә хокуклы булуларын тану өчен вакыт кирәк. Бер каршылык икенче каршылыкны барлыкка китерә. Азатлык ышаныч тудыра, дигән иде ул.

Кызганычка, элекке совет дәүләтләренең барысында да үзәк үз вәкаләтләренең бер өлешен урыннарга бүлеп бирсә, дәүләт көчсезләнәчәк, дигән фикер яшәп килә. Халыкларга «юл бирү» җитәкчеләр тарафыннан түбәнсетелү кебек кабул ителә. Шул ук вакытта дөнья тәҗрибәсе бөтенләй башка нәрсәне күрсәтә. Нәкъ менә үзәкләштерү бетерелгән һәм төрле этник төркемнәр хокуклар субъекты рәвешендәге гарантияләргә һәм милли азчылыклар турындагы законнарга ия булган илләрдәге федерация генә нык һәм какшамас була ала.

Татарстан белән килешү төзү Русиядә сәяси кризис барлыкка китермәде һәм хәтта федераль хөкүмәтнең абруен күтәрде. Шул ук вакытта Чечнядагы хәлләр Мәскәүдәге тотрыклылык өчен куркыныч тудырды, көн тәртибенә яңадан Русиянең бердәмлеге һәм бүленмәслеге мәсьәләсе куелды.

Ни өчен Татарстанга мөстәкыйль халыкара сәясәт кирәк тә һәм Гаага башлангычы кебек башлангычлар белән чыкканда безнең мәнфәгатьләр нәрсәдән гыйбарәт? Халыкара мөнәсәбәтләрдә үз позициябезне булдырырга теләвебезнең берничә сәбәбе бар. Иң беренче нәүбәттә, без Татарстан статусын һәм Русия белән урнашкан мөнәсәбәтләрне таныту белән кызыксынабыз. Мәскәү җитәкчеләренең икеләнүләре булачак ике яклы мөнәсәбәтләргә йогынты ясарга тиеш түгелләр. Моның өчен халыкара яклау табарга кирәк. Тормыш тәҗрибәсе күрсәткәнчә халыкара җәмәгатьчелек фикере Русия җитәкчелегенең үз-үзен тотышына йогынты ясаучы фактор булып тора. Гаага башлангычыннан соң Көнбатыш матбугатында Татарстанның тынычлыкны яклау сәясәтенә игътибар биргән мәкаләләр дөнья күрде. Генераль сәркатип Бутрос Гали БМОның Куркынычсызлык Советын яңа башлангыч турында мәгълүматлы итүне кирәк дип тапты һәм очрашу вакытында М. Шәймиевкә рәхмәт белдерде. Моны Мәскәүнең үзендә дә игътибардан читтә калдырмадылар. Тынычлык урнаштыру буенча башлангычлар белән чыгу республиканың абруен күтәреп, аның актив икътисадый хезмәттәшлек элемтәләре урнаштыруы өчен тагын да зуррак мөмкинлекләр тудыра. Ә моннан башка дөнья базарына кереп булмый. Ниһаять, мондый сәясәт империяне торгызырга теләүче көчләргә каршы киртәләр булдырырга ярдәм итә.

Кырым да, Приднестровье да, Абхазия дә турыдан-туры Русиягә бәйләнгән. Приднестровьеда Русиянең 14 нче армиясе тора. Кырымда Русия составында калырга теләүче көчләр күп, Абхазия элек тә Русия ярдәменә мохтаҗ булган, бүген дә аның ярдәменә ышана. Чечнядагы хәлләр гамәлдәге мөнәсәбәтләр структурасын бозды һәм яңадан империя торгызылу куркынычын тудырды. БДБ илләре инде элекке СССРга әйләнеп кайтырга теләмиләр. Әмма моның өчен теләк булмау гына җитми. Гаага башлангычы элекке совет дәүләтләрендәге низагларны кан коюдан башка хәл итү юлларын эзләү буенча зур һәм катлаулы эш башлап җибәрде.

ТАТАР КАЛЕНДАРЕ — 96

Татарстан китап нәшрияты стенага элеп куя торган татар календарен (численник) быел сентябрь аенда ук бастырып чыгаруга иреште. Бу, әлбәттә, аны сатуны оештыруны җиңеләйтәчәк. Әмма татар календарен ел беткөндә генә алырга өйрәнгән халыкны кыен хәлдә калдыру ихтималы да бар. Чөнки, һәр елдагыча, календарьның тиражы артык зур түгел (200 мең). Ягъни аны сату 2-3 атнада тәмамланачак. Шуңа күрә, очраганда, татар календарен алып калырга тәкъдим итәбез (ел ахырында эзләп-эзләп тә таба алмавың бар).

1996 ел өчен бастырылган татар календарен сату бәясе түбәндәгечә: акча күчерү юлы белән (1000 данәдән ким булмаган очракта гына рөхсәт ителә) — 2900 сум, ә турыдан-туры нәшрияттан акча түләп алганда 3000 сум (Башка сату оешмаларындагы бәяләр өчен нәшрият җавап бирми).

Күчерү юлы белән алучылар акчаны Казаннан:

р/с 363901 ТКСБ г.Казани МФО 265016;

республика районнарыннан һәм чит өлкәләрдән

р/с 363901 кор.счет 700161503 в РКЦ НБ РТ МФО 265005 исәбенә күчерергә тиеш.

Нәшриятта календарьның бәтү-бетмәвен белешү өчен телефоннар 32-66-07 яки 32-77-05.

Амур ШАКИРҖАН

Ат арбасына бишенче тәгәрмәч кирәкме?

Район үзәгендә йомышымны хәл иткәч, Казан юлына чыгып бастым. Чирек сәгать тә үтмәде, Казанга баручы йөк машинасы килеп чыкты. Шуңа утырып китеп тә бардым. Кемнәр белән генә таныштырмый бу юл дигәннәре.

Рульдә утырган Зиннәт бик аралашучан кеше булып чыкты. Сөйләшеп киттек. Аңлашыла инде, беренче сүзебез көнкүреш турында булды.

Хөкүмәт мәсьәләләренә дә кагыла башлагач, тәмәке кабызып җибәрдек. Берара вакыт гәпләшкәч, ниһаять, Зиннәт янә сүз башлады:

— Әгәр мин министр булсам, иң әүвәл барлык ярдәмчеләремнең, урынбасарларымның ышанычлымы, юкмы икәнлекләрен тикшереп чыгар идем.

Аннары ул шундук машинаны туктатып, үзе утырган яктагы алгы тәгәрмәчне карарга чыгып китте. Тишелгән икән тәгәрмәчебез.

Запас тәгәрмәч куеп, бераз киткәч, Зиннәт баягы сүзен дәвам итте:

— Ярый, барысы да ышанычлы да булсыннар, ди. Әмма минем белән һәрчак килешүчән, миңа каршы бер сүз дә әйтергә кыймаган урынбасардан нинди файда көтеп була? Димәк, икебезнең берсе артык, бөтенләй кирәге юк...

— Ялгышасың, Зиннәт, — дидем мин, аны бүлдереп. — Син бер нечкәлекне онытасың... Менә әле генә син көпчәк алыштырдың. Янныбызда запас тәгәрмәч булмаса, хәзер нишләр идек?

— Ю-у-ук... Бу уңышлы чагыштыру түгел... Күрәсең бит, бер тәгәрмәч тәзек булса да барыбер эшсез тора. Урынбасар да хәвеф-хәтәр чыкканчы тик торырга тиешмени? Ә инде бишенче тәгәрмәчнең кирәге бик сирәк очракларда гына килеп чыга. Ат арбасына артык тәгәрмеч салып йөрмиләр бит. Әгәр тәгәрмәч нык һәм ышанычлы материалдан эшләнгән булса, алмаш тәгәрмәчнең, гомумән, хаҗәте юк... Мин һәрторле урынбасарга каршы — аларның барысы да артык, барысы да адәм имгәге! Ни өчен рәссамның, шагыйрьнең, җырчының, укытучының, шоферның һәм идән юучының урынбасары юк? Бик күпләр урынбасарсыз эшлиләр, урынбасарсыз яшиләр бит. Ә ялдагы яки авырган түрәнә алыштыру өчен генә урынбасар тоту, минемчә, ахмаклык ул. Эшләмәгән кеше ашамый, вәт. Әнә Югары Совет сессиясендә дәүләт һәм хөкүмәт аппаратындагы түрәләр санын киметү турында сүз чыккач, зал тач тыккан умарта оясыдай гөжли башлады... Эшнең кая таба баруын сизделәр, барысы да тыпырчынырга тотынды. Урынбасарсыз калачак түрәләр инде бигрәк тә. Ышту син, урынбасарсыз калу аларның бөтен тынычлыгын чәлпәрәмә китерә, хәтта йокысын качыра, чөнки шәхси җаваплылыкның хәлиткеч нәрсәгә әверелүе аны куркыта — аңа күмәклек, күмәк җаваплылык артына качып калу күпкә җайлырак бит. Әгәр мин, мәсәлән, министр булсам, урынбасарсыз эшләр идем — барысына да үзем генә җавап бирер идем.

— Тирәннән уйлап караганда, синең сүзләрдә дә хаклык бар, малай, — дидем мин. — Ләкин бер үзең генә барысына да өлгермәс идең, хәлдән таяр идең...

— Хәлдән таярлык булгач, министр булмаска яисә башка җиңелрәк эшкә күчәргә кирәк. Менә минем урынбасарым юк, унбиш ел йөртәм инде машинаны, караучысы да, төзәтүчесе дә гел үзем. Станок артында эшләүче токарьның да урынбасары юк. Дөрес, ул станокны тәүлек буена да эшләтеп була, ләкин өч сменалы эш өчен өч токарь кирәк. Эше шулай бик күп һәм хәлдән дә таярлык булгач, ни өчен министрларның эш сәгате тәүлек буена дәвам итми? Шулай булганда, ичмасам, аларның берсен очратып булыр иде. Йомышың төшсә, берсен дә тотып булмый бит аларның. Болай гына әйтәм инде, миңа аларның берсе дә кирәкми. Кемгә генә кирәктер инде алар. Мәсәлән, безнең авылда берәүнең дә туганнан бирле министр күргәне юк. Элек тә, хәзер дә... Кем икәннәрен дә, исемнәрен дә белмибез — әллә бар алар безгә, әллә юк. Белсәк тә, онытып бетергән булыр идек. Элегрәк ит, сөт, балык промышленносте министрлыклары бар иде... Сыерың, кәҗәң булмаса, министр сине сөтле дә, итле дә итә алмый, балыгы турында инде әйтмим дә. Үзең тотсаң, ашыйсың, тота алмасаң, ашамыйсың. Диңгездә тоткан балыкны мичкәләргә тутырып, каядыр озату өчен дә министр кирәк түгел. Хәзер андый министрлыклар бетте бугай инде, ләкин безнең колак ишетмәгән әллә ниндиләрен дә уйлап чы... дылар бит! Инде, ярар, обо... министры булсын да ди. До... һөҗүменнән саклану яки су... башлау өчен андый минист... рәк, әлбәттә. Бер уйласаң, б... нистр тышкы эшләр белән, чи... эшләре белән дә шөгыль... алыр иде. Ә менә эчке э... өчен министр нигә кирәк? Э... эшләр, ил эчендәге эшләр, ... күп бит алар — барысына да ... нистр җиткереп буламыни? Б... нистрлыкның исеме үк дөрес ... гел, шуңа күрә эшнең нәтиҗәс... күренми. Хәер, нәтиҗәгә кил... мактап телгә алырлык мин... юктыр да. Шулай булгач, алар... барысын да, һич югында, уры... сарсыз эшләтеп карыйсы иде ... рма сизелер иде микән? Сиз... иде, агайне, бик сизелер иде.

— Синә тыңлап бара тор... Зиннәт, фикер әллә кайларга ... реп китте әле... — дидем ... яңадан тәмәке кабызып. — Б... раугa бер сүз белән генә җа... биреп булмас, әмма мин синә... рәхәтләнеп тыңладым. Кызы... фикерләр оялаган синең баш... күбесе күңелгә хуш килерлек ... рес уйлыйсың син. Идарә итү ... осталык та, белем дә, өлге... тә, сәләт тә таләп итә, идарә ... — чын сәнгать ул. Уңышсыз ... итү өчен яки көйгә салынган ... таркату өчен министр булу ... бүри түгел — моны кем дә б... дыра ала.

Ә инде урынбасарларны б... нче тәгәрмәчкә тиңләүгә ки... мин синең белән тулысынча ки... шәм. «Урынбасар» сүзе ми... үземә дә ошамый. Урынбаса... ны ничектер башкача исем... аларга төгәл һәм анык җава... лык йөклисе иде... Бәлки ул ... нәрне дә күрербез әле. Дәүләт а... паратын да, хөкүмәт органна... да камилләштерү турында сүз ... ри башлады бит. Бәлки нәкъ ... уйлаганча килеп чыгар әле, бер... көтик, көтик, туган.

Кечкенә музейның зур эшләре



Казанның Яңа Савин районында балалар һәм яшүсмерләрнең төбәкне өйрәнү, туризм һәм экскурсияләр үзәге бар. Ул 1991 елда район мәгариф бүлеге һәм район хакимияте тарафыннан балалар һәм яшүсмерләргә әхлакый, эстетик һәм физик тәрбия бирү максатында ачылган иде. Үзәк күзгә күренерлек файдалы эшләр башкарды да инде.

Быел 1 сентябрьдә шушы үзәктә татар әдәбияты музее ачылды. Тантанага язучыларыбыздан Р Мостафин, Г Рәхим, Г Садә һәм республикада нәшер ителә торган «Сабантуй» газете һәм «Ялкын» журналы мөхәррирләре дә килгән иде.

Кечкенә бер бүлмәгә сыйган бу музейның диварларында Г Тукай, М Җәлил, С Хәким, Ш Галиев, Ф Яруллин h б әдипләргә багышланган стендлар, язучыларыбызның Бөек Ватан сугышы чорындагы батырлыгын чагылдырган планшетлар, альбомнар куелган, алар зәвыклы итеп бизәлгән. Әдәбият музееның бер бүлеге тормыш юлы һәм иҗаты әдәбият сөючеләргә әлегә яхшы таныш булмаган шагыйрь һәм ж... рналист Шамил Гәрәйгә багышланган.

Музейның мөдире педагог Фәридә ханым ... лимова Шамил Гәрәйнең туганы да булып ч... ты. Ул музейны оештыру, төрледән-төрле ... спонатларны табу, булдыру, саклау буенча ... эш алып бара, моңа якындагы мәктәп укучы... рын да җәлеп итә. Әдәбият музее мак... балалары күңелендә татар әдәбияты, аның ... рихы, бүгенгесе белән кызыксыну уяту, ... ләребез иҗатын өйрәнү һәм пропаганда... максат итеп куйган. Шулай ук ул республ... дагы аерым әдипләрнең тәрҗемәи хәле ... иҗатына багышланган музейлар белән дә ... ләнешкә кергән.

Кечкенә музей зур максатлар белән яши...

Салисә ГӘРӘ...

Роберт ӘХМӘТҖАН

Көзгә кереш сүз

Эзләп тапты көзем бу якны да,
Һич тә онытмады.
Хушлаша Җәй, ак яулыклар болгап,
Агыла болытлары...

Хушлаша җир, яфракларын җилпеп,
Шаулаша юкәләр.
Көзге җиргә яфрак төшәп, бар да
Төялеп китәләр.

Сибелә яфрак эзләреңә, сары
Көзнең табышлары.
Кагыла җирнең җан җиренә, кагыла
Торна тавышлары!..

Сине уйлап мин дә чиртәм сазның
Көзге кылларына.
Авырттырма, җаныма тимә, көздәй
Чыкма юлларыма!

Көзге мәхәббәтем сиңа түгел — аны
Көзге урман тыңлар.
Сиңа түгел, бәгырем!
Сулыгып-сулыгып, моңы
Еракта бер тынар...

Сәяхәт башы

Илһам Шакирга

Без очраклы бер үк пароходтан.
Туган ярлар артта калды ла...
Калдырдыңмы онытып, җырчы дустым,
Фанер чемоданың Чаллыда?..

Кемнәр алды икән ул фәкыйрьне,
Шук малайдыр, кулы коргыры.
Кама суын ак пароход яра,
Сибелә йөзгә көзнең яңгыры.

«Гафури»* бу, яра Кама суын,
«Тукай» кебек ул да беркатлы.
«Шундый бәекләр дә кечкенә!» дип,
Бөтен пароходлар шаккатты.

Шатун-валы кыйный Идел сыртын,
Дулкыннарны кисеп юлында.
Төнне калтыратып гудок бирә,
Сыер мөгерәгәндәй болында.

Син, Казанга җитеп, җиңел генә
Чыктың ярга такта траптан.
Сиңа ул чак Казан, колач җәеп,
Бирмәде әле урын торактан.

Җыр илендә син салонда бүген,
Бар галәмгә җырың яңгырый.
Җырың тыңлыйм.Мин койрыкта һаман, —
Сибелә йөзгә хәтер яңгыры.

Җырчы дустым, ул чак Идел түгел,
Моңнар дәрьясын бит кичкәнсең!
Мин — койрыкта. Соңгы чалбар төбен
Умырып алды дегет мичкәсе.

Инвалидлар җырлый шул койрыкта,
Бер аяксыз тарта тальянны.
Бесплатный уты — ай яктырта...
И бәхетле чагы дөньяның!

Алга дәшә гомер офыклары,
Ак ялларын җилгә таратып,
Китеп югалды да... Әллә кайдан
Аваз бирә
Яңьылек-пароход!

Май, 1995 ел.

*** Элекке бер палубалы Агыйдел-Кама пароходлары.**

Тост

Агыйделнең аргы якларында
Бөке атып шаулый шешәләр!
Искә төшә
Күксел Тавридалар*,
Чал диңгезләр
искә төшәләр...

Аның да бит килде туган көне.
Килмәс димә,
Килер сиңа да.
Китер әле
Гомер подвалыннан
Кайнап торган
Тулы пыяла!

Искә алыйк дусның туган көнен,
Үч итеп бер көнче дошманга.
Берне тотыйк —
дусның саулыгына,
Икенчесен —
Күңел кушканга!

Өченчесен — кайгы дәмексенгә,
Дүртенчесен —
акча беткәнгә,
Бишенчесен —
чорлар чуар чакта
Тугры булып ярын коткәнгә!

Соңгысын да,барыбер, күтәрербез...
Саубуллашыр көннәр җиткәндә.

Июль, 1995.

*** Таврида — Кырым.**

Соңгы сурәтеңә

... Килде ул көн: сине энекәшеңнән
Чыгардылар ятлар чакыртып...
... Кияү белән кәләш утырган ат
Арт урамнан үтте
чаптыртып...

Озак йөрдем чатта, сагышлардан
Булмаганны җирдә таптыртып...
Карар өчен бер сурәтең калды...
Аны да алды яшен...
яктыртып!

1992.

Кысыр болыт

И йөрде болытлар күктә,
Аунатып утлы шарын.
Искәртеп, гүя, Ходайның
Шифалы яңгырларын!

Шулкадәр күкрәп йөрделәр,
Селкенде җирләр хәтта!
Нигә күкрәргә, — туфракка
Бер тамчы төшмәс чакта?!

Китте җил, җыеп күкләрдән
Алды да болытларын,
Көтүче чыбыркысыдай
Яшьнәтеп офыкларын.

И, күкләр вәгъдә иткәнен
Кайларга илтеп коя?!
Ә монда... тамчыга сусап,
Ымсынып калды дөнья!..

Мин дә кайчак юкка шаулыйм, —
Бер кысыр болыт, гүя...

Август, 1995.

Дифирамб

Ш.Г.

Татар бугазына
Килеп керде кашык.
Гомерем буйларына
Мин кашыкка гашыйк.

Суына бит боткаң —
Аша, шагыйрь, ашык.
Татар бугазында
Бер кораб ул кашык!

«Инде нишләргә», дип,
Торма башың кашып;
Суына бит фикерең,
Ашык, шагыйрь, ашык.

Бир миңа да кашык,
Әйдә, бергә ашыйк.
Килеп керде ашыгып
Зур кашыклы Гашыйк!..

Татар бугазыннан
Гибралтарга чаклы
Шаулый җанда нәфес —
Нәфес — безнең яклы!

Август, 1995.

* * *

Якшәмбе көн. Шәһәр палас кага
Ишегалларында — шап та шоп!
Тормыш бара! Тупыл ботагында
Ала карга утыра шаккатып!

Бара тормыш! Искән җилдәй шаулап,
Тели һәркем аннан калмаска,
Безне дә бит шап-шоп кага Тормыш,
Әйләнгәнче иске паласка!

1994.

Бүгенге бишек җыры

Йокла, җаным, җан йолдызым,
Яктырып йокла —
Бишегең янында әле
Җаһилләр юк ла,
Елмаеп йокла!

Бер чебен генә куарлык
Кодрәт бар бездә.
Койрыгы белән кигәвен
Куа үгез дә...
Йоклый бит бишек янында
Әтиегез дә.

Йокла, уяу булып йокла,
Уянгач йокла.
Йоклагач уян, елмай да,
Елаудан тукта.

Төшеңә керсен йолдызлар,
Сызылып, янып;
Куансыннар Ай яныннан
Үз тиңен танып.

Йокласын тирәктә кошлар,
Суында балык...
Ватан бишеге янында
Йокламый Халык!

Август, 1995.

Аның тавышын сихри дип әйтүләрен, бәрхет белән чагыштырганнарын ишеткәнем бар. Ә менә минем үземә Айдарның җырлавы күңелне назлап исүче иртәнге йомшак таң җилен хәтерләтә. Ул җил синең җаныңны иркәли, күңелеңә рәхәтлек бирә. Башкортстанның танылган җырчысы Айдар Галимовның шушы сихри, бәрхет кебек, салмак, талгын, таң җиледәй тавышы Казан тамашачыларын әсир итте дә инде. Аның концертларында, кем әйтмешли, алма төшәрлек урын калмавы да шушы хакта сөйли булса кирәк. Октябрь аенда Айдар Галимовның мәркәзебезгә концертлар белән килүе турындагы хәбәр шуңа күрә дә җыр, музыка сөючеләрнең йөрәгенә сары май булып ятты.

Ә бер көнне җырчы көтмәгәндә редакциябезгә үзе килеп керде.

Айдар ГАЛИМОВ:

«МИНЕМ ҖЫРЛАРЫМ — САГЫШ, МОҢ ҺӘМ СӨЮ ТУРЫНДА»

— Айдар, Казан тамашачылары сине үз итеп өлгергән кебек, син үзең дә мәркәзебез, республикабыз тамашачыларын яраттың кебек...

— Казан тамашачылары эстраданы дәррәү дип әйтерлек күтәреп алдылар. Татарстан халкы эстрададагы дәртне, күтәренкелекне ярата, җырчыларны, гомумән, сәнгать кешеләрен ихтирам итә. Казанда җырчылар һәм, әйтергә кирәк, көчле, моңлы, матур тавышлы җырчылар, күп булуына карамастан, мине — Башкортстанда туып-үскән, яшәгән җырчыны да якын итә алдылар. Алай гына да түгел, «Үзебезнең Айдар» дип кабул иттеләр кебек. Аларның миңа булган мондый җылы мөнәсәбәте өчен рәхмәтемне җырларымда җиткерергә омтылам.

Билгеле, ихтирам, мәхәббәт ике яклы була. Әгәр тамашачыга хөрмәтең булмаса, ул синә берничек тә кабул итә алмый. Мин үзем дә Казан тамашачысы янына сөенеп, куанып киләм. Башкортстан татарларының казанлылар белән элемтәләре ныгый баруына шатланып. дусларым янына ашкынып киләм.

— Дусларым дисең...

— Әйе. әйе! Минем Татарстанда дусларым артканнан-арта бара. Миңгол Галиев белән исә дуслыгыбызга шактый еллар. Армиядән кайткан гына чагым. Башкортстанда Татарстан көннәре гөрли. Минем туган авылым Олы Кәркәләгә дә татар сәнгать эшлеклеләренең бер делегациясе килде. Анда Миңгол Галиев тә бар иде. Авыл халкы татарстанлыларны шатланып каршы алды. Миңгол Галиевнең җырлавын бик тә ошаттылар. Шушы очрашуда мин дә җырладым. Миңгол абый шунда миңа игътибар иткән икән. сөйләшеп, танышып, дуслашып ук киттек. Мин аны автобуста Миякәгә озата бардым. Шунда ул миңа «Айдар, син сәнгать юлыннан китсәң, әйбәт булыр иде. Сине зур сәхнәдә күрәсем килә». — диде. Бу сүзләр күңелемә нык уелып калды һәм алар сәхнәгә чыккан саен хәтеремдә яңаралар. Миңгол абый белән без әле дә дуслар. Очрашып торабыз. Аңардан музыка буенча дәресләр алуымны дәвам итәм. Миңгол абый — беренче киңәшчем дә, олы юлга фатиха биреп озатучым да. Безнең очрашуыбыз тәкъдирдән булгандыр. дип уйлыйм.

— Айдар, син журналистлар белән булган бер әңгәмәңдә моң ата-бабаларыбыз туган авыл туфрагында, кешеләр күңеленә сеңгән йөрәк тавышында саклана, дигән идең. Сиңа моң биргән «туфрак», «йөрәк тавышы» турында гәпләшеп алыйк әле.

— Мин Башкортстанның татарлар күп яши торган Олы Кәркәле авылында туып-үстем. Татар-башкорт халкының йөрәк ярасы бик тирән һәм күптәнге. Шушы төзәлмәс җәрәхәт авыр тормыш безнең борынгы ата-бабаларыбыз җырына үз эзен салган күрәсең. Халкыбыз җырлары бик тә моңлы, сагышлы безнең. Мин менә шул җырлар белән, йөрәкләргә әрнүле ата-бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләр, кануннар аша тәрбияләндем. Еллар узган саен ата-бабаларыбыздан килгән моң, сагыш минем җаныма тирәнрәк үтеп керә барды.

Михнәт дигәнен дә безнең картәти, картинәйләребезгә, әти-әниләребезгә. авылымның өлкән яшьтәге кешеләренә. бүгенге ветераннарга капчыклап кына түгел, олаулап татырга туры килгән. Бөек Ватан сугышы биргән ачы хәсрәт авылымның һәр өенә диярлек кергән. Җырлаганда боларның барысы да минем йөрәгем аша үтә кебек. Юк, бирәдә «минем» дип кенә әйтү дә дөрес булмас. Авылыбызда җырга-моңга тартылучылар күп безнең. Элек-электән бездә концерт куярга читтән артистлар чакыру гадәте булмады. Гармунчысы да, җырчысы да үзебездә иде. Хәзер дә мәктәптә укучылар арасында әйбәт җырчы чыгардай кызлар-малайлар күп.

— Димәк, халкыбызның үткәне, моңы буыннан-буынга түкми-чәчми тапшырылып килә. Гаиләгә, боларның барысы да безгә әти-әниләребездән, безнең бишек җырлары, аларның гадәти тормышы, яшәеше аша да килеп ирешә бит...

— Билгеле, шулай. Минем әтием гади бер авыл кешесе, шофер булып эшләде. Кичен өйгә кайткач, көннәр буе юл йомгагын сүтә-сүтә, кешеләр белән аралашып күңеленә тулган хисләрен гармун телләренә күчерә иде. Гармунда җилкенеп-җилкенеп, кешеләр күңелен дәртләндереп, җидерен уйный, кешеләр күңелен дәртләндереп, җиңел бии торган кеше ул.

Әнием исә — бик нечкә күңелле, әзлекле кеше. Беркайчан да кешегә күтәрелеп бәрелмәс, сүзен җайлап, иплән, әмма дөресен әйтер. Ул дөреслек

Айдар Галимов Башкортстанның Миякә районы, Олы Кәркәле авылында туып-үсә. Кечкенәдән үк сәнгать, әдәбият белән кызыксына, шигырьләр язу белән мавыга. Табигать биргән моң, тавыш барыбер үзенекен итә: Айдар Галимов җырчы булып китә.

нең күзенә карап яшәде һәм яши. һәрвакыт хаклык ягында булды. хакыйкать яратуы башка. чит кешеләргә карата гына түгел иде аның. үзенә. гаиләсенә. туганнарына карата да гадел булды. безнең дә шундый булып үсүебезне теләде. Дөреслек үзенә кыенлыклар китереп чыгарырга мөмкин булганда да ул беркайчан да аңардан качарга омтылмады. Әнием 35 ел буе мәктәптә укытты. Укучыларының бер генә тапкыр да — дөрес. бу хакта сүз дә булырга мөмкин түгел — әнием турында кечкенә генә өнәмәү сүзе әйткәннәрен дә ишеткәнем юк. Боларны яңгыравык сүзләр дип кенә аңламагыз. Ул чын-чынлап әйбәт укытучы булды. Әнием. үзе турында да онытып. бөтен көчен, йөрәк җылысын балаларга биреп яшәде. аларның сөенечен дә, көенечен дә үзенеке итте.

— Үз авылың. туган-үскән йортың ераккарак киткән саен кадерлерәк була бара шул. Җырда да:

«Сагынырсың, саргаерсың,
Читләргә китеп кара»,

— диләр бит.

— Безнең якның табигате. дөрестән дә, бик матур, үзенчәлекле. Быел миңа Эквадорда булырга туры килде. Сүз дә юк, табигате гаять күркәм, әмма барыбер безнең якларга җитми. Без шулкадәр әйбәт урында урнашканбыз. Бирәдә кышы да, язы да, көзе дә. җәе дә бар. Боларның барысы да кирәк

икән бит. Һәркайсының үз матурлыгы, үз моң...
икән.

— Синең авылдашың, минем шәриктәшем, жур...налист Флера Хәлимова да үзе язган бер җыр...да:

«Йөрәк җырларымда,
Маңгай сырларымда,
Саф мәхәббәт эзе бар сыман»,

— дип язган иде...

— Әйе, әчке дөньяң җырга чыкмый кал... Йөрәгеңдә, уеңда булмаса, аны башкаларга ... керерлек итеп җырлау да мөмкин түгел. Җырла...чакта нинди милләттән булуым да, ата-бабага... да, әлеге дә баягы табигать тә, гаиләм дә, кы... Гүзәл дә күз алдыннан уза.

— Димәк, син җырга тавыштан бигрәк хис с...лырга тырышасың?

— Кайбер кешеләр, җырчы көчле тавышлы б...лырга тиеш, дип исәплиләр. Мин башкачарак ф...рдә торам. Салмак тавыш белән дә тамашачы ...рәгенә барып җитәргә мөмкин. Аннары кешене... ңелен ничек яулыйсың бит. Йөрәктән нәрсәдер ...реп кенә тамашачы күңелендә хис, давыл уяту... кем әйтмешли, бөтен җанын актарып ташлага... итәргә мөмкин. Җырлаганда сүзләргә, көйгә ми... үземнең дә хисләрем кушылгандай, рухым ... гәндәй була. Инде җырым белән тамашачыда ... дидер образ тудыра алам икән, димәк, мин кеше...рга барып җитәм, дигән сүз.

— Узган ел Казанда синең концертың барга... бер ир-егет, хисләнеп китеп, тамаша залына... балконнан да егылып төшкән иде бугай...

— Әйе, андый хәл булды. Ул егетне би... күрәсем, аның белән очрашасым килә. Без ... эзлибез, әмма таба алмыйбыз. Ул безнең конц...ларга килсен, безне күрсен иде.

— Бу хәл тамашачыларның синең җырлавы...ны бирелеп, онытылып тыңлавы турында да с...ли бит. Кешеләргә шулай дөньяларын онытыр... итеп җыр тыңлата алу зур осталык, әзерлек ... сорыйдыр?

— Мин бу очракта, иң тәүдә үзеңдә җаваплы... хисе булу кирәк, дип әйтер идем. Менә шул ... тамашачы хакына, исемең хакына, ихтыяр көче... туплап, үзеңне күп нәрсәләрдән чикләргә, ф... яктан сәламәт тотарга кирәк. Сәхнәгә чыкка... бөтен ару-талуларыңны онытырга, күңелсезлек... реңне эчкә яшерергә, авыр уйларыңны, хәл ит...мәгән мәсьәләләреңне читкә куеп торырга ту... килә.

— Соңгы биш ел синең файдага эшләде ши...ле, син үзеңне татар халкына танытып та өлгер...дең. Ә үзең бу хакта ничегрәк уйлыйсың?

— Әй. соңгы елларда. чыннан да. үз-үземә ы... ныч барлыкка килде. максат куеп яши башла... Ул тормышта ныклап басып торырга көч би... үземнең бу дөньяда кирәклегемә ышаныч, гом...нең заяга узмаячагына өмет тудырды.

— Соңгы вакытта нинди җырларны яратып ... тып башкарасың?

— Әйтеп үткәнемчә, күңелеңә якын булма... тоткан кыйблаңа, яшәешеңә туры килмәгән, с... ләре җаныңа ятмаган җырны җырлап булмый. - Соңгы вакытта Зөлфәт Хәкимнең җырла... яратып башкарам. «Нәрсә булды сиңа бүген?», «Т...нгә сәяхәт» җырлары бик ошый. Күңелемә С... апа Садыйкованың «Беренче мәхәббәт», «Чит ...ләргә чыксаң» җырлары да якын. «Хәтер» (Ве... Илембаев шигыре. Роберт Тимербаев көе), «И... ем» (халык җыры) һәрвакыт күңел түрендә.

— Бу гастрольләреңдә Казан тамашачыс... ни-нәрсә белән сөендерергә ниятлисең?

— Быел безнең иҗат коллективы беркад... ишәйде. Башкортстан җиреннән килгәч, үзебез... туган якларны да күрсәтергә тырыштык. Җырлар... бызның яртысыннан күбрәген яңарттык. Лекин ... гә бөтенесен дә сөйләп бетерергә ярамас. Тама... чылар өчен башка төмле күчтәнәчләр дә әзер... дек.

Әңгәмәне Сөембикә КАШАПОВА оештырды.

«Мәдәни җомга»ның укучыларына тыныч, тигез тормыш телим! Сезне ихтирам итеп, яратып Айдар Галимов

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар

Әхсән БАЯН

Лирик товар күпме тора?

Бер карасаң, бүгенге шигърият заман афәтләрено бирешмәде кебек. Тезмә әсәрләрнең саны һич тә кимемәде, ә бәлки арта гына төштә Газета һәм журналлар күбәйде Элек бер журнал, ике-өч газетада гына басыла килгән шигырь хәзер дистәләрчә газета һәм журнал битләрендә тулып-тулып чыга.

Эшләребез ал да гөл дияргә җай бардыр, зарланырга урын юктыр шикелле. Өстән-өстән генә карасаң, мәгънәләргә, төсләргә, яңгырашларга игътибар итмәсәң, чынлап та, борчылмыйча гына яши бир.

Ә менә без борчылабыз һәм кемнәрнеңдер илаһи тынычлыгын бозарга җөрьәт итәбез. Бер дә сәбәпсезме?

Иң беренче сәбәп — тормышта шигырьнең кирәклек дәрәҗәсе. Гаҗәбрәк фикер, шулай бит? Ләкин кара син бүгенге хәлләргә — шигырь кайгысымы бәндәләрдә?! Кемдер җан-фәрманга капитал каера, байлык туплый. Юк бәягә дәүләт мөлкәтен үзенеке итә, «приватизацияли» Кемдер тормышның хәлиткеч позицияләрен кулдан ычкындырмаска, икенчеләре аны тартып алырга тырыша.

Җимереп кору чорына хәтле булган заманнарда кешенең кеше өстеннән хакимлек итүе кебек тискәре омтылышына аннан да түбәнрәк комсызлык тойгысы гөрелеп өстәлде. һәм аңа алдау талау, хәтта үтерүдән тайчанмаган ерткычлык инстинкты кушылды. Чорның төп галәмәте шундый. Меңнәрчә, миллионнарча адәмнәр кара хисләрдә кайнаша. Аларга әллә шигырь кирәкме?

Кешелекләрен югалтмаган, җитештерүчән хезмәттән аерылмаган адәмнәрнең уй-омтылышлары тормыш төбенә батмас өчен авыр көрәшләрдә сарыф ителә Айлар буе хезмәт хакы алмаган. мәҗбүри ялга җибәрелгән кеше нишләсен? Билгеле инде. аның уенда иң беренче максат — «очны очка ялгау».

Шушындый гайре табигый шартларда күп кеше әле дә бирешми Бигрәк тә авыл кешесе. Чын мәгънәсендә каһарманнарча көрәшә ул. Үзен төрлечә кимсетергә азапланган кала кешеләрен дә ризыктан өзми Рухи тормыштан да ваз кичмәскә көч таба. Ләкин ярым бөлгенлек хәлендә аның газета-журналларга язылырга. китаплар сатып алырга мөмкинлеге бик тә аз калды шул

Мәдәниятне бар итүче зыялылар... Асылда болар — «бюджетник»лар. Иң түбән хезмәт хакы алучылар Банк хезмәткәрләре кебек, миллионнар белән түгел, меңнәр белән генә исәпләнә аларның керемнәре Әлеге дә баягы, аларның да көндәлек мәшәкатьләре кара дәрьяга батмау өчен көрәш ысуллары эзләүгә кайтып кала.

Әдәбиятның тагын бер таянычы булган олы яшьтәге иманлы затлар, пенсионерлар һәм студентлар. укучыларга килгәндә. аларның бөтен керемнәре ике-өч китап алырга җитәр иде дә, мәгәр яшисе, җан саклау кебек проза ихтыяҗы бар.

Шушы хәлләрне күз алдыннан кичерсәң, әдәбиятның, аерып алганда, шигъриятнең ни дәрәҗәдә кирәклеге яхшы ук аңлашылса кирәк. Базар холкы билгеле сорау булмадымы, товар узмый, узмаган товар җитештерелми.

Шулай да, әйткәнебезчә, нихәтле гаҗәп тоелмасын, шигырьләр әлегә языла тора бит. Ельцин акчалары санынча ук булмаса да, тезмә әсәрләр күпләп һәм күпләп басыла һәм үзенчә инфляция хәле тудыра. Нинди шигырьләр соң алар? Менә шушы сорау башка китереп суккач, айнып киткәндәй булабыз.

Чыннан да, нинди шигырьләр һәм алар нәрсә хакында?

Тематикада күптәннән килгән традициянең дәвамы буларак, авылны сагыну һәм кайта алмыйча газап чигү өстенлек итә. Табигый хәл бит, француз әйтеме хаклыгын җуймый: шагыйрьләр авылда туа, шәһәрдә вафат була. Беркемгә дә, ник авылны сагынасың, дип булмый Сагына бир, рәхим ит. Яза бирү дә гаеп түгел, әмма язганың моңарчы булганнарга яңалык өстәсә Югыйсә, аның булу-булмавыннан аерма юк дияргә туры килә Бездә исә яңалык өстәлмәү генә түгел, ә булганны сан-исәпсез кабатлау һәм темадан гайрәт чигүгә генә китерә торган «сагынулар» тоташ бер агым булып ургыла бирә Авылның үзе, бүгенге авыл кешесенең рухи яшәеше, гүяки, сәнгатькә бирелми.

Икенче төп тема — ул әниләрне сагыну. Монысы да культ дәрәҗәсендә Кабул итәргә мөмкин булган бердәнбер культ дияр идем. Ләкин бит баягы хәл — сагыну һәм кайтырга ашкыну газаплары Шул хәтле сагынгач, кайт та кит инде Юк, кайтырга тырышу дигәннәре әллә шагыйранә ялган, әллә чын ялган Икесен дә фаразларга мөмкин Әмма бу җәһәттән дә хак сәнгать сүзе ишетелми диярлек Бихисап вариантлар ташкынында батмыйча кала килгән берничә шигырь һәм өч-дүрт җыр тексты бар Аларына шөкер

Модалар була тора, алда да булырлар. Ләкин шушындый да изге темаларга булган модаларны кабул итү кыен.

Мәхәббәт темасына — тагын да күбрәк күләмдә агыла торган язмаларга карата да шушы ук сүзләрне генә әйтә алам.

Моннан кала, шулай ук доминанта ролен үтәгән тема — халык язмышы, аның бәйсезлеге, тарихи хокуклары хакында кайгырту

— соңгы елларда рәсми югарылыкка күтәрелеп, иң актив рәвештә дәвам итә. Сәнгатьчә яңалык китергән әсәрләр язылмады түгел. Уңышлар киләчәктә булыр дип өметләнәбез. Ләкин ботенләй үк тынычланырга да җай юктыр Киресенчә, борчылырга мәҗбүр иткән мисаллар байтак дияргә туры килә.

Элеккерәк чорларда мәдәни көнкүрештә декламация дип аталган шигырьләр киң таралган иде. Ачыктан-ачык чакыру сүзе, «законлы яшәеш» алган жанр. Төп эчтәлек — җитәкчелектәге сәясәтне яклау Агитация Тора-бара бу атама үзгәреп, аны публицистика дигән икенче бер төшенчә алмаштырды. Максаты шул ук калды — коммунистик идеологияне зурлау Ул иң абруй-дәрәҗәле, бүләкле, отышлы жанр иде. Тормыш күрсәтә килгәнчә, яшәүчән дә икән. Иҗтимагый корылыш үзгәрүгә, тоткан мәсләк алмашынуга карамастан, ул үзгәртеп кору чорында да үз хасиятен саклап калды. Элеккесе формасы белән милли, эчтәлеге белән социалистик булса, хәзергесе аның гомуми формасы белән интернациональ, эчтәлеге белән милли рәвешкә килде..

Декламация, сәяси һөҗүмчәнлегенә карамастан, сәнгатькә мөнәсәбәттә тыйнак иде. Ул, агитация чараларының бер төре буларак, югары поэзия вазифасына дәгъва кылмады. Ә менә аның урынына килгән публицистик шигырь исә чын поэзия янында үзен тиң санап кына калмыйча, аны хәтта кимсетә башлады.

Үзебезнең дә гадәткә кергән инде, публицистик шигырь, дибез. Икенче төрле әйткәндә, «тозлы» бал... Әлбәттә, публицистик сүзнең үз хокуклары бар Әгәр дә башкалар урынын басып алырга тырышмаса

Совет чорында шулай иде. хәзерге «буржуаз диктатура» чорында да бер төслерәк булып калды Әле кайчан гына «Яшәсен партия! » — дип җырлаган шагыйрьләр (әлбәттә исәннәр хакында гына бара сүз) хәзер исә «Яшәсен демократия яшәсен милләт!» — дип такрарлый Ләкин, әйткәнебезчә болларның югары поэзиягә (Аристотель үк билгеләгән матурлык төшенчәсенә) мөнәсәбәте бик тә чамалы

Поэзия — күңел чагылышы. җан сурәте. тойгылар яшәеше Поэзия минем рухи дөньямны күрсәтеп бирә Күңел — галәмнең үзе кебек, чиксез Нурлар спектры — хисләр гаммасы Гражданлык тойгылары. интим хисләр Алар кешеләрнең үзләренә хас дәрәҗәдә Байлыгы да, фәкыйрьлеге дә Лирик әсәрдә авторның үз җаны гәүдәләнә Ә син үзең кем? Әгәр синең җаның буш булса?! Анда чагылдырыр матурлык булмаса?!

Кемдер, кемнәрдер (алар хәтта күптер) юкны чагылдырырга, күрсәтергә тырыша Уйлап чыгарырга омтыла Ләкин үзең татып карамаган төмне тасвирлау җайсыз Поэзиядәге барлык тискәре хәлләрнең башы әнә шунда һөнәрчелек, бизнесменлык, теләсә кемнән алып, теләсә кайдан җыеп язу шуннан. Газета вазифаларына гына җавап биргән публицистиканың сәнгатькә дәгъвасы шуннан. Күңел эше, тойгы хәрәкәте белән бәйләнешә булмаган көн темалары — шулай ук чиксез. Алар хакында язмалар чиксез. Әмма алар поэзия түгелләр.

«Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән», — диләр дә бит Әмма поэзия сүз генә түгел шул Җор, үткен фикер генә түгел Поэзия — сәнгатьле сүз. Тирән моң, музыка белән сугарылган сәнгать. Ритмлы аһәң, яңгырашлы хисләр.

Әлбәттә, сүзләр стихиясе булып калган поэзия тавыш сәнгате белән генә чикләнә дип нәтиҗә ясарга ашыкмыйк. Ул яңгырашлы сүзләр аша мәгънәгә ирешә, мәгънә аша психикага тәэсир итә Башка жанрлар шикелле үк, аның да максаты — тасвирлаудан һәм шул рәвешле аңлатудан гыйбарәт Тойгылы аһәң, сурәтле мәгънә синтезыннан гыйбарәт булган әсәр укучы, тыңлаучы күңеленә тәэсир итеп, анда матурлык ләззәте тудыра. Сәнгать дәрәҗәсенә күтәрелмәгән сүзләр мондый таләпкә җавап бирә алмый.

Остазыбыз Сибгат ага Хәким, үзе сәяси темаларга байтак әсәрләрен багышлауга карамастан, көн хаҗәтләреннән узмаган шигырьләрне «упшый шигырьләр» дип атый иде. Шундый «упшыйлар». һич тартынмыйча, киң мәйданга әле дә чыга торалар.

Хәзер төп мәйдан — эстрада. Гәрчә моның белән килешү кыен. Чын шигырь — рухи тормыш белән яшәүче кешенең якын сердәше. Ул аның белән икәүдән-икәү калып сөйләшергә, киңәшергә, аңлашырга мөмкин. Шигырь, бигрәк тә аның лирика дигән төре — безнең интим дустыбыз. Ә интим хисләрне сәхнәгә чыгып кычкыру килешә торган нәрсәмени?

Шигырьләр инерция буенча языла тора. Һәр автор үз хезмәтен кулга тотарлык хәлдә, китап рәвешендә күрергә тели. Совет власте чорында мондый мөмкинлек бар иде. Ләкин базар өчен шигырь — сөйкемсез кош. Ит тә юк, мамык та юк аңардан Алайса нишләргә — таралып яткан әсәрләрне ничек итеп халыкка бөтен рәвештә күрсәтергә?

Хәзер бер генә диярлек ачык юл калды — эстрада. Менә ни сәбәпле кайберәүләр сәхнәгә омтыла. Китапларны сәхнә алыштыра башлады. Чор галәмәте!

Бу очракта бөрчә микъдарда шигырь җыр текстлары рәвешенә керсә, үз рәвешендә калганы исә халык алдына көйләр агымына ияреп чыга. Арада әйбәтләре дә күренгәли. Ләкин күпчелеге — икенчел әсәрләр. Алар, нигездә, интим хисләргә, мәхәббәт темаларына багышланган булырлар. Мәгәр чынлыкта мондый әсәрләрдә мәхәббәт кичерешләренең үзләре түгел,ә алар хакында «упшый» сөйләүләр өстенлек ала.

(Ахыры 10 нче биттә).

Әхсән БАЯН

Лирик товар күпме тора?

(Ахыры. Башы 9 нче биттә).

Сурәтсез риториканың сәнгатькә якын тормавы хәзерге дәвердә шагыйрьләргә генә түгел, барча шигырь сөючеләргә мәгълүм. Шул сәбәп беләндер, шигърияттә янә бер культ — метафора культы урнашты. М.Лермонтовның «Васыять», Ф.Кәримнең «Сибәли дә сибәли» исемле шигырьләре кебек үтә дә гади (әмма даһи) әсәрләрне соңгы елларда очрата алмассың. Бу күренеш, гомумән, шигырь техникасының үсеш дәрәҗәсенә бәйле. Әгәр әсәрләрне шушы җәһәттән тикшерә башласаң, тулаем алганда, үсешнең гарип яклары күзгә күбрәк ташлана. Нинди сурәт,нинди метафора бит. Фикер һәм тойгының үзләреннән килеп чыгамы-юкмы, мәҗбүрияте бармы-юкмы — уйлап тору юк. Бигрәк тә без эстрада шигырьләре дип атаган әсәрләр шундый күперенке, ясалма бизәкләрдән гыйбарәт булыр.

Гомуми шаукымга бирелү аркасында бугай, акланмаган, җирлексез метафораларны танылган шагыйрьләр иҗатыннан да күпләп табарга мөмкин. Бәлки монысы да базар галәмәтедер. Алдамасаң, сата алмассың. Миннән киткәнче, иясенә җиткәнче. Кабул гына итә күрсеннәр. Ә кабул итүчеләр бар... Тагын ни кирәк? Шулай бит?

Бәгъзе тәнкыйтьчеләр кайбер шагыйрьләрне метафоралар күплеге өчен үтә дә «үтереп» мактагач, шул әсәрләрне яңадан укып караган идем. Ни күрдем? Метафоралар сәбәпсезлекне, эчтәлексезлекне каплап калдыру чарасы гына икән ләбаса. Язганга чаклы чын кичерешләрең, уйлануларың булмаса, хәтта яңа табылган, ачыш дәрәҗәсендәге метафоралар да сиңа ярдәм итә алмыйлар икән.

Башлангыч мәктәпләрдән үк беләбез ки, тәмамланган уйны белдерүче сүз яки сүзләр төркеме җөмлә дип атала. Мәгънә белдермәгән сүзләр җөмлә була алмый димәк. Ә менә тәмамланган бер генә уйны да белдермәүче бихисап шигырьләр, шигырьлеккә дәгъва кылган тезмәләр газета һәм журнал битләрен тутыра, эстрададан рәхәтләнеп кычкыра, бии, шамакайлана.

Бер карасаң, базар мәҗбүр иткәч, китап чыкмагач, автор сәхнәгә менми нишләсен. Эстрада, бу очракта, китапның суррогаты. Икенче карасаң, байтак укучының рухи мөмкинлекләре шундый китап укырга әйткәнебезчә, берәүләрнең вакыты, икенчеләрнең тәләге, өченчеләрнең аңларга хәле чамалы. Шигырь китапларының яңалары юк, искеләрен эзләп уку — күпләр өчен онытылган гадәт. Чын шигырьләрне радио яки телевидение аша (чәйнәп каптырганны йотып җибәрер өчен) бәлки тыңлап та карар иде әле, мәгәр анда да еш кына очракларда бик тә сай мәгънәле әсәрләр яңгырый шул. Мәгънә эзләсә аңларга тырышса да таба алмагач, анысына да кул селтәп, көнкүреш мәшәкатьләренә чума кеше.

Ярый әле, хәзергә аның театрларга, концертларга йөрү теләге кала бирә. Монда ул, аңлар-аңламас килеш булса да, чама белән тоеп, күңел ача. Моның өчен дә рәхмәт аңа. Әмма ни кызганыч, залда утыручыларның күбесе, әлбәттә, китап укымый һәм укымаячаклар да...

Бу кичәләрнең бер мәгънәсе китапны алмаштыру булса, икенчесе — базар шаукымы, бизнес. Анда, сәнгатьтән бигрәк, сату-алу, спонсорлык исеме алган шикле шөгыль шаккатыргыч бүләкләр, ачы-төче мактаулар вә бүтән төр ыгы-зыгы. Тагын да аянычрагы шул: бу гамәл, бу омтылыш көчәя һәм ныклап законлаша бармакчы.

Кемнәргәдер юаныч. Әмма ул юаныч озын гомерле була алмастыр шул. Кислород мендәре ярдәменә калгач, нинди тантаналарга исәп тотарга кала инде. Бәлки чираттагы беркатлылык белән шулай уйларга җөрьәт итәмдер, шигырьләрне укучыларыбыз китаплардан эзләп һәм табып укыса икән.

Мәгәр тормышта икенчерәк шул, күңел таләбен канәгатьләндерү өчен укучылар даирәсе тарая бара. Шигырь хакында сөйләшү, күзәтүемчә, инде бик тә сирәк хәл. Сүз була калганда да, гадәти көнкүрешкә хас фикерләр генә әйтелә, ә шигъри идея, шигъри аһәң, шигъри моң уйга да керми.

Укучыны гына гаепләсәк, хаклы була алмабыз. Аның мөмкинлекләрен без алда барладык бит инде. Өстәп әйткәндә, ул, еллар буе дигәндәй, йөзләрчә, меңнәрчә ясалма эшләнмәләр тыңларга күнеккән, һәм моңа шагыйрьләр үзләре дә булышлык иткән, үзләре дә җиңел һөнәргә, шигъриятсезлеккә иялләшеп өлгергән. Шул рәвешле, очлар тоташып, бөтен түгәрәк хасил иткән.

Соңгы вакытта хәтта күренекле шагыйрьләр иҗатында да шактый түбән дәрәҗәдәге кизү шәлкемнәр күзгә ташлана тора. Аларны нинди дә булса сүз әйтү өчен түгел, ә бәлки укучы күзенә күренә тору өчен генә тәкъдим итәләр диярсең. Көндәлек матбугат битләрендә урын алу — әгәр портрет белән булса, бигрәк тә күңелле — максатлар шуннан артмый кебек. Кешенең әйтер сүзе юк. Әйтер сүзе булса, поэзиясе булмый...

Чын оста, кагыйдә буларак, үз талантына хыянәт итә алмый, әлбәттә. Ләкин кагыйдәдән чыгармалар була бит. Хәзер шаукымга иярмәгән осталар бармак төртеп санарлык кына. Укучылар арасында, әйткәнебезчә, чын сәнгатьне һөнәрчелектән, ялган бизәкләрдән, икенчел әсәрләрдән, хәтта плагиаттан аера белүчеләр шулай ук күп түгел. Хәтта укучыны яманнан яхшыны аера белергә өйрәтергә тиешле тәнкыйтьчеләрнең үз араларында да, поэзияне бәлки аңлаган хәлдә дә аны чын-чынлап тоючылары сирәк. Бәйнә-бәйнә шигырьнең эчтәлеген сөйли тәнкыйтьчеләр. Әсәрнең җаны, моңы, аһәңе читтә кала.

Шунысын да әйтик: моң сөйләүгә бирелми. Тәнкыйтьчеләргә тулаем үпкәләү җайсыз. Минем аларга дәгъвам бер генә: яхшыны-яманны субъективлыкка бирелмичә генә күрсәтә торсыннар иде. Бу теләгем — элек-электән килгән чир — кыргый базар чорында җирдән бөтенләй аерылган хыялдыр. Әйе, бизнесчы авторлар булганда, нишләп инде бизнеска бирелгән тәнкыйтьчеләр булмасын ди!

Әдәби хәрәкәттәге тулаем картинаны ачыклау һәм андагы тенденцияләргә уңай юнәлеш бирү максатында (һәрхәлдә, аның төп идеясе шуннан гыйбарәт) язучыларның ел саен гомуми җыелышлары үткәрелә. Ләкин анда да куелган максатка ирешү элек-электән бәхәсле килеш кала бирә иде, ә соңгы елларда исә субъективлык аеруча ныгып урнашты. Бигрәк тә поэзиягә мөнәсәбәттә. Иҗат ителгән барлык әсәрләрне күздән кичереп, бәя бирү, уңай омтылышларга ярдәм итү, ә тискәреләрен бетерү киметүгә булышу урынына, доклад тикле докладка алынган кеше, үзенең көндәлек тормышында аралашып, өшнәләшеп өлгергән, яисә нинди дә булса йомышы төшәрдәй, җитәкчерәк урында утырган дус-ишләр даирәсеннән чыга алмыйча, вак-төяк уңышларны күпертеп, зурларын күрмичә, калын катламнарны ермачлап чыккач, зур эш бетергәндәй, сәхнәдән колакларынача елмаеп төшә. Кемнәрдер аның кулын кысарга да онытмас, җилкәләреннән сыйпар...

Әйтерсең, татар поэзиясенең традициясе бүген башлана, бүгенге уңышлар (күбесенчә кечкенә уңышлар) тарихи үсеш нәтиҗәсе буларак түгел, ә кемнәрнеңдер зур таланты нәтиҗәсендә килеп чыккан. Ә кайда буыннар бәйләнеше?

Музыка өлкәсендә (бу очракта вокал сәнгатьтә) башкаручының Ходайдан килмеш талантын һәм аның профессиональ дәрәҗәсен ныклап беләсем килсә, мин аның романслар башкаруына игътибар итәм. Романс — такмак түгел. Аны югары дәрәҗәдә башкару өчен, тыңлаучы күңелен дулкынландыра, тәэсирләндерә алыр өчен олы табигый талант һәм профессиональ өзерлек кирәк. Уртакул сәләтле яки һәвәскәр җырчы моңа ирешә алмый. Әдәбиятта шундый жанр дип мин лириканы исәплим. Әлбәттә, сүз чын лирика, чын тойгылар хакында бара. Мондый төр әсәрләр күп языла алмый. Ә булганнарының бездә инде менә дистәләрчә еллар буе кадерен белүчә юк. Аларны ялган лирика һәм публицисти[ка] күмеп калдыра. Тәнкыйть асыл ташны га[...] чуерташтан аерып алырга ярдәм итми ди[...]лек.

Узган 1994 ел поэзиясенә йомгак ясар[га] тиешле җыелыш, минемчә, шуның бер м[...]лы булды. Поэзиянең гомуми торышы тур[ын]да бер доклад тыңланды. Икенче чыгыш пу[б]лицистик шигырьләрне тикшерүгә багышла[н]ган иде. Докладчылар үз бурычларын әйбә[т] башкарып чыктылар. Өченче чыгыш лирика[га] махсус багышланса да, хәзерге чорда лири[ка] шул ук публицистика инде ул, дип, доклад[чы] янә публицистик әсәрләр хакында гына сө[й]ләргә тиеш тапты.

Ни өчен шулай килеп чыга соң? Ихтима[л], лирик жанрдагы әсәрләрнең азлыгы сәбә[п]тер, доклад ясарга мөмкинлек юктыр. Бәл[ки] шулайдыр, ә бәлки түгелдер дә. Югыйсә, [...] дигән әсәрләрне дә күрсәтеп бирергә, [...] урыннарын билгеләргә кирәк иде бит.

Монысы — бер мисал гына. Гомуми хәл и[...] катлаулырак һәм аянычлырак. Базар псих[о]логиясе, ерткычлык сыйфатлары, поэзия[гә] каршы көч буларак, һәртөрле шигырьне, а[е]руча лириканы кысрыклый.

Гуманистик идеологияне[...] догматик сәясәтчеләре б[...] геләгән кысалары җимере[л]гәч, аның үз асылына кайт[у]ын көткән идек. Ләкин ситуация шундый ки, күз алд[ы]бызда гуманизмны ерткы[ч]лык психологиясе белән а[л]маштыру процессы бара. Х[...]ерчегә (мәгълүм ки, хәзер алар һәр урам чатында утыра) аш урыны[...] таш суза торган токым барлыкка килеп, [...] идеологиясен тарата. Күпме пычрак йот[ып] өлгердек инде — порнография, чернуха (м[о]ның татарча термины әле табылмаган бугай), [...]кан, шәфкатьсезлек... Алардан инде гары[...]быз. Игелеклелек, миһербан, намуслылык с[а]гындыра. Шигырьдә һәм тормышта мин шул[а]рның кайтуын көтәм. Булырмы андый көннәр?

Аккошларны кырып бетердек тә, хәзер а[ла]рны сагынып яшь түгәбез. Кайчангача?!

Дөнья бер төсле генә түгел, диярсез. Матур[...]лык та бетеп бетмәгән, әйбәт, хәтта даһи ш[и]гырьләр дә юк түгел диярсез. Андыйларны д[а] күрергә иде, диярсез. Һәм хаклы булырсы[з]. Әйе, нәкъ мин дә бит шуларны күрергә һә[м] күрсәтергә тырышырга иде дим. Бу җәһәттә[н] шушы елның башында «Татарстан хәбәрләре» газетасында басылган «Иләмсез үрдәк бә[бкә]сә» исемле мәкаләмдә уңай мисаллар д[а], тискәреләре дә байтак күрсәтелгән иде. Б[у] юлы исә аларны кабатлыйсым килмәде. М[и]салларны тагын да күбрәк күрсәтүче булс[а], мин аларны сөенеп укыр идем.

Әйе, бар алар — күңел җәүһәрләре. Ләкин сатыла торган түгелләр. Бар син, базарга чы[к]та: «Лирика сатам, кемгә кирәк?» — дип игъ[...]лан кыл. Сары йортка юл күрсәтүчеләр бу[л]мас димә. Ә менә аракы дисәң, икенче [...]. Почмак саен ун кибет. Һич югы ун кибетнең берсе китапныкы булса икән. Иллә дә мәгәр шигырь сатып кем баеган!

Гәрчә «демократлар», оялгандай, бу сүзне телгә алмасалар да, урамда — капитализм. Кур[...] Тукайлар кичергән кыргый капитализм. Кур[...]гәнебез бар лабаса, бөек шагыйрьнең ел[...] кагы шикелле җыентыкларын. Каргалган Со[...]ветлар властена шуның өчен рәхмәт, аның [...]томнарын кабат-кабат чыгару мөмкинлеге би[...]реп, халкыбызның талантлы икәнен күргәзер[...]гә (гәрчә вакытлы дип исәпләнгән юмартлык белән булса да) җай тудырды. Ә моннан соң? Базар кыза. Аның өчен Тукай да, Пушкин да кирәгер дип фаразлау беркатлылыкка тар[...]тым.

Әгәр дә күңел җәүһәрләрен натураль җә[...]үһәрләр кебек колакларга, муеннарга тагар[...]га, йөзек кашлары итеп ялтыратырга мөмкин булса, хафаланмас идек тә. Нишләмәк кирәк, [...] рухи кыйммәтләрнең бәяләре матди товар бә[...]яләре күтәрелә бару бәрабәренә төшә, кадер[...]сезләнә бара. Иҗтимагый корылышка бәйле булганлыктан, бу мәсьәлә бары тик дәүләт югарылыгында гына хәл ителә алачак.

Ә дәүләткә шигырь кирәгерме? Көтеп [...]рыйк. Берденбер чара — шул. Өметсе[з] — шайтан.

Их, шигърият...

Мин аңа, иләмсез үрдәк бәбкәсенә, тагын озын гомер телим:

— Аккошка әйләнеп, үз югарылыгыңа күтә[...]рел! Бәхетле очышлар сиңа!!

Август, 1995

И ТУГАН ТЕЛ...

«МӘДӘНИ ҖОМГА» ГАЗЕТАСЫНЫҢ МАХСУС КУШЫМТАСЫ № 2 (25)

Татарча укырга карар кылдым да бит...

Мәктәптә

(өзек)

Күңелсез һәм дә ямьсез булса да шул чак табигатьтә,
Кызык ләкин, күңелле бит авыл кырыенда мәктәптә!

Габдулла ТУКАЙ.

МӨХӘРРИР ФИКЕРЕ

Гыйлемгә омтылу — татар кешесенең асыл сыйфатларыннан. Ул гомер-бакый балаларын укыту өчен үзен җаваплы тойган. Татар халкы үз мәгарифенә беркайчан да битараф булмаган. Укытуның ана телендә булуын да халык фарыз санаган. Кысык заманнарда да хыялыннан ваз кичмәгән, һәр мөмкинлектән файдаланырга тырышкан, гыйлемлеге ягыннан иң алдынгы халыклар рәтендә торган.

Ана телендә укып белем, тәрбия алу милләтнең асыл сыйфатларын үзләштерү, ата-бабаның гореф-гадәт-йолаларын саклап, алар уйлаган кебек уйлап, гамәл кылып яши белүнең төп чарасы һәм чыганагы икәнен без яхшы беләбез. Олы җанлы, шәфкатьле, хезмәт сөючән, мәдәнияткә омтылган шәхес булу өчен дә ана теле юл ача. Ана теле башка телләрне дә үзләштерергә, шулай итеп бүтән халыкларның уңай сыйфатларын, мәдәниятен, үрнәк алырлык эш-казанышларын өйрәнергә мөмкинлек бирә.

Үз телендә белем алу мөмкинлекләре чикләнү аркасында халкыбыз тәрәккыят юлында күпме отылды. Куып җитәр өчен хәзер гаять күп көч, вакыт сарыф итәргә кирәк! Шөкер, акрынлап булса да куа киләбез. Кайчан гына башкалабыз Казанда татарча ярым-йорты укытылган бер бөртек мәктәп бар иде, бөтен районы татардан торган район үзәкләрендә дә татар мәктәпләре бетерелгән иде. Хәзер татар мәктәпләре, урыс мәктәпләрендә татар сыйныфлары елдан-ел ишәя. Бүген татар гимназияләре генә дә 90га җитте, быел ор-яңа 36 татар мәктәбе ачылды.

Сизәсез булыр, әле дә сан ягын остенрәк куябыз, чөнки мәктәпләрнең, аеруча югары уку йортларының, аларда татарча укучыларның сан ягыннан ишәюе дә бик кирәк. Шулай да бүген инде сыйфат ягыннан калышмыйбыз микән? дигән сорау куя да бик урынлы булыр. Укуның, белемнең нәтиҗәсен баллар, мактау грамоталары белән генә бәяләү чоры үтте. Ана телендә укыту барышын, сыйфатын, нәтиҗәлелеген бөтен җәмәгатьчелек, бөтен халык хәстәренә, күзәтүенә алырга бик вакыт.

Ана телен яхшы белгән, аны тормышта кулланып, халыкка файдалы эшләр эшләгән кешеләрнең хезмәтен югары бәяләргә, андый белгечләрнең кадерен белергә кирәк.

«И туган тел...» 1 сентябрь көнне мәктәп, гимназияләрдә, татарча укытыла торган югары уку йортларында укучыларга бер сорау бирде: «Сез ни өчен татарча укырга карар кылдыгыз?» Беренче карашка гади генә тоелган бу сорауның төбендә татарча белем алучыларның язмышы, татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрелү мәсьәләсе кебек җитди уйланулар ятадыр. Безгә җавап биргән укучылар аңа нәкъ менә шулай караганнар да. Безнеңчә, бу сорауны һәр класста, һәр мәктәп, гимназиядә, башка уку йортларында да бирергә мөмкин. Җаваплар ата-аналарга, укытучыларга, педколлективларга гына түгел, урындагы һәм хатта хөкүмәт җитәкчеләренә дә уйланыр өчен нигез булыр иде дип өметләнәбез.

Бу сәхифәдә без КДУның журналистика факультетына укырга кергән студентларның җавапларын тәкъдим итәбез.

Кул ярасы төзәлә,
тел ярасы төзәлми

Калган хәтернең
кары китсә дә,
бозы китми

БЕЗНЕҢ АНКЕТА

«Нәрсәгә кирәк!» диләр

Егерме проценттан артык милләттәшебез бүген татар телен үзенең туган теле итеп санамый, шәһәрләрдә яшәүче татарларның күпчелеге ана телендә рәтле-юньле сөйләшә-аңлаша алмый. Татар теле дөньяда иң күп таралган дәрәҗәле 14 телнең берсе дип мактанабыз тагын. Инглиз, немец телләрен беләбез, ә туган телебез... «успеет».

Әйе, әйе, нигә туган телеңне белмисең, дигән сорауга, күбесе «а зачем он нужен?» — диләр. «Нәрсәгә кирәк», диләр. Шундый җавапларны мин еш ишетәм. Бигрәк тә шәһәрдәге дус-ишләремнән.

Менә быел мин 11 нче сыйныфны саф татар гимназиясендә тәмамладым. Без нинди телдә аралаштык соң? «Татар телендәдер», диярсез. Юк шул, юк. Чәтердәтеп урыс телендә сөйләшә идек. Әлбәттә, авыл кызлары үзара татар телендә аралаша иде. Ләкин, шәһәрнекеләр, хәтта татар теле һәм әдәбияты дәресләрендә дә урыс телендә сөйләшә иде. Кая инде ул башка предметларны татар телендә өйрәнергә, җавап бирергә. Андыйлар урыс мәктәбенә барсын, диярсез. Ә нигә, ул бит саф татар гимназиясендә дә урыс телендә укый ала. Ә чынлап торып татарча белем алырга теләгән күпме укучы мондый мөмкинлектән мәхрүм.

Нишләргә? Татар теле үссен, халкыбызның күңеленә керсен өчен безгә әле күп тырышырга кирәк. Бигрәк тә журналистларга, мәгариф хезмәткәрләренә. Һәрберебез моңа үзеннән өлеш кертергә тиеш, бу — безнең изге бурычыбыз. Шуңа күрә дә мин татарча укырга карар кылдым.

Люция СӘЙФЕТДИНОВА.

Йөзебезне югалта яздык

Беренчедән, безнең бәйсез Татарстаныбызны, татар милләтен дөньяга таныту өчен күп белгечләр кирәк. Алар арасында журналистлар мөһим урында. Шулар тырышлыгы белән халык арасында фикер һәм караш урнаша. Шушы юлда мин дә милләтемә үз өлешемне кертергә җыенам.

Моңарчы без башка халык мәдәниятенә кушылып үзебезнең культурабызны, гореф-гадәтләребезне югалта яздык. Ә тел, безнең туган телебез милләтнең, дәүләтебезнең йөзе булырга тиеш.

Икенчедән, минем татарча укуга мөмкинлекләрем бар: безнең Әгерҗе районы, Девятерня урта мәктәбендә телебезгә игътибар кимемәде.

Ләйсирә ФАЗЛЫЕВА.

Шәехзадә БАБИЧ

И китап!

Ап-ачык тор һәрвакытта, и китап! Баксам синә,
Чын, асыл нигезле җирдән күп белемнәр бир миңа!

И китап! Мин аңгыраны төз юлга күндерсәнә!
Мине баскан «җәһел» утын су сибеп сүндерсәнә!

Син — җуаткыч, син — уяткыч, син миңа чын-чын атам,
Булмасаң син, мин сине сагнып кына чирләп ятам.

И китабым, и китап! Миңа кыл син хитаб!
Син генә башымдагы чүп-чарны алырсың утап.

1910.

Җәһел — наданлык; Хитаб — эндәшү, сүз, мөрәҗәгать.

ЯСЛЕ-БАКЧАЛАРДА



Казанның Вахитов район мәгариф бүлегенә караган «Сөембикә» ясле-бакчасында татар теле көне буе ишетелеп тора. Биредә ана теле мохите балаларны тәрбияләргә, укытырга ярдәм итә.

Бу рәсемдә сез тәрбияче Нурзия Бәдретдин кызы Мингалиеваны олкән группа балалары белән күрәсез. Балалар да ана телен яхшы белергә омтылалар — аларга бит озакламый мәктәпкә барырга, татарча укырга!

Сәхифәбездә:

- Туган телне — гамәлгә! Тел укытуның сыйфаты [illegible]?
- Термин язмышын белгеч хәл итсен!
- Мирасыбызны барлыйбыз. Гыйлемгә омтылу — татарның асыл сыйфаты.
- Ут күршеләрдән сәламнәр.
- Этимологик табышлар.
- Безнең кунакта «Өмет» газетасы.

Су язып, май булырмы...

Тагын терминнар турында

Безгә фикер төрлелеге сүз иреге алып килгән үзгәреш заманының баштагы көннәре матбугатта төрледән-төрле агым. чоңгылләр белән болганган ташкын рәвешендә чагылып калды. Хәзер бу ташкын юашланып-хәлсезләнеп ярларына төшә бара сыман. Зурдан кубып кайнарланып кузгатылган мәсьәлә-проблемаларның кайберләре гамәлгә ашып тарихка да кереп калды. күпчелегенә исә ялкыны басылып төтене генә аз-маз чыгып яткан учак хәлендә. кайбер темалар инде чәйнәлеп-чәйнәлеп тәмам чүбеккә әйләнсә дә. берниндй дә нәтиҗәгә ирешелмәгәнгә. ә яңаларына теш үтмәгәнгә яисә кыюлык җитмәгәнгә һаман төкереп ташланмыйча чәйнәлә бирелә.

Дөрес бу юнәлештә дә буталчыклык фикер төрлелеге хәзер бераз ачыклана. дуамал кайнарлык бернн-кадәр сүрелә төште. Бүген фикер алышу минемчә төп ике яссылыкта төенләнә: татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсенә бик акрын күтәрелүенә борчылу һәм яна термин-атамалар мәсьәләсе.

Ике мәсьәләнең дә «чәйнәлеп ташланмыйча» җәмәгатьчелек игътибарында кала бирүе аларның чыннан да бер яктан халык язмышына җәмгыять мәнфәгатенә миллэтнең киләчәгенә бәйле икәненә һәм халыкның шөкер моны аңлавына ишарә булса. икенче яктан. аларның әле хәл ителмәгәнен дә сөйли.

Ләкин фикер алышуның. тәкъдим таләпләрнең һаман да бертөрлерәк калып бер урында таптануы гамәли һәм фәнни колачы киңәймәве борчый. Чыннан да бер үк нәрсәләрне күшибез дә күшибез бит — асылда телебезнең дәүләт теле була алмавыннан зарланудан ерак китә алмыйбыз. Күптән түгел «Тел күрке — сүз» радиотапшыруында яшь галимнең ярты сәгатьлек чыгышы күренекле җәмәгать эшлеклеләренең бу темага язмаларыннан өзекләр җыелмасын бәян итүдән гыйбарәт булды. Әлбәттә, ул фикер тәкъдимнәр үз вакытында кыюлык батырлык иде. кирәкле. файдалы иде. Әлбәттә вакыт-вакыт аларны кабатлап искә төшергәләү дә әллә ни зур гөнаһ түгелдер. Тик ул сүзләрне бүген аларның ни дәрәҗәдә эшкә ашырылуын бәяләү өчен. чагыштыру өчен китерергә кирәктер ләбаса. Ул тәнкыйть фикерләренең хуҗалары бүген дә шул ук депутатлар. идарәдә яисә гыйльми оешмаларда. матбугатта җитәкчеләр ич. Татар теленең дәүләт теле дәрәҗәсенә җитүе өчен бүген алар ни эшли соң тегә сүзләре ничек гамәлгә аша? Гайрәт чәчүләре кабат депутат булып сайлану урыннарында калу өчен генә булмагандыр бит?!

Безнең Конституциядә республикабыз Президентының ике дәүләт телен дә белүе шарт итеп куела. Бу берничә дә карамыйча үтәлергә тиеш. Шул ук Конституция Президентка әлеге шартның үтәлүен башкалардан да таләп итү хокукы биргән. һәм ул ике телнең дә бертигез дәрәҗәдә дәүләт теле булуының гаранты дип билгеләнгән. Димәк республикада тел сәясәтенең булдырылуы һәм гамәлгә ашырылуы өчен беренче чиратта Президент Дәүләт Советы хөкүмәт җаваплы. Нигә алар ин әүвәле үзләре үк чыгарган имза салган кабул иткән закон программа карарларының үтәлүен катгый таләп итмиләр?

Болар без бүгенге язмабызда җентеклебрәк тукталырга җыенган икенче бер мәсьәләгә җәмәгатьчелек игътибарыннан төшмичә матбугатта радио телевидениедә даими тема булып кала биргән мәсьәләгә телебезгә яңа сүзләр терминнар кабул итү элеккеләрен яңарту эшчәнлегенә дә турыдан-туры бәйле. Бу хакта да үзгәреш заманының башлангыч чорында фикерләр төрледән-төрле иде. фәннән шактый ерак торган кайнар хисле бәхәсләр тарихка да бүгенге фәнгә дә уйлап үлчәп тормыйча кизәну таш атулар бихисап булды. Хәзер бераз сүрелү сизелә шулай да бәхәс. алыш тартышлар җыелышларда матбугатта булгалап тора. Мисалга «Татарстан яшьләре»ндә М. Хәбиров (1 апр.), Ә. Хәмиди (13 июнь), Р. Тукрани (13, 5 авг.), Вахит Юныс (12 сент.) катнашкан бәхәсне. «Шәһри Казан»да. «Тел күрке — сүз»дә. «Татарстан». «Аргамак» журналларында әледән-әле кузгалып торган фикер чәкәшләрен алыйк.

Һәр авторга һәр фикер тәкъдимгә игътибар белән карарга хөрмәт итәргә күнегик әле. җәмәгать һәр чыгышның иясе яхшылык эшләү ниятеннән сүз алган дип фараз кылыйк. фикерен җиткерер өчен көчен сәламәтлеген исраф иткән. Шулай уйлаганда гына без үз чыгышларыбызга да җаваплырак карарбыз. Баштагы чорда. чыннан да телебезнең сүзлек хәзинәсенә яңалыклар кертү терминологияне камилләштерүгә караган күп кенә кызыклы. файдалы фикер тәкъдимнәр әйтелде. Фәнни нигезләнгән тормышчан тәкъдимнәр гамәлгә керә дә бара. Хәзер инде эзләнүләрне фәнни тирәнәйтәсе фикер алышу бәхәсләр нәтиҗәсендә кабул ителгән карарларны үтәү өстендә армый-талмый эшлисе дә кала. юк бит. күпчелек очракта элек әйтелгәннәрне кайтып-кайтып тәкрарлау. алга-артка уңга-сулга карамыйча үз фикереңә генә ябышып ятып үз туксаныңны туку дәвам итә.

Гафу итегез бу бит (монда мәрхүм Мөхәммәт Мәһдиев фикере белән килешмичә булмый). чыннан да гомум наданлык билгесе. Кайчандыр татар язмаларында сүзлекләрдә очраткан гарәп-фарсы яисә иске төрки сүзләрне эзләп табып. халык инде ике-өч буын кулланып күнеккән сүзлекләрдә дә теркәлгән дәреслекләрдә дә береккән алынмаларны шулар белән алыштырырга кирәк дип. берниндй фәнни нигезсез сынау-тәҗрибә үткәрмичә үҗәтләнеп йөрү гыйлемле булумы икән?

Иң башта бездә әле гомуми кулланыштагы гади сүз белән термин сүзен бутау сизелә. Телдә гасырлар буе берегеп яшәгән килгән тәртипне аерым шәхеснең оешмаларның теләү теләмәвенә карап кына үзгәртеп булмый. бу безнең ихтыярда түгел. Әгәр берәр сүзне яки грамматик форманы (әйтик. кушымчаны) үзгәртергә яисә алыштырырга телисең икән халыкка тәкъдим иткәнче син аны үз ихтыяҗыңны канәгатьләндерер өчен (гаиләңдә хезмәттәшләрең арасында җәмәгатьчелектә һ.б. кулланып кара. Әлбәттә. моның өчен синә тәкъдимеңнең тормыш ихтыяҗы икәнен фәнни нигезле икәнен исбатларга. моның өчен сынау тәҗрибәләр үткәрергә кирәк булачак. Артык гадиләштерелгән бу мисал таләпне аерым галимнәргә фәнни оешмаларга да куеп буладыр. Әгәр тәкъдимең яңалыгын бөтен халык ихтыяҗын канәгатьләндерә икән. аның да телләгенә муафыйк килә икән. димәк яңа берәмлек сөйләмдә кулланыш табар телгә дә кереп китәр — мондый «бәхетле» очраклар шөкер булып тора.

Терминга килгәндә исә. аларга карата таләп тә тәртип тә икенчерәк. Болар — аерым төр һөнәр белгечлек эшчәнлек тармагына караган берәмлекләр. Алар мәгълүм бер эш урынында. махсус һөнәри белгечлек кешеләре арасында ягъни тарлрак даирәдә кулланыла. Әйтик мехчы күнче мебельче елгачы һ.б. бик күп һөнәрләргә. белгечлекләргә караган меңнәрчә сүзләрнең термин профессионализмнарның шәләр урамнарында әйләрдә бөтенләй ишетелмәве дә ихтимал. Алар да телебез хәзинәсе. әлбәттә алар да тел законнары белән ясалалар кулланылалар. Аерма шунда гына. терминнарны үзара килешеп яисә өстән кушып та кертеп яки алмаштырып була.

Тегә бу һөнәр белгечлек өлкәсендә эш урынында берәр яңа әйбер күренеш барлыкка килә икән яисә элек хәрәкәттә гамәлдә булган берәр әйбер күренешнең сыйфатлары үзгәрә икән. яңа төшенчәгә яңа атама кирәкшелә. Бу иҗади эш махсус кагыйдәләргә таянып. аерым алганда. безнең шартларда Татарстан хөкүмәте тарафыннан расланган «Татар терминын ясау камилләштерү һәм куллану кагыйдә-принциплары»на нигезләнеп, шушы һөнәр белгечлек тармакны яхшы белгән. тәҗрибәле белгечләр ихтыяры (тәкъдиме кушуы) белән. шушы өлкәдә аралашучы бүтән кешеләр белән һәм әлеге тармак терминологиясеннән яхшы мәгълүматлы тел галимнәре белән киңәш тотып эшләнә.

Бу иҗади эшчәнлекнең колачы кечкенә бер коллектив (лаборатория, институт һ.б.) кысасында чикләнергә яисә математика физика. нефть. төзелеш транспорт һ.б. кебек киңрәк тармакларны эченә алырга. хәтта мәгариф медицина. хокукый. иҗтимагый-сәяси кебек бөтенхалык республика мәнфәгатьләренә кагылган өлкә терминнары белән дә эш итәлергә мөмкин. Димәк. терминнарның язмышын аерым тармак белгечләренең күрсәтмәсе дә. җитәкче оешмаларның тәкъдиме дә. хәтта хөкүмәт карары, Президент фәрманы да хәл итүе ихтимал.

Ничек кенә булмасын. терминология эшчәнлегенең башлыча нәкъ менә урыннарда — һөнәр белгечлек тармагының җитәкче һәм фәнни оешмаларында шушы өлкә белгечләре белән башкарылуы хәерле. Шөкер, бездә дә хәзер нәкъ шушы юнәлешкә таба үзгәреш сизелә башлады.

Казан дәүләт педагогия университетында аерым фәннәр буенча (математика физика психология педагогика һ.б.) терминологиясе буенча эшләүнең күпьеллык тәҗрибәсе бар. Биредә бу эшчәнлек соңгы вакытта тагын да җанланды. Терминология юнәлешендә фәнни-нәзари һәм гамәли эшчәнлекнең бергә үрелеп барганда гына уңыш бирәчәгенә мисал дәлил, әлеләрне нәкъ менә шушыннан күпләп китерергә була.

Медицина авыл хуҗалыгы академияләре дә үз тармакларына караган термин сүзлекләре төзүдә өлгерлек, тырышлык күрсәтә.

Казан архитектура һәм төзелеш академиясе галимнәренең эшчәнлеге аерым билгеләп үтүгә лаек. Биредә соңгы елларда техника төзелеш өлкәсенә катнаулы фәннәргә караган терминология мәсьәләләрен хәл итү, термин сүзлекләре төзүдә яңача эшләр. Аерым фән тармак һөнәр терминологиясе бүлекчәләренә булышлык арадашлык итү максатында академия буенча гомуми термин комиссиясе оештырылды.

Быел май азагында «Техник югары уку йортларында татарча укыту проблемалары» дигән темага республика фәнни конференциясенең дә биредә үткәрелүе очраклы түгелдер. Конференция барышында бүгенге терминологиянең төрле фәнни һәм гамәли яклары да күтәрелде. Әйтик тармак институтлары белән фәнни институтлар, оешмалар арасындагы бәйләныш даими эшлекле булганда гына уңышлар киләчәге күп мисаллар белән дәлилләнде. Төзелеш белгече доцент Рәшит Шакирҗанов белән Тел әдәбият һәм тарих институты галиме филология фәннәре докторы Рифгать Әхмәтьяновның берләшеп иҗат иткән зур күләмле югары сыйфатлы «Русча-татарча төзелеш атамалары сүзлеге», медицина профессоры М. Миңнебаев белән тел галимәсе Р. Шәмсетдинова төзегән «Кыскача русча-татарча медицина терминнары аңлатмалы сүзлеге» һ.б. моңа ышанычлы мисаллар.

Кама политехника институтында, Казан ветеринария академиясендә дә бу юнәлештә зур җанлану сизелә. Тулаем алганда әлеге конференция барышында терминология темасына уңлап чыгыш ясалуы уңай күренеш булды. Киләчәктә дә тематик конференцияләрдә бу тема читтә калмасын. булган тәҗрибә гомумиләштерелә. таратыла барсын иде. Вуз-ара термин комиссияләре төзергә кирәк. дигән тәкъдим менә шушы конференциядә әйтелеп. хуплау тапты.

Күренә ки. терминнар буенча эшләүнең дөрес кыйблаларын тормыш үзе билгеләде. Яңа төшенчәләргә атама билгеләү. элеккеләрен алыштыру шушы һөнәр. белгечлек буенча урындагы башлангыч бүлекчәләр тәкъдиме белән хәл ителергә тиеш. Республика термин комиссиясе хәзер нәкъ шул юнәлештә эшчәнлеген җанландыра да. аерым һөнәр. белгечлекләр укытыла өйрәтелә торган оешма. институтларда. зур предприятие (эшханә), ведомстволарда. тармак идарәләрендә һәм министрлыкларда тармак терминология бүлекчәләре булдырыла. Аларның саны егермеләп булыр дип көтелә. Республика термин комиссиясе аларны терки башлады инде. Һәр бүлекчә үзенең җитәкчеләген сайлый. эш планын тәкъдим итә. Бүлекчәләр яңа термин, профессионализмнарны сайлап алу. камилләштерү. куллану үзенчәлекләрен төшендерү. термин сүзлек һәм сүзлекчәләрен төзеп. басмага тәкъдим итү белән шөгыльләнә. Сүзлекләрне. бу өлкәгә караган төрле кулланма. язмаларны республика термин комиссиясе басмага бары бүлекчәләр хуплаганнан соң гына тәкъдим итәчәк. Комиссия чираттагы бер утырышын әлеге бүлекчәләрнең эшен җанландыруга багышлаячак.

Дөресен әйткәндә. республика термин комиссиясенең үзенә дә. эшчәнлеген җанландыру өчен матди булышлык сорап. шул министрлык ведомстволарга. эшханәләргә бай хуҗаларга барып баш иярге калды бугай. 1919 елдан ук халыкка хезмәт итеп килгән. заманында Югары Совет хөкүмәт органы саналган комиссия бүген килеп. гадәт буенча гына республика комиссиясе дип аталса да чынында. Татарстан Министрлар кабинеты карары белән. узган елның августыннан Министрлар кабинеты каршындагы җәмәгать башлангычында эшләүче (дөресрәге. кәгазьдә генә «эшләүче») телләрне гамәлгә ашыру комитетының шулай ук җәмәгать башлангычында эшләүче (дөресрәге, бушлай эшләргә. димәк. эшләр-эшләмәс җан асрарга мәҗбүр ителгән) гади бер комиссия итеп теркәлгән.

Шундый хәлгә каршылык нәфрәт белдерәсе урынга кайбер «белдеклеләр» комиссияне белмәмешкә күрмәмешкә сабышалар (бәлки наданлык аркасында чыннан да белмиләрдер дә) андый комиссия юк булдырырга кирәк дип лаф оралар. Хәер бу хакта Мәскәүдә яшәп тә комиссия хакында яхшы хәбәрдар Вахит Юныйсның күзәтүе. дәлилләре игътибарга лаек.

Комиссиянең эшчәнлеге турында аңардан башка да уңай яктан да, тәнкыйтьләп тә бер генә мәртәбә язылмады. Язылуын язылды. тик терминология хуҗалыгын тәртипкә китерү юнәлешендәге һәм фәнни. һәм гамәли эшләр әле хәтсез. Болар хакында уртага салып җитди бер сөйләшү үткәрергә дә вакыт җитте шикелле. гомумән дә бер гомумтөрки конференцияләрнең берсен. сузмыйча. терминология темасына багышлыйсы иде. Шулай да. иң әүвәле республикабызда төпле уйланылган. тормыш ихтыяҗына таянып эшләнгән дәүләткүләм тел сәясәте гамәлгә куелса, терминология мәсьәләләре дә анда җитдиләрдән саналып, аларны эзлекле, нәтиҗәле үтәргә мөмкинлекләр барлыкка килер иде. Акыл сатудан. вәгазь укудан, үзара «надан» бәхәсләр кузгатудан туктар идек. Ә хәзергә...

КДУ лифтында ике яшь галим сөйләшеп төшеп килә.

— Тарихны татарча укытырга куштылар әле. Терминнары да эшләнмәгән бит әле аның.

— Әйтмә инде бер көнне сүзлекне бекарап утырам. «раскулачивание» беләсеңме ничек? «Раскулачить итү». Во! Ха-ха-ха!

Лифт тартмасы шаркылдаудан ярылып китә дип торам. Яшьләр бит, дим. көлсеннәр әйдә. Халкыңның үткәненнән үз тарихыңнан көлү килешмәсә дә. заманы шундый бит әйдә, көлешсеннәр дим. Көлеп туктарлар да, үзләре яхшырак сүз-термин тәкъдим итәрләр дип көтәм. Юк шул...

Илдар НИЗАМОВ,
КДУ доценты.
филология фәннәре кандидаты

МИРАСЫБЫЗНЫ БАРЛЫЙБЫЗ

Шәйхи МАННУР

Агымсуларга карап

Әткәм-әнкәмнең теле...

Нихәтле генә гарьлек булмасын, мин тагын мәктәпкә киттем. Беренчедә Коръәннең кирәге юк, шулай да аны букчадан калдырмадым — әтәй сизмәсен. Тагын шул маймычлар арасына кереп утырдым. Мөгаллим абый иң элек безгә дәрес бирде. Хәрефләрне тактада күрсәтеп, аңлатып, укытып карады да бер бит тулганчы шуларны тактадагыча итеп язарга кушты. Ә минем кулга «Мөгаллиме әүвәл» дигән китап биреп, беренче битен ачтырды да «ата, ана, арба, чана, ат» дигән аерым дәрес бирде. Шуларны миңа матурлап, китаптагыча итеп, бер дә пычратмыйча ике бит тутырып язарга кушты. Бу миңа тагын сәер тоелды. Мәдрәсә ишеген ачып кергәннән бирле мин «әбҗәд һәүвәз» дип «кәлимәтен тайбатын» дип, «ясин вә коръәнелхәким» дип «әлхәмде лилляһи раббиль галәмин» дип гел үзем белмәгән телдә укып килгән идем. Ниләр сөйләде икән ул сүзләр? Ә монда, ана сөте белән үк ачыла башлаган җип-җиңел үз телеңдә «ата, ана, арба, чана, ат» дип, күз алдында тап-тере булып торган нәрсәләр турында укып маташ. Шул — сабак була, имеш! Бер уйласаң, гел көлке ич! Ә икенче бер уйласаң — ник сабак булмасын? Анда бит шундый якын, шундый газиз кешеләр, шундый таныш нәрсәләр турында әйтелә. Юк, әйбәт дәрес икән бу. Нәрсә чәйнәгәнеңне белеп чәйнисең.

Үземчә шундый «акыллы» фикергә килдем дә бик тырышып, тәбәнәк парта өстенә ята төшеп, дигәндәй, язарга тотындым. Мөгаллим абый килеп-килеп күз төшергәләсә дә «тегеләй ит болай ит» дип, ләм-мим бер сүз әйтмәде. Эштә гаеп күренмәгәч, күңел гел үсеп китә икән. Ике бит белән генә калмадым, кыңгыравык булганчы өч бит яздым мин ул сүзләрне. Язган саен хәрефләр шомарак төшкән сыман күренә башлады.

... Белмим, берәр бәйрәм уңае беләнме әллә болай гынамы, мөгаллим абый безнең беренче-икенчеләрне шигырь әйтергә өйрәтте. Башта ул шигырьне берничә дәрестә безгә әйтеп яздырды, аннары күрми өйрәнеп килергә кушты. Ятлап килгәч, такта янына чыгарып тезде дә үзе өйрәткән көйне үзе башлап җибәрде. Без яшелле-күкле тавышлар белән аңа кушылдык.

И туган тел, и матур тел,
Әткәм-әнкәмнең теле...

Бөтен мәктәп яңгырап китте. Өченчеләр белән дүртенчеләр дә парта арасына басып безгә кушылды, тагын да шәбрәк яңгырата башладык. Шәмәк мәдрәсәсендә минем малайларга кушылып әлвидаг әйткәнем бар, гарәфә кичтә малайлар белән мәчет манарасына менеп салават әйткән бар, гаеткә барганда әтәйгә күрше-күләнгә кушылып тәкбир әйткән бар, түтәй белән бергә кушылып «Мөхәммәдия» китабыннан мөнәҗәт әйткән бар, әмма шигырь әйткәнем юк. Монда килеп кергәнче шигырь дигән сүз булуын ишеткәнем дә юк, һәм дөньяда без әйткән шикелле шундый матур шигырь барлыгын да белгәнем юк иде.

Шул көннәрдә безнең баракка, минем яшәр Мехәмәй атлы малаен ияртеп, аксак Гыйлаҗ абзый килеп чыкты. Аның элек тә бер-ике булганы бар иде. Ул үзе Түбән Тәкәнешнеке. әтәйнең дус кешесе. Кайчандыр шахтада басылудан шулай аксак булып калган. Хәзер Томскидан китереп китаплар сатып йөри. Аның аркасына күтәреп йөри торган фанер әрҗәсе бөтен «Мөхлисун» өчен бердәнбер китап кибете иде бугай. Бөтен урында татар китаплары сатылуын белмим. Үткән килүендә әтәй аннан Коръән тәфсире алып калган иде. Миңа бик үк аңлашылып бетми торган һәм укырга кызыгы булмаган калын китап. Мин ул чакта Гыйлаҗ абзыйның әрҗәсендә тагын нинди китаплар булуы белән кызыксынмаган да идем. ә бу юлы «әрҗә кибет»кә иң элек мин ташландым. Ул миңа төрле догалыклар белән бергә «Җырлар әхтәрисе» «Менә сиңа шәп җырлар» «Сугыш бәете» «Канау буе» «Суга баткан кыз» дигән китаплар күрсәтте. Боларның хаклары ике-өч тиеннән артмаганга күрә, барысын сыпырдым да алдым.

ЯҢАЛЫК! ЯҢАЛЫК!

Даими кунаклар

Яңа уку елы алдыннан гына Казанда Башкортстаннан татар теле-әдәбияты укытучыларыннан, сәнгать-мәдәният эшмәкәрләреннән торган делегация булып китте. Аны даими делегация дияргә дә була — бу даирә эшлекләре, Башкортстанның татар мәркәзе рәисе урынбасары Кифая Фазлетдинова җитәкчелегендә, берничә мәртәбә Татарстанның төрле мәдәни үзәкләрендә булдылар, мәгариф яңалыклары белән кызыксындылар инде.

Бу юлы да кунаклар мәгариф, мәдәният өлкәсендәге соңгы яңалыклар белән танышты. Матбугат йортында шагыйрьләр, галимнәр, журналистлар белән очраштылар, китаплар, уку әсбаплары сатып алдылар, музей, күргәзмәләрдә булдылар.

Ә бәлки...

Айлык «Выбор» гәзитенең (аны тотучылар — ТР инвалидларының социаль-иҗтимагый оешмалары ассоциациясе, Русия пенсия фондының ТР буенча бүлеге) август санының бер бите татар телендә басылган. Анда инвалидлар яшәешенә багышланган махсус аңлатма-язмалар, «Җиде бабагызны белегез», «Даруларсыз дәвалан» кебек кызыклы материаллар эдәби әсәр дә бар.

Иң мөһиме — сәхифәдә шушы гәзитне укучыларның берничә хаты басылган. Менә шушы җитди темаларга ана телендә язып җибәрелгән хатлар гәзит журналистларына татарча сәхифә чыгарырга ният-сәбәп булгандыр да.

Киләчәктә бәлки гәзит укучыларның таләбе белән тулаем татарча гәзит чыгарыла башланмасмы!?

И.МАЗИН.

БЕЗДӘН КҮРЕП, ГЫЙБРӘТ АЛЫРЛАР

БДБнең татарлар яшәгән кайсы гына төбәген алма, андагы халыкның таләбе белән татарча якшәмбе мәктәпләре, катнаш мәктәптә татар класслары, кайбер урыннарда хәтта татар мәктәпләре ачыла. Безнең институтның татар теле һәм әдәбиятын укыту методикасы кафедрасы хезмәткәрләре мәсәлән, Омски, Томски, Төмән, Чиләбе, Пенза, Түбән Новгород өлкәсендә һ.б. өлкәләрдә үзләре булып, шуңа ышанып кайттылар. Татарстаннан, татар мәдәнияте үзәгеннән читтә яшәп тә, үз баласына ата-бабасы телен, гореф-гадәт-йоласын әйрәтергә омтылган милләттәшләргә башка милләт вәкилләренең хуплә сокланып та, көнләшеп тә карый.

Быел җәй без Удмуртиянең Мәгариф министрлыгы чакыруы буенча андагы татар теле һәм әдәбияты укытучыларының август киңәшмәсендә катнаштык. Шунда укытучылар һәм мәгариф җитәкчеләре белән аралашудан алган тәэсирләрне сезнең белән дә уртаклашырга уйладык.

Удмуртия җитәкчелеге, шул исәптән Мәгариф министрлыгы катнаш мәктәпләрдә татар сыйныфлары, балалар бакчаларында татар группалары ачуга уңай карый. Кызганыч ки, Удмуртиянең үзендә удмурт мәктәбе түгел, бер генә удмурт классы да юк.

Удмуртиянең Мәгариф министрлыгында татар мәгарифе буенча (Мәдәният министрлыгында татар мәдәнияте буенча) махсус татар белгече тотылу да, татар телен укыткан укытучыларның берсенә (мәдәният өлкәсендә эшләүчеләрнең берсенә) Удмуртиянең атказанган укытучысы (мәдәният хезмәткәре) дигән мактаулы исем бирелү андагы җитәкчелекнең милләттәшләребезгә аларның үсешенә булышуын теләп ярдәм итүен аңлатадыр.

Удмуртиянең дәүләт университетында, педагогия училищесында татар теле бүлекләре ачылып, укытучыларны үзләрендә әзерләү мәсьәләсен хәл итү, балаларның җәйге ялы вакытында Удмуртиядә яшәүче татар балалары өчен махсус лагерьлар оештырылу (ә боларның барысына да миллионнар кирәк), татарча чыгышлар тапшыру өчен дәүләтнең радио һәм телевидениесендә даими вакыт бирелү, татар телендә газета чыгарылу да — барысы да җирле хакимиятнең татарларга булган мөнәсәбәтен ачык чагылдыра. Монда халкыбызның эшенә карап бәя бирәләр, хезмәтенә карап хезмәт күрсәтәләр дияргә була.

Удмуртиядә яшәүче татарлар мисалы безгә уйланырга, кайбер нәтиҗәләр ясарга җирлек бирә. Кеше нинди генә милләттән булып, кайда гына яшәмәсен, аның рухи ихтыяҗы ата-бабасы традицияләре нигезендә үсәргә тиеш. Моңа бер җирдә дә, бер кем тарафыннан да киртә куелмау мәгъкуль. Мәгариф, мәдәният өлкәсендә эшләүче һәр кеше — җитәкчеме ул, гади хезмәткәрме — шуны онытмасын иде. Ә мәктәп белгәнебезчә милләтләр арасындагы үзара татулыкның нигезе салына торган урын. Шуңа күрә катнаш мәктәптә укучы һәр бала «үзенекен» белдертеп тәрбияләнергә, шул ук вакытта, үзе белән бер мәктәптә укучы башка милләт вәкиленнән булган балаларның да халкына хас уңай сыйфатларны белергә, аның гореф-гадәт-йоласына хөрмәт хисендә тәрбияләнергә тиеш. Ягъни катнаш мәктәптә — ә алар бүген һәр урында күпчелек — укучы бер милләт баласы үз халкының батыр, горур, тырыш һ.б. уңай сыйфатларын ишетеп, икенчесе үз халкы турында ишетмәсә, кимсенеп утырыр. Бала, теләгәндә нәкъ шул яхшы сыйфатларны үз халкында таба ала. Баланың әти-әнисе төрле милләт кешеләре булса (андый гаиләләр азмыни!?), әтисенең милләте турында яхшы сүз ишеткәндә әнисенең милләте турында да шундыйрак сүзләрне ишетсен иде.

Шуңа күрә бүгенге мәктәп укытучысы милләтләр арасындагы килешүгә, димәк, тыныч киләчәгебезгә бүгенге төрле милләт балалары аша нигез сала.

Татар халкының мәдәни һәм мәгариф проблемалары Татарстан дәүләтенең чикләрендә генә хәл ителеп бетә алмый. Шуңа да, әгәр киләчәктә тыныч илдә имин яшик дисәк, без — Татарстандагы татарлар — үз дәүләтебездә яшәүче һәр халыкның рухи үсешенә ярдәм күрсәтик. Мәктәпләребезне милләтара килешүгә баруда нигез итик. Татарстанның мөстәкыйльлеккә бару юлында үз моделе барлыкны Русия генә түгел, дөнья таныды. Киләчәгебезнең бер-беребезгә бәйле булуын аңлап, мәктәпләребезне милләтара килешүнең башы дип танып, шул модельне яңа эчтәлек белән баетыйк. Бездән гыйбрәт алып, башка җирләрдә, илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә ул мәмләкәтләрнең мәктәпләрендә ярдәм итәрләр.

Н.МАКСИМОВ,
Укытучылар белемен күтәрү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире

Түрдән рәхим ит, Өмет!

Миллионнан күбрәк татар халкы булган Башкортстанда элек татарча ике-өч дубляж район гәзите, нибары бер республика гәзите («Кызыл таң») чыга иде. Хәзер алар арта бара. Менә бишенче елын яшьләр гәзите «Өмет» чыгып килә. Баш мөхәррире — Фаил Фәтхетдинов. Гәзит яшьләр арасында татар теленә хөрмәт тәрбияләү, аны өйрәтү, татар халкының тарихын дөрес яктырту, гореф-гадәт-йолаларын тарату, өйрәтү өлкәсендә, Татарстан белән Башкортстан арасында бәйләнешләрне беркетерү юлында зур эш эшли. Тиражы өлегә 32 мең чамасы.

«Өмет»нең «Чаткылар» кушымтасы балалар арасында абруй казанып бара — ул татар әдәби телендә чыга, язучыларыбыз, сәнгатьчеләребез иҗатына даими игътибар бирә, балалар иҗатын үстерүгә зур өлеш кертә.

Түбәндә «Өмет»тән һәм «Чаткылар»дан кайбер язмалар тәкъдим итәбез.

Тереләрдән тере Тукаебыз

Безнең кырык кеше утырган уңайлы автобус та «Туган тел» көен шаулатып-гөрләтеп Кырлайга, Габдулла Тукайның йорт-музее янына килеп туктады. Агачлар, яшеллеккә күмелгән ихатада шагыйрьгә һәйкәл. Гүя ул монда килүчеләрне сәламләп каршылый...

Башкортстаннан килгән сәяхәтчеләр арасында татар теле укытучылары, урыс мәктәпләрендә ачылган татар класслары укучылары, фәнни хезмәткәрләр, журналистлар, башка зыялылар бар. Һәркем дулкынлана...

Йорт-музейдан тәэсирләр хисенә исереп чыгабыз. Малайлар һәм кызлар шаулаша.

— Әйдә, Тукай иҗатына багышлап конкурс оештырабыз!

Әйбәт тәкъдим. Каршы килүче юк. Ә инде өдип һәйкәле янында аның шигырьләрен укуга, матур җырлауга, такмаклар әйтүгә имтихан оештырып кара инде!

Уфаның 126 нчы мәктәбеннән 5 нче сыйныф кызы Әлфия Булгакованың Тукайның «Туган авыл»ын, 9 нчы мәктәпнең 5 нче сыйныф укучысы Салават Гәрәевнең шулай ук Тукай шигырьләрен матур итеп укуы күпләрне сокландырды. Ә Кандрадан 6 нчы сыйныф укучысы Руслан Фәттахов башкаруында халык җырлары ямь өстенә ямь өстәде. Ләйсән Мортазина Тукайның «Кәҗә белән сарык әкияте»н укыды.

Нәни үзешчәннәргә җыелган халык гөрләп кул чапты. Ә аларга һәр чыгыш саен — сувенирлар, тәмле-тәмле бүләк — кәнфит-печенье...

Равил ХӘКИМОВ,
«Өмет»нең махсус хәбәрчесе.

Дуслар җыелган җирдә

Репортаж

Югары Яркәй авыл стадионында «Җидегән йолдыз» акционерлык җәмгыятенең «Башкортстан» иҗади клубы белән бергә оештырган башкорт-татар яшьләре җыены үткәрелде. Ул, республикада барган С.Юлаев көннәре уңае белән, Бөтендөнья башкортлары корылтаена багышлап оештырылган.

Җыенны үткәрүнең максаты турында сөйләүне сорап, аның баш режиссеры, Башкортстанның халык артисты Идрис Газиевка мөрәҗәгать иттек.

— Бу бәйрәмне оештыру уе күптән күңелләрне биләгән иде. Элек-электән башкорт-татар халкының иң яраткан бәйрәмнәреннән бит ул җыен. Анда борын-борыннан рәхәтләнеп ял иткәннәр, күңел ачканнар, көндәлек борчу-мәшәкатьләрдән арынганнар, яңа дуслар тапканнар, яшьләр табышкан, аннан көзге бәйрәмнәрдә кавышкан. Ә бит безнең бу катлаулы чорыбыз да үзара берләшүне, заман авырлыкларына бердәм каршы торуны таләп итә. Менә шушы максатлардан чыгып, ике тугандаш халыкны бербөтен итеп карап оештырылды бу тамаша. Аны тормышчан итүдә Башкортстанның атказанган артисты Венер Мостафин зур көч, тырышлык салды. Үткәрү географиясе дә бу турыда ачык сөйли. Яңавыл, Борай, Стәрлетамак, Салават, Бәләбәй, Ишембай, Күмертау, Туймазы, Илеш, Дүртөйле, Нефтекама, Сибай, Учалы районнары үзәкләрендә күрсәтелде һәм күрсәтелә чыгышыбыз.

Тамашачылар бик җылы кабул итте программабызны...

А.ХӘЙРЕТДИНОВА.
Илеш районы.

Әй уйнадык, уйнадык

Бездә дүшәмбе көннән башлап җанлы әдәбият атналыгы үтте. «Ул чал тарихы бар халкымның» дип аталды. Беренче көнне 6 нчы сыйныф укучылары «Аулак өй» күренешен әзерләгәннәр иде. Аларның чыгышы бик матур, күңелле булды. Аулакта «йөзек салыш», «кем сукты» уеннарын уйнадылар. Йөзек салынган укучылар үзләренең осталыгын күрсәтте. Рафикова Римма белән Шәмсетдинова Нурсиләнең җырлары бигрәк тә ошады. Атналыкның икенче көнендә 5 нче сыйныф укучылары фольклор бәйрәме оештырдылар. Бәйрәмдә без халкыбызның төрле матур җырларын, әйтемнәрен, такмазаларын ишеттек. Аларның шулкадәр оста әзерләнүе, матур итеп бәйрәмне оештыруы һәркемнең күңеленә хуш килде. Ә инде атнакич без, 7 нче сыйныфлар, «Нәүрүз бәйрәме» үткәрдек. Анда без халкыбызның онытылып барган «Наза» уенын уйнадык...

Розалия АЛПАРОВА,
Авыргазы районы, Кормакай урта мәктәбе, 7 нче сыйныф укучысы.

ЭТИМОЛОГИК ТАБЫШЛАР

ГӘРӘБӘ ҺӘМ ГЕРӘБӘНКӘ.

Татарча **гәрәбә**, башкорт сөйләшләрендәге **кәрәбә**, Себер татарларындагы **кәкрәбә**, марича һәм удмуртча **гәрәбә, гараба**, чувашча **керепе, кахраба** «гәрәбә (янтарь); гәрәбә муенса» сүзен фарсыча **кәһруба** «салам тарткыч» сүзеннән дип уйлыйлар. Бик күп сүзлекләрдә (шул хисаптан К.Насыйриның «Ләһҗәи татари» дигән аңлатмалы сүзлегендә дә) шулай аңлатыла. X гасырда яшәгән бөек фарсы-таҗик шагыйре Әбелкасыйм Фирдәүси дә болай яза:

Гәрәбә ничек суырса саламны
Патшаны шулай үлем урлап алды.

Хикмәт шунда: гәрәбә бик тиз электрлана, һәм салам кисәкләрен һ.б.ш. үзенә тарта башлый. Борынгылар бу хәлгә шаккатып торганнар. Һәм, күрәсең, гәрәбәне «салам суыргыч, салам тартучы» дип атаганнар.

Ләкин миңа бу атама ничектер ясалма кебек күренә.

XI гасырның бөек галиме А.Бируни сүзләренә карағанда, гәрәбәне Урта Азиягә һәм Иранга Болгардан китергәннәр (Болгарга исә ул Балтыйк буеннан килгән). Соң, шулай булгач, безнең болгарлар гәрәбәне фарсыча түгел, үзләренчә атаганнардыр лабаса! Исемсез товар булмый ич. Мөгаен, фарсыларның **кәһрубасы** борынгы болгар сүзен халык этимологиясе буенча бозудан килеп чыккандыр.

Ә болгарча бу сүз ничек яңгырады икән? Удмуртча гәрәбәне **гуривесь** дип тә атыйлар. Бәлки бу сүз борынгы Болгардан алынгандыр. Ә бәлки татарча **герәбәнкә, гервәнкә, гәрәнкә** «бер кадак чамасы авырлык үлчәме: борынгы акча берәмлеге, ун тиенлек алтын акча (урысчасы гривенник)» сүзе нәкъ шул борынгы болгар сүзенең үзгәнәседер.

Күп кенә телләрдә таралган гривенка «көмеш акча» сүзен урыс теленнән таралган, урыс телендә ул сүз **грива** «җилкәлек, муенса» (грива — җилкә, ял, муен, муенса) сүзеннән дип уйлыйлар. Муенса өчен алтын да, көмеш тә кулланылмый, ә гәрәбә бик еш кулланыла. Элекке заманнарда гәрәбәнең акча функциясендә йөрүе билгеле. Болгарга, күрәсең, гәрәбәне турыдан-туры Балтыйк буе халыклары түгел, урыслар китергәннәр һәм аны грива-«муенса» дип атаганнардыр.

Кыскасы, **гәрәбә** ул **грива** сүзеннән. Ә **кәкрәбә** һәм фарсыча **кәһруба** — шул сүзнең яңгыравыгы кайтавазы гына.

Грива сүзенең үзенә килгәндә ул урыс телендә башта ук муенса мәгънәсендә булып, «муен» һәм «ял» мәгънәләре соңрак килеп чыккан. Бу сүз рус теленә литва-латыш телләреннән кергән. Аларда **грива, гриева** «елга тамагы», нәкъ елга тамакларында диңгез буенда гомер-гомергә гәрәбә җыеп алалар — дөньяда гәрәбәнең иң күп табылган җире — Литва һәм Латвиянең диңгез буйлары.

ГОБӘДИЯ. ГӨЛБӘНӘК. ГӨРӘБИЯ.

Бу ашамлык исемнәре фарсыдан кергән. **гөбәдия** фарсыча **гөлбәдия** — кыргый гөл (роза), **гөлбәнәк** «гөл букеты», **гөрәбия** — фарсыча гөлрәбия «язгы (иртә чәчәк аткан гөл)». Башта болар барысы да роза чәчәгенең төрле сортлары шикелле итеп пешерелгән ашамлыкларны белдергәннәр. Тора-бара аларның формасы үзгәргән кебек. Аларны белдергән сүзләр дә үзгәрә барган.

Фарсы кухнясы татарларга Алтын Урда заманнарында бик көчле тәэсир иткән. Фарсылар ашамлыкны бизәп ашарга яраталар.

ГӨЛЕСТАН ҺӘМ ГӨСЛӘ.

Татар фольклорында (мәсәлән, «Заятүләк белән Сусылу» дастанында) гөлестан дигән кыллы музыка әсбабы искә алына.

Гөлестан сүзе, гомумән, уен коралын түгел, чәчәкләр, гөлләр бакчасын белдерә. Дастандагы гөлестан исә фарсыча **гүселдан** «гөслә тартмасы (футляры)» сүзеннән булса кирәк. Фарсыча **гүс, күс**, гарәпчә «күс» «литавр», татар китабы «Кыйссаи-Хәтамтай» телендә (Казан, 1875, 9 бит) (музыкантлар) күсләренә ордылар диелә.

Урысча **гусли** сүзен этимологлар (Фастяр, Шанский һ.б.) **гудеть**, «гүләү» сүзе белән бәйлыйлар. Шуннан чыгып татарча **гөслә**, чувашча **кослә**, марича **күслә** урысчадан алынган дип уйланыла. Ләкин иске татарча **күс**, гарәп-фарсы телләрендәге **күс, гүс** башкача фикергә дә урын калдыра. Иске төрекчә **гүсил** «гөслә» славян телләреннән булуы ихтимал, әмма **гүс, күс** тамырыннан төрки телләрдә дә ясалуы мөмкин.

Р.ӘХМӘТЬЯНОВ,
филология фәннәре докторы.

И туган тел...

1995 ел 29 сентябрь № 2 (25)

Татарстанның халык язучысы Гариф Ахуновны, олы юбилее уңаеннан, «И туган тел...» дә ихластан котлый, телебез хакына гомерлек тырышлыгы өчен рәхмәт әйтә, тел энҗеләрен халыктан табып, аңа ук кайтара баруда тынгысызлык, сәламәтлек, сүнмәс илһам тели.

Сәхифәбезнең нәкышләренә без Гариф Ахунов табып, үз әсәрләрендә кулланган, шулардан Нәкый Исәнбәтнең өч томлык «Татар халык мәкальләре»нә теркәлгән мәкальләрне тәкъдим иттек. Менә аларның янә кайберләре генә: Бөтен кешенең хәтерен берьюлы хәтерләп булмас; Үткәнлеккә бик үткен, бия танавын ник үптең? Авыл башы манара, акыл башы замана; «Белмәгән» дә «күрмәгән» — мең бәладән котылган һ.б.

Тилегә тиле дисәң, тигәнәк буе сикерә

Мулла янында мулла, юрга янында юрга

Киләсе саннарда:

- Анкета дәвам итә: Сез нигә татарча укырга карар кылдыгыз?
- Туган телне — гамәлгә! Парламент тыңлаулары булачак — фикер, тәкъдимнәрегез бармы?
- Бишек җыры. Конкурс дәвам итә.
- Тел кабинеты. Фикер алыша башлыйбыз.
- Сөйләмият дәресләре.
- Агач — авыз, балта — тел.
- Нәниләргә укыгыз. Балалар иҗаты һәм бүтәннәр.

Сәхифәнең мөхәррире Илдар НИЗАМОВ.
Адресыбыз: 420503, Казан, Бауман урамы, 19
«Мәдәни җомга», «И туган тел...»

Ләбибә Ихсанова

Ятимкәй

/хикәя/

Рәхиләнең башында ни яхшыдан, ни яманнан берниндн уй юк иде. Вагон тәрәзәсеннән күренеп калган алма бакчаларын да, яртышар чакрымга сузылган тимер юл составларын да күңел күзе түгел, маңгай күзе белән генә карап бара. Янәшәсендәге хатыннарның сөйләгән сүзе колагына керә, аңына килеп житми. Табигатьнең дә була бит шундый тын чагы: «Җил дә исми, яфрак та селкенми» дигән кебек, галәмәт зур калпак астында калгандай оеп яткан мәле. Күп тә үтмәс, зилзилә кубар да бар нәрсәнең астын өскә әйләндереп ташлар кебек тә түгел. Поезд туктаган арада вагонда ыгы-зыгы булып ала, кай арада кеше күбәеп-тыгызланып китә, кайчагында бушаеп-иркенәеп кала. Шуны да сизми Рәхилә. Алай дисәң, зиһене бөтенләй үк йоклап та бетмәгән икән әле. Үзенең тукталышы якынлашуга, билгесез бер көчтән хәбәр алган кебек, кинәт кабаланып чыгарга әзерләнде.

Ике кулына шактый авыр ике төен тотып, бакча капкасыннан кергәндә, каравылчы өе янында жыелып торган хатыннарны күреп тә әллә ни гаҗәпләнмәде. Исәнләшеп кенә китәргә уйлаган иде дә, кешеләрнең борчулы йөзләре тукталып калырга һәм сүзләренә колак салырга мәжбүр итте:

— Ай-һай, кеше булырмы икән?

— Дачадагы һава да килешмәәч...

— Алар күргәнне күрсәң...

— Ходай язмасын, дип әйт.

— Ятимкәй жылый да жылый. Бер кемгә килми. Ризык та алмый.

— Эт жылагач, жүнлегә түгел инде ул...

— Яманга юрама, кеше авырмый тормас.

Рәхилә бу сүзләрдән һични аңламаса да, начар хәбәр ишетәсен сизенеп:

— Берәр хәл булдымы әллә? — дип сорады.

— Әмбиләне «скорый» белән алып киттеләр. Башына кан сауган.

— Кан басымы өч йөзгә житкән, ди.

Болдыр басмасында бөгәрләнеп яткан болонка нәселле көчек, хатыннарның сүзен аңлаган кебек, эчтән сыкрап чыккан нәзек тавыш биреп куйды. Әллә шушы хәсрәтле шыңшу, әллә инде Әмбиләнең каты авырып китү хәбәре күкрәк турыннан пычак белән сызып алгандай итте. Рәхилә, хәлсезләнеп, утырыр урын эзләде. Тапмагач, Ятимкәй янына чүмәште. Сизелер-сизелмәс калтыранып яткан көчеккә кулын салды. Бармаклары белән аңа сак кына кагылды, йомшак иркәләп сыйпады. Ятимкәйнең хәсрәтен генә җиңеләйтә алмады. Ничек кенә назласа да, хужа хатынның кулы түгел иде ул. Ятимкәй аның кулын йөз генә түгел, мең кеше арасыннан аера алыр иде. Аның кулларыннан килгән жылы сөт исен башка бер кайда да тойганы, тәмле диңгез балыгын, куырган итне башка бер кулдан да шулай теләп ашаганы булмады. Хужа хатын алдына менеп яткан көчекнең ак бияләй кебек салынып төшкән колак артын кашыр, Ятимкәй шул назга оеп күзләрен йомар һәм төшендә күбәләкләр куып уйнаган чагын күрер иде. Рәхиләнең бармакларыннан килгән жылы агымны да сизде ул. Яхшылык өмет итеп, ышаныч белән башын күтәреп карады. Кая алып киттегез минем яраткан хужамны, ник алып киттегез, дип сорый кебек иде аның күз карашы. Мөлдерәмә яшь тулы күзләр хатынны тетрәндереп жибәрде.

Рәхилә Әмбиләне әле кичә генә күргән иде. Ашыгып поездга чыгып барышы иде аның.

— Исәнмесез, Әмбилә, — дигән дә, жавабын да көтеп тормыйча, йөгереп диярлек узып китте.

Ник ашыга икән бу кеше дигәнең? Максатыма ирешәм, табам, тотам, булдырам дия-дия гомере буе кабалана. Сәгатьләрне генә түгел, көннәрне, айларны, елларны этеп-төртеп үткәрә. Шул көннәрнең кире кайтмасын, гомеренең кыскаруын гына уйламый. Ни үкенечләр кала шулай ашыгып үткән юлларда. Рәхиләгә дә, бер генә минутка туктап, Әмбиләнең хәлен сорашырга иде дә бит, бер жылы сүз әйтсә дә йөрәгенә дәва булыр иде, бәлки. Күрде бит ул аның, гажиз булып, башын түбән иеп, уйларга батып утыруын. Ашыкты шул, соңгы поезд китә дип белерсең.

...Бакчага яңа каравылчы алганнар дип ишетсә дә, үзен күргәне юк иде әле Рәхиләнең. Көннәрдән бер көнне аларның дача өйләрен караклар басып чыкты. Ат югалгач абзар бикләгән кеше кебек, шул турыда әйтергә дип керде ул аларга. Ул көнне дә шулай башын учына салып, өстәл янында утыра иде Әмбилә. Аңа күз төшерүгә үк инде олыгаеп килгән бу хатынның бик үк бәхетлеләрдән булмавын аңларга мөмкин иде. Хәер, кайда да булса үз почмагы, яхшымы-яманмы, шунда жайга салынган тормышы булган кеше тик торганнан, житмеш жиде төрле холыклы адәмнәрнең көен көйләп, юк кына эш хакына бакча каравылчысы булып керәме соң инде. Йә ялкау, йә эчкече, йә төрмәдән чыккан кеше генә андый эшкә алына дип ышана иде Рәхилә. Әмма бу ханымның чалара башлаган чәче, әллә инде моң тулы зур күзләре, ә, бәлки, олпат гәүдәседер, ирексездән хөрмәт уятты, нәселдән килгән затлылыкны тоярга мәжбүр итте. Кирә-керүгә үк борчуын әйтергә ашыкмады Рәхилә. Сөйләшә торгач, ирле-хатынлы бу кечкенә гаиләнең, булган барлык мал-мөлкәтләрен калдырып, Грозный шәһәреннән Арча якларына кайтып егылуларын, анда төпләнеп калырга жай тапмыйча, шушы бакчага килеп урнашуларын белеп алды да, үзенең кысыр хәсрәтен әйтергә бөтенләй көче житмәде.

Бакча хужалыгын бик тәртипле тоттылар алар. Бер вакытта да су өзелеп тормады, утсыз да интекмәделәр. Әмбиләнең ире Хәмзәнең кулы эш белә иде. Кайсысына су торбасын төзәтергә, кемгәдер түбә ябарга, кадак кагарга булышты. Әмбилә бакчадагы хатыннарга Кавказ халкындагы аш-суларның серен өйрәтте. Яңа жиргә ияләшеп, беркадәр җайлашып киткән кебек булдылар. Әмбиләнең күзләрендәге сагышны, йөрәгенең әрнүләрен генә берни баса алмады. Кешеләр белән сөйләшеп торганда да, онытылып, күңеле белән әллә кайларга китеп бара торган булды.

Менә ярты ел инде бер үк күренеш күз алдына килеп интектерә аны: ишек алды уртасында, сасы күкерт исе бөркеп, снаряд чокыры ыржаеп тора. Чиләк-чиләк жимеш бирә торган өрек агачы урталай сынып жиргә ауган. Өйләренең бер ягы убылып төшкән. Сервант, өстәл, урындыклар берсе өстенә берсе өелгән. Тәрәзә пыялалары челпәрәмә килеп идәнгә сибелгән. Ишек төбендә канга баткан эт үләксәсе ята.

Иртәдән үк авырып тора иде бахыр. Менә-менә балаларга жыена иде. Әмбилә иске чүпрәк жәеп, аңа урын әзерләде. Хәзер үкенеп бетә алмый: урынын башка жиргә салса, бәлки, исән калган булыр иде. Сыңар тупсага эленеп калган ишекнең очлы почмагы аның башына батып кергән. Үлгән этнең ике имчәгеннән жылы сөт тамып тора. Яңа туган жан иясе абына-сөртенә килеп, әнкәсенең имчәген эзләп тапты, йотлыга-йотлыга имә башлады. Үзе рәтләп суыра да белми, тончыга, төчкерә, башын чайкый, юеш борынын тагын имчәккә төртә. Менә ул имеп туйды. Авыраеп китте. Әнкәсенең әле суынып өлгермәгән тәненә аркасын куеп бөгәрләнеп ятты. Әмбилә аны нәкъ менә шул мәлдә күреп алды. Шул чагында тетрәндергеч бер минут кичерде ул.

Әле күзе дә ачылып өлгермәгән, ап-ак йоннары юештән бөдрәләнеп торган көчекне кулына алды да күкрәгенә сыендырды.

— Ятимкәем, ятимкәем минем,— дип пышылдый иде аның кансыз иреннәре.

Ул төнне дә, аннан соңгыларында да алар күршеләренең чоланында кундылар. Бер төнне коточкыч төш күреп уянды Әмбилә. Мусаның бәләкәй чагы икән. Әтисе ясап биргән агач ат белән әле генә өйдә уйнап утыра иде. Ни арада чыгып снаряд чокыры кырына килеп басакан. Башын иеп түбәнгә карап тора. Кулында агач мылтык. Әнисе тәрәзәдән:

— Муса! Кит аннан, егыласың бит! — дип кычкыра. Ә Муса ишетми. Әмбилә улы янына йөгереп чыкмакчы була, ләкин ишекне ача алмый. Аптырагач, тагын тәрәзәгә килә. Муса инде чокыр авызында ук тора. Менә ул чайкалып китте, кулыннан мылтыгы төшеп, түбәнгә очты, малай нинди кодрәт беләндер егылмый калды.

— Улы-ы-ым! — дип җан ачысы белән кычкырып жибәрүгә, үз тавышына уянып китте Әмбилә. Шабыр тиргә баткан, йөрәге дөп-дөп кага.

Иртән күрше хатынга шул төшен сөйләгән иде.

— Сугыш бетәргә булсын. Мусаның мылтыгы төшеп киткән бит, үзе түгел, — дип яхшыга юрады тегесе. — Исән булыр.

Аларның бердәнбер уллары, тау бөркете кебек кыю Муса чечен гаскәрләрендә сугыша. Баштарак кайткалап йөри иде. Айга якын инде күзгә-башка күренгәне юк. Ә сугышның ахыры күренми әлегә. Шәһәрнең үзәген танырлык түгел, жимерелмәгән йорт калмаган. Федераль гаскәрләрнең утлары шәһәр читендәге урамнарны да эзләп тапты инде. Дөп тә дөп атышу. Әле бер, әле икенче йорт яна. Зиратта яңа каберләр күбәйде. Әмбиләләр тирәсендәге гаиләләрнең кайсылары тау араларындагы авылларга, туганнары янына күченеп китте, кайберләре аннан да ераккарак. Хәмзә дә туган ягы Татарстанга кайту турында бер генә әйтмәде хатынына. Ләкин кайсы гына ана ут эчендә йөргән баласын ташлап китә алсын соң инде.

Болай яшәп булмаслыгын ачык белгән Хәмзә, улын эзләп табарга да, икәүләп Әмбиләне күндерергә кирәк дигән карарга килде. Мусалар отряды торган жирне чамалап белә иде. Атна-ун көн эзләп йөрсә йөрде, теләгенә иреште ул. Йа Хода, исән икәнсең, дип улын кочагына алды. Командирыннан сорап, бер генә көнгә әнисе янына кайтып килде егет. Өчәүләп утырып киңәшкәч, сугыш бетүгә үк артларыннан кайтып житәргә дип Мусадан вәгъдә алгач, Әмбилә, ниһаять, туган-үскән жирен ташлап китәргә мәжбүр булды. Киткән чакта Муса аяк астында бөтерелеп йөргән көчекне алып сөйде дә әнисенең кулына бирде.

— Ятимкәйне калдырмагыз. Үзегез белән алыгыз, — диде.

* * *

..Бик авырлык белән иялөнеп килә иде Әмбилә яңа жиргә. Кичләрен өй түрендәге эскәмиягә чыгып утыргалый ул. Уйларының авырлыгын күтәрә алмагандай, башы салынып төшкән хатын янына Рәхилә дә килгәли. Алмалары пешә башлаган бакчаларга сүзсез генә, тын гына карап утыралар. Шундый бер кичне Әмбилә:

— Безнең өрек агачы да жимеш биргән булыр иде, — дип, авыр сулап куйды һәм, янында кеше барлыгын да онытып, тагын үз эченә бикләнде. Аның күңеле Муса янына китеп барган иде.

Хатынның сагышы никадәр көчле булса да, аяктан ук егар дип берәүнең дә башына килмәде. Бакчадагыларга бик авыр тәэсир итте бу хәл. Аның хәлен белергә дип, көн дә Хәмзә янына кереп чыгалар. Сабагыннан өзеп кенә кура җиләге, яңа кайнаткан варенье, башка тәм-томын китерәләр. Әмбилә генә болар турында белми. Аңар хәзер бар да бер инде. Хәтта сөекле улы Муса белән дә аралары мәңге барып житмәслек ерак. Ком баскан чишмә кебек туктыйм, бетәм дип типкән хәлсез йөрәге дә хәрәкәтсез гәүдәсе генә ята палата койкасында. Ни тырышсалар да табиблар әҗәлдән алып кала алмады, атна-ун көн дигәндә, аңына килә алмыйча дөнья куйды Әмбилә.

Әмбилә сәламәтләнеп кайтканчы дип, Рәхилә Ятимкәйне үз янына алган иде. Ул төнне көчекнең борчылуына чыдарлык булмады. Ишекне тырный-тырный чинады. Аптырагач, Рәхилә аны тышка алып чыкты. Ятимкәй кулдан төшүгә, алдын-артын карамыйча, өйләренә таба чапты. Аның кыска аякларына каян шундый житезлек килгәндер.

Ә иртәгесен Әмбиләнең үлгән хәбәрен китерде Хәмзә.

Мәрхүмәгә мәчеттә җеназа укыдылар. Озата килүчеләр күп иде. Яңа кабер өстенә таудай булып бакча чәчәкләре өелде. Көчләп тагылган мәгънәсез сугышның тагын бер корбаны үзенең иленнән еракта мәңгелек йортын тапты дип көрсенде кешеләр. Чечня фажигасе аларның үз капкаларын килеп каккандай булды.

Ятимкәйне Рәхилә бөтенләйгә алырга теләгән иде. Хатын-кыз кулында тәрбиялерәк булыр дип Хәмзә дә каршы килмәде. Әмма Ятимкәй мәрхүмәне алып чыгып киткән өйне ташлап китәргә теләмәде. Ул инде күбәләкләр куып та уйнамый, аягына урала-урала атларга комачауалап, Хәмзә белән бакча буйлап йөреп тә килми. Әмбиләнең кайтуын көткәндәй, көннәр буе болдыр басмасында ята. Аяк тавышын ишетсә, өмет белән башын күтәреп карый. Чит кешене күргәч тагын боегып кала.

● КОНКУРСКА

МИЛЛИ КИНО

Рабит БАТУЛЛА

ХӘТӘР ХӘТЕР

«Аңга килү» фильмын карагач

Карләш халыклардан иң алда нәфис фильмнар төшерә башласа да, татар тәки киногa тиенә алмады Кайчандыр театр сәнгатенә бабаларыбыздан өйрәнгән халыклар театрлы да, кинолы да булды Безгә шул документаль фильмнар студиясен генә рөхсәт иттеләр Әлеге студия чыгарган фильмнар да нигезлә татар кулында булмады Шулай да киночыларыбыз иҗат иткән матур фильмнар юк түгел Харис Фәхретдин, Виктор Беспалов (телестудия) һәм берничә режиссер эшләгән кинотасмаларны карап, зәукый ләззәт алган идек Кызганыч, алары да татар халкының фаҗигасе, бүгенгесе, киләчәге турында тәфсилле әсәрләр түгел иде

«Нәфис фильмга әле тәҗрибә, көч-куәт, актерлар һәм дә химаяче юк Боларны көтеп ятканчы, тарихи фильмнар, бөек шәхесләр турында документаль тасмалар төшерик, дөрес тарихны сөйләп, күрсәтеп, халыкның күзен ачыйк!» - диеп күпме ачындык. Булмады

Бу ачлыктан безне кем килеп йолыр? Шундый фильмга ихтыяҗ, тарихыбыз-ватаныбыз турында уйлап җирсү үзенә күрә бер чиргә әверелеп, шул чир йоккан буын гүр иясе булып бетте Инде нәфис фильмнар, кантарлы мәсьәләләр күтәргән документаль тасмалар кирәклеген дә оныттык, дигәндә генә киночылар уяна, аңга килә башлады Сценарийлар да языла тора, беренче адымнар да ясала тора, шөкер

Сәнгатьтә яңа әсәр белән танышканнан соң тетрәнү халәте сирәк була Рәфкать Исрафилның «Галиябану» спектаклен карагач, халык өнсез калып, хиссияттән аерыла алмыйча, бер кавым тын утырган иде Шулай ук Марсель Сәлимҗанның «Сүнгән йолдызлар»ы да караган саен җирсетә, тетрәндерә торган спектакль иде Туфан Миңнуллинның «Әлдермештән Әлмәндәр»е, Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыяте», Бакый Урманченың «Сагыш» сыны халык язмышын үз иңнәренә күтәргән шаһ әсәрләрдән санала

Күптән инде шулай ләззәтле сызлану аша тетрәнгән юк иде

Чаллы режиссеры Нәфис Гафиев әзерләгән «Аңга килү» фильмын видеода караганнан соң, мин әнә шундый тетрәнү хисе кичердем (үзне озакка сузмыйча гына, фильмны иҗат итүчеләргә мөхтәрәм режиссер Нәфис Гафиев әфәндегә, язучы Айдар Хәлим, оператор Георгий Казанцевка, малтабар-химаяче Бертуган Кашаповларга һәм бик күп көч куйган башка фидакарьләргә олуг рәхмәт белдереп

Кантарлы, шәп фильм иҗат иткәнсез! Бабаларыбыз рухын нәҗестән пакьләп, сез үзегезнең дә милләтебез каһарманнары икәнлегегезне исбат иттегез! Машаллаһ! Афәрин! Йөз яшәгез! диеп тәмамларга да булыр иде, әмма зур куаныч белән уртаклашмыйча йөрәккә тынычлык иңмәс шикелле.

.. Экран яктыруга шомлы тантана илә музыка ишетелә башлый Бу музыка катлаулы, буталчык, ялганы-чыны укмашып беткән тарих төпкелләреннән килә һәм олы язмышлар, кара тәкъдирле шәхесләр, нахакка рәнҗетелгән халык турында сөйләргә вәгъдә итә Шул мохиттә экранда татар халкының үлемсез символы, табигать сакчысы, миһербан иясе, безнең генә түгел, бөтен төрки халыкларның нәсел башы Акбүре пәйда була Без - әнә шул Акбүре токымыннан Акбүредән туган халык нәҗес була аламы?

Кинәт дала җиле исә Җелекләргә үтеп керә торган бу ачы җил мохитендә мәшһүр артистыбыз Ирек Баһман авазы, гасырлар авазы яңгырый

« Милли дәүләтебезне яклап һәлак булган каһарман бабаларыбыз истәлегенә багышлана »

Дала буйлап кылганнар йөгерешә Офыкны кып-кызыл шәфәкъ биләгән Ниндидер шом бар табигатьтә Ирексездән Такташның ачыргаланып кычкырганы колакка бәрә

Күк читендә канлы пәрдә,
Әллә кемнәр
«Таң», диләр,
«Таң түгел ул, җиргә төшкән
Шомлы каргыш, кан», диләр...

Иске Казан, Ислам Татар Казаны манзаралары, мәчетләр, кәрвансарайлар, хансарайлар, бәкләр, мирзаларның күккә ашкан мәһабәт йортлары Күктә яңа туган Ай Һилал йөзә.

Фильмның экспозицион өлеше әнә шулай вәгъдәле башлана бу фильм-сабак, бу фильм-сагыш, бу фильм-гыйбрәт.

Шушы мохиткә ялгыз җайдак үсмер җегет килеп керә Ул җан-фәрманга чабып барганда, кинәт арт аякларына үрә баскан айгыр өстеннән җиргә егылып төшә Яшь айгыр серле таш бал-балдан курыктымы, әллә үсмер җегетнең йөрәгенә дошман угы баттымы? Ни булды? Һәлакәт! Әле тормышта матур хыялларыннан башка һич тә явызлык кылырга җыенмаган бу оланны кем үтерде?

Әлбәттә, бу символ Үтерелгән яшь кеше ул Бөек Болгар дәүләте. Чәчәк аткан яшь мәмләкәтне кем җимерде, кем Идел дәрьясындагы Миһербанны үтерде?

Фильмны шартлы рәвештә дүрт өлешкә бүлеп карарга булыр иде Болгар дәүләте турында хикәят, Алтын Урда чоры турында хикәят һәм Казан ханлыгы турындагы хикәят. Соңгысы, дүртенче өлеше халкыбызның бүгенгесе-киләчәге турында кисренке уйланулар

Болгар, Алтын Урда, Казан дәүләтләренең шөһрәте, бөек мәдәнияте, табигать байлыкларының кешүе кулы, баскынчылар кылычы белән юкка чыгарылганлыгы турында ачынып сөйли бу фильм, һәм «... бердәмлек җитмәү» аркасында шундый мөшкел кәлдә калганбыз, дигән фикер, мичәүгә җигелгән ат кеби, фильмның буеннан-буена, буыннан-буынына шул яман холык итәк чабуга ябышып бара «Әгәр Казан халкы бердәм булса, аны берниңди дошман да җинә алмас иде», диләр фильм авторлары

Бу гыйбарә әле дә искермәгән, бүген дә без моны гелән кабатларга, истә тотарга тиеш Авторлар аеры-чөере яшәүне, бер татар халкы өстенә генә аударымыйча, «төрки халыклардагы таркаулык»ның гомум гарасатка китергәнен фильм дәвамында басым ясап, зиһенгә үткәзәләр. Төркиянең, Кырым, Әстерхан, Себер, Касыйм ханлыкларының Казанга җинаятьчел гамьсезлектә калуларын искәртәләр

Бүген дә шул ук хәл, шул тарих кабатлана түгелме соң?

Татарстан үзенең бәйсезлеген игълан иткәч, кайсы тугандаш мәмләкәт безнең бу фәгалиятебезне хуплады? Чечнстан фаҗигагә дучар ителгәч, кайсы җөмһүрият ачыктан-ачык ярдәмгә ашыкты?

Казан бөтен мөселман-төркиләр һәм урыс-христиан булмаган халыклар арасындагы күперне тотып торучы субай баганасы ролен үтәп килде Субай багана егыла икән, ташкын бөтен күперләрне себереп алып китәчәк Әйтик, Төркия дигән баганаы кисеп аударсалар, Иран, Әфганстан, Урта Азия, Себер Кавказ Кырым, Казан баганалары да аварга мөмкин 1552 елда Казан баганасы киселгәч, шундыйрак хәл булмадымыни?

Кинода бу ап-ачык күрсәтелгән Экранны тутырып Тилергән Кызыл Үгез (СССР картасы) койрык чәнчеп, дулап чаба Аның карынында ничә милләт кайный? Шуннан соң каберләр, каберләр .. Музыка тына, диктор туктап кала Тынлыкта каберстан манзарасы Тәэсирле, мәгънәле кадрлар. Сүз кирәкми, музыка кирәкми Кабер ташлары үзләре сөйли Әче тәкъдир, гыйбрәтле язмыш.

Шушы төштә режиссер яңа темага күчеп:

Әмма без уңай үзгәрешләргә дә куана белергә тиеш! дип искәртә

Һәм чыннан да хәлкәйләребез никадәр генә мөшкел булса да, яшибез ич, яшибез! Әнә, Ленин көтепханәсе «Милли китапханә»гә әверелгән, әнә, Печән Базары мәчете торгызылган, әнә, Әҗем мәчете яташханә булудан туктап, архитектура сәнгатебезнең гүзәл үрнәкләре рәтенә кайтарылган .

Мәгълүм ки, татар халкы үз бәгыреннән каерып алып, байтак даһиларын ятларга бирергә мәҗбүр булган Дөньякүләм мәшһүр галим Һарун Таҗи (Ырынбур җегете), Мстислав Келдыш (Балтыйк буе татары). Роальд Сәгъдиев (Казан), София Гобәйдуллина Рудольф Нуриев (Уфа), Чыңгыз Әхмәров, Латыйф Хәмиди, Алисә Галләмова, Гата Камский, Артур Йосыпов, Ирек Мөхәммәдов һәм башка бөекләребез урыска, шулай ук Америкага, Франциягә, Урта Азиягә, Төркиягә (Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый, Акдәс Курат, Зәки Вәлидиләр) хезмәт иткәннәр, хезмәт итәләр

Мактанычмы бу, әллә милләтнең хурлыгымы?

Карамзин, Державин, кенәз Йосыпов, Шереметьевлар татар булган, дип корыга куанучылар байтак әле хәзер дә

«Аңга килү» фильмында бу сорауга да җавап бар: үз милләтенә хезмәт итүдән гайчандырылганга күрә алар ватаннан, халыктан читләшергә. Аллаһ биргән талантларын кире кайтарып алалмаслык рәвештә ятларга бирергә мәҗбүр ителгән!

Әле, шөкер, Исхакый, Акчура, Курат, Кошай, Арат, Туган һ б лар кеби татар галим-әдипләренең әсәрләре Төркиядән янә үз ватаны Татарстанга кайта башлады Аларның мирасы татар халкының мирасы Бу бөекләребезнең әсәрләрен ана телебездә күпләп чыгару, дәреслекләргә кертү, киң җәмәгатьчелеккә таратуны дәүләт күләмендә кичекмәстән башкарырга кирәк

Фильм алга таба азатлык өчен көрәшнең бүгенге торышы турында сөйли Экранда каһарманыбыз Фәндәс Сафиуллин җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлеге турындагы Декларацияне бәян итә, беренче Президентыбыз Минтимер Шәймиев бөтен милләт вәкилләрен, Татарстан халыкларын бәйрәм белән котлый Бәйрәм куанычын экранда Хәтер көне, матәм нәмазы алыштыра. Халык Сөембикә манарасына агыла

Чаллылар килә. Кол Шәриф сәед, Кол Шәриф шагыйрь әйдәп, газаватка алып киткән яугирләрдәй. Чаллы җегетләре азатлык байрагын тотып, Бөек Ватаныбызны саклаганда шәһит киткән бабаларыбыз янына ашыга!

Татар гомере буе бәйнәлмиләл (интернационалист) милләт булды Бәлки артыгы белән дә Чөнки аның бәйнәлмиләллеге күп вакыт үзенә зыян эшләде Бу фильмны иҗат итүчеләр дә бәйнәлмиләл булудан туктамаган: экранда чуваш, мари, удмурт халыкларының, урысның гаделлек өчен һәлак булган каһарманнарына да рәхмәтлелек күренә Шулай! Вакланмыйк! Урыс өммәтеннән булган Худяков, Чернышевский, Гумилев, Сахаровларга без оныкларыбызда бөек ихтирам тәрбият итәргә тиеш

Тагын кайтып, мин фильмдагы профессиональ режиссура вә кинооператорлык сәнгате турында әйтмәк булам. Бу монтаж эшләрендә бигрәк тә ачык күренә Иске кинокадрларны урынлы сайлау, җимерелгәнгә кадәр бөтен дөнья сәяхәтчеләрен сокландырган мәһабәт Казан манзарасының галимнәр, рәссамнар, тарихчылар тарафыннан торгызылган рәсемнәрен оста файдалану, мәрхүм галим-рәссам Фуат Вәлиев ясаган Иске Казан күренешләре — барысы да фильмны бизи, әсәрнең ышандыру көчен арттыра.

Сөембикә манарасындагы Һилал (Ай) өстендә кара каргалар өеренең бөтерелүе әллә нинди имәнгеч чагыштыру, күзаллауларга этәрә Бу символ, бу кисәтү Бүгенге Сөембикә өстендә дә кара козгыннар җыела түгелме? Бу кадрларны кабатлау-монтажлау белән тагын да көчәйтергә кирәктер.

«Аңга килү» фильмын һәр елны Хәтер көнендә экранда күрсәтү ихтыяҗы бар Һәм аны күбәйтеп сату-таратуга мохтаҗлык көн кебек ачык Керсен хакыйкать һәр өйгә, һәр күңелгә Фильмны төрле телләргә тәрҗемә итеп, чит илләге туганнарга җибәрү мөһим Ләкин боларны эшләр алдыннан авторлар кинотасмалардагы бәгъзе урыннарга игътибар итсен иде

Киемнәрнең фәкыйрьлеге, артык дәрәҗәдә гадилеге, җайдак җегетнең (Бөек Болгар символының) киндерә тезгенле, юка йөгәнле атта йөрүе, гап-гади чүпрәк чалбарлары, кара эш итекләре, карга оясыдай бүреге, Сөембикәне гәүдәләндерүче кызның да клуб үзешчәннәре генә киеп уйный торган күлмәге, бизәнү әйберләренең ярлылыгы күңелдә ризасызлык уята Соңгы сугышка чыгарга җыелган шәкерт-яугирләрнең кыяфәтләрен дә яңадан игътибар белән күздән кичерергә кирәк. Эре планда татарга хас йөзләр күбрәк күренсен иде. Чибәр халык икән татарлар, дисен ятлар

Музыка нигездә уңышлы Ләкин сүз, музыка, хәрәкәт берьюлы булса, игътибарны чәчә. Кайчак колак та ял итәргә мохтаҗ Хәрәкәтнең, сүзнең көче җитмәгәндә генә ярдәмгә музыка килсә, бәлки, уңышлырак булыр шикелле. Утыз-кырык ел элек экранны кирәксә-кирәкмәсә дә музыка белән тутыралар иде Фактик материал, гүзәл мәчетләр, үзәк өзгеч хәрабәләр үзләре музыка лабаса

Фильмның сүз өлеше һәйбәт, ләкин бер-ике урындагы чатаклык колакны рәнҗетә Болгар шәһәре җимерелгәннән соң, диктор «башка күтәрелә алмый», ди Миңа калса, бу төштә «кабат» сүзен куллану урынлы «Ярымай» сүзе «полумесяц»тан күчте Татарның өлкән буын вәкилләре «Тулган ай», «Һилал» сүзләрен куллана иде Һилал яңа туган, яки яртылаш тулган айны аңлата Һич югында «Ай» сүзе генә булса, колакны тишмәс иде кебек

Титрлардагы татар исем-фамилияләренең «Гайнутдинов, Шакуров» диеп язылулары да безнең әле һаман изелү астында яшәвебезне сөйләмиме икән?! Без өлешчә генә түгел, тулысы белән аңга килергә тиеш

Режиссер һәм аның теләктәшләре фильмны гел сыктау, гел үкенү белән генә сугармаган Аттан егылган җайдак аңга килә, аягүрә баса, ләкин ни өчендер ияргә менми, атына сыенырмы, атын сөеп ме, хәрәкәтсез тора, камера кош очар биеклеккә күтәрелә, атының яңагына үз яңагын куйган җегет аста, дала уртасында кала.

«Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаганмы?» дигән сорауга Тукай

Һушы гына киткән! дип җавап биргән иде. Һушы гына язган булса, ул бер айныр, исенә килер Татар милләте үлем җәрәхәте алып, аңын җуйган, ахрысы Үлем җәрәхәте алган җайдак җегет фильм азагында аягүрә басты, ләкин әле ул ияргә менә алмый Узар вакыт, әлеге углан хәл алыр, сәламәтләнер, тәмам аңга килер һәм томырылып чабуын дәвам итәр!

Янә бүгенге Казан урамнары, янә офыкны кызыл таң шәфәкъ били, күктә янә Тулганай балкый таң ата Яңа туган бала җылый Нәсел дәвам итә Дөньяга аваз салган бу бала кем булыр? Телен, динен оныткан манкортмы? Яисә газиз халкын бәйсез дәүләткә ирештерүче милли каһарманыбызмы ул?

Гомәр САТТАРОВ-МУЛИЛЛЕ

Ялгызлык исемнәре һәм безнең хәят

(Очерк-эссе)

(Дәвамы. Башы 9, 10 нчы саннарда).

Әмма теге яки бу торак пунктның кайчандыр башкорт кешесе, кабиләсе, ыруы, тебеге тарафыннан нигезләнүе яки башка атрибутларына нисбәтле рәвештә барлыкка килүе генә, тарихи, миграцион, лингвистик, этнографик, сословие, үзаң һ.б. факторларны исәпкә алмыйча, аны башкорт торак пункты (башлыча авылы) дип санарга тулы рәсми-юридик хокук бирми. Менә шуңа да күренекле башкорт этнограф-галиме Р.Кузеев «Происхождение башкирского народа» (Изд. «Наука», М., 1974) дигән фундаменталь хезмәтендә Төньяк-көнбатыш башкортлары турында сүз алып барганда: «Большинство нижнебельских деревень в этническом отношении смешанные: башкиро-татарские, башкиро-марийские, башкиро-удмуртские. Информаторы, перечисляя входящие в состав рода деревни, обычно подчеркивали, что «башкирской является только основа аула или его название»... С XYI в., в результате нарастающего колонизационного потока с Поволжья постепенно меняется как этнографический состав населения северо-западной Башкирии, так и направление этнических процессов в значительной части района. Численное преобладание в составе переселенцев татар дает толчок этническому развитию башкир в сторону татаризации», — дип язды (336-367 битләр). Бу тарихи хакыйкатьне инкарь итү, исәпкә алмау, санга сукмау һич тә мөмкин түгел.

XYI йөзнең беренче яртысында нугайлар тарафыннан нигезләнүдән чыгып кына Татарстанның Апас районы үзәге Апас авылын, Зеленодол районындагы Карагуҗа, Карәтмән, Күгей, Күгеш, Айдар һ.б. татар авылларын (бу ойконимнарның асылында нугайларның абас, кара, каратөмән, күгей, күгеш, айдар ыругларының исеме-этнонимнары ята) нугай авыллары дип әйтә алмыйбыз әле. Алар Казан татарлары авыллары, халкының сөйләше татар теленең урта диалектына карый.

Башкортның танылган әдәбиятчы галиме һәм язучы Гайсә Хөсәенов «Агыйдел» журналының 1994 елгы 10 нчы санында басылган мәкаләсендә «Ризаэтдин Фәхретдинов туган Кичүчат авылын, аның нәсел-нәсәбен «башкорт» ясый, башкорт итәргә тырыша.

Кичүчат авылы башкорт авылы булганмы соң? Бу сорауга җавап алу өчен сүзне танылган край белгече һәм язучы Дамир Гарифуллинга бирик: «Кичүчат авылының беркайчан да башкорт авылы булганы юк. 1781-1782 еллардагы дүртенче ревиз (халык санын алу) материалларыннан күренгәнчә, монда 92 типтәр ир-ат гомер сөргән». Мин Ризаэтдин Фәхретдиновка бер-бер төрле башкортлыкны «сыларга» тырышып карадым. Кичүчат авылында алып барылган элекке «метрика дәфтәрләре»н актаргалап чыктым, ләкин авылда бер дә башкортларны таба алмадым. Дәфен ителгәннәр (җиргә иңдерелгәннәр) арасында да, вөҗүдкә килгәннәрә (дөньяга туганнары) арасында да башкорт табу насыйп булмады. Типтәрләр, ясаклы татарлар бар. Ә менә башкорт юк. Хәер, ул яктагы авылларның кайсында гына бар икән ул асыл башкортлар?» («Ризаэтдин Фәхретдинов кем булган». «ВТ». «Әллүки» чыгарылышы. 26 май, 1995 ел).

Күрәбез ки, башкорт галимнәре, рәсми органнары, учреждениеләре һәр өтрафта өлгерлек күрсәтәләр. Башкортстандагы һәм аннан читтәге өлкә һәм республикалардагы, шул җөмләдән Татарстандагы күп кенә татар авылларын да башкорт авыллары «ясыйлар», объектив чынбарлыкка хилафлык итеп булса да, башкортныкы итеп,башкорт авыллары дип дәгъва кылалар.

Ә без — татарлар ни эшлибез? Татар авыллары татарныкы булып калсын өчен ниләр эшлибез, нәрсәләр майтарабыз? Татарстаннан читтәге татар торак пунктларын тиешенчә барлыйбызмы, бөтен Җир шарына диярлек сибелгән татар авыллары банкын булдыру буенча эш алып барабызмы? Шушы ифрат кирәкле, мөһим эш белән эзлекле, планлы рәвештә шөгыльләнәбезме? Махсус фәнни эзләнүләр, эш-гамәлләр кылабызмы? Юк диярлек.

Шушы гаять мөһим фәнни эш белән рәсми гыйльми учреждениебез — Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институты интенсив рәвештә нәтиҗәле шөгыльләнергә тиеш.

Күптомлы «Татар энциклопедиясе»н булдыру — җиде миллионлы халкыбызның, аның зыялылары, галимнәренең күптәнге хыялы, теләк-омтылышы. Шушы ифрат зур мөмкинлекне, кадерле форсатны кулдан ычкындырмыйча, «Татар энциклопедик сүзлеге» һәм «Татар энциклопедиясе»ндә бирү өчен Татар бугазыннан алып Босфор бугазына кадәр, хәтта арырак — көнбатыштарак сибелгән барлык татар торак пунктларын, татар авылларын барлап, алар турында кабул ителгән схема үрнәгендә кыскача мәгълүматлар тупларга тиешбез. Бу исә «Татар энциклопедик сүзлеге» һәм «Татар энциклопедиясе» чынлап та татарныкы, татар халкыныкы булсын өчен мәҗбүри ихтыяҗ һәм катгый таләп — зарурият та. Анда Татарстандагы барлык торак пунктлардан тыш, Русия Федерациясендәге барча татар авыллары, Казакъстан, Белоруссия, Литва, Украина, Польша, Румыния, Болгария, Төркия, Кытайдагы татар авыллары турында кирәкле мәгълүматлар урнаштырылырга тиеш. БДБ, Финляндия, Алмания, Югославия, АКШ, Австралия, Япония, Монголия һ.б. кебек илләрдә татарлар тупланып яши торган шәһәрләр һәм башка торак пунктлар турында да кыскача мәгълүматлар бирү зарур. Бөтен дөньяга, Җир шарының барлык кыйтгаларына таралган татар торак пунктларын тулысынча барлап, алар турында кыскача мәгълүматларны тиешенчә туплап «Татар энциклопедик сүзлеге»ндә һәм «Татар энциклопедиясе»ндә хәзер — XX йөз азагында бирмәсәк, алар кайчан һәм кайда бирелер?! Безгә Ходайның рәхмәте белән иңгән бу изге форсатны, олуг мөмкинлек-гамәлне кулдан һич тә ычкындырырга ярамый. Чал тарихлы татар халкына безнең көннәрдә беренче мәртәбә үзенең «Татар энциклопедик сүзлеге»н һәм «Татар энциклопедиясе»н төзү насыйп булды. Аларда бөтен дөньядагы татар торак пунктлары турында мөмкин кадәр күбрәк белешмә-мәгълүматлар урын алырга тиеш. Шулай булмаганда, алар «Татар энциклопедик сүзлеге» һәм «Татар энциклопедиясе» була алмыйлар. Без- не исә, булган мөмкинлекләрне, форсатны кулдан ычкындырсак, тарих, киләчәк буыннар гафу итмәячәк, каһәрләячәк. Менә шуңа Татар энциклопедиясе институтында шушы мөһим һәм зарури эшкә муеннан чумар вакыт җитте. Бу изге гамәлне төрле сылтаулар табып сузу яки бөтенләй алып бармау — зур гөнаһ. Моның өчен җаваплы түрәләребез шуны яхшы төшенсәләр, яхшы аңласалар иде!

Аңлашыла ки, төбәкләр, авылларыбыз тарихын өйрәнүне һәвәскәрчелектән фәнни нигезгә салыр вакыт җитте. Менә шуңа Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институтында төбәкләр (авыллар) тарихын өйрәнү бүлегән кичекмәстән ачуны заман, бүгенге тормыш үзе таләп итә.

Русиянең күптомлы төүге Зур Энциклопедиясенең беренче томын 1997 елда чыгару планлаштырыла. Төүге Татар энциклопедиясенең беренче томы да 1997 елдан соңга калмыйча, мөкәммәл сыйфатлы булып дөнья күрсә иде! Амин!

Халкыбызның тарихын, телен, этногенезын, тарихи географиясен региональ экологиясенең элекке һәм хәзерге тормышын тикшерү-ачыклауда үзеннән ифрат зур өлеш кертү мөмкинлекләренә ия булган татар ономастикасы фәнен алга табан үстерү, киң колачлы фундаменталь гыйльми тикшеренүләр белән баету. Казан дәүләт университетының татар теле кафедрасында «Төрки-татар ономастикасы һәм татар халкының этногенезы мәсьәләләре» дигән дистә елларга исәпләнгән приоритетлы фәнни юнәлеш-теманы уңышлы һәм нәтиҗәле итеп тормышка ашыру өчен:

беренчедән, кулъязма хәлендә нәшриятлар портфелендә инде берничә ел басылып чыгуны көтеп яткан монографияләрне («Татар топонимиясе» дип аталган, 30 ел гомерем сарыф ителгән, 25 басма табаклык фәнни хезмәтем менә биишенче ел инде, акча булмау сылтау ителеп, Казан университеты нәшриятында басылмыйча ята) тизрәк бастырып чыгарып фәнни әйләнешкә кертү;

икенчедән, «Татарстан Республикасы халыкларының телләрен саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт Программасы»нда татар ономастикасын фәнни өйрәнү, үстерүгә караган экспедицияләрне техник чаралар белән тәэмин итәргә, татар исемнәре һәм топонимнарының сүзлекләрен чыгару кебек мөһим эш-гамәлләрне эзлекле һәм нәтиҗәле итеп тормышка ашыру;

өченчедән, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында ономастика бүлегенең, Татар Милли Университетының татар филологиясе факультетында төрки-татар ономастикасы кафедрасын ачу;

дүртенчедән, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә җөмһүриятебезгә исем биргән татар халкының туган теле — татар теленең абруен күтәрү, дәүләт теле булу статусын тулысынча һәм мөкәммәл тәэмин итүне күздә тотып, татар телен, шул исәптән ономастикасын, академик планда җентекле итеп өйрәнү-тикшерү эшен тагын да нәтиҗәлерәк итеп оештыру һәм алып бару өчен « татар теле гыйлеме» буенча өстәмә рәвештә бер академик һәм бер әгъза-мөхбир штатлары булдырып, сайлаулар үткәрү.

Ошбу очерк-эссе язылып бетеп беркадәр вакыт узгач, әлеге дүртенче тәкъдим-таләбемә көтмәгәндә анык җавап таптым. Татарстан Фәннәр академиясенең гамәли әгъзаларын (академикларны) һәм әгъза-мөхбирләрен 1995 елның көзендә чираттагы сайлаулар булачагын хәбәр иткән игъланында («ВТ». 23 июнь, 1995 ел, 15 бит) татар теле гыйлеме һәм татар әдәбияты белеменнән бер генә вакансияле урын да бирелмәве билгеле булды.

Ни аяныч, ни кызганыч. Президиум әгъзалары һәм җитәкчеләр Татарстан Фәннәр академиясенең тиешле милли йөзе, төсмере, үзенчәлеге булуын, татар теле һәм әдәбияты фәннәренең хәзерге заман таләпләренә җавап бирерлек камил булып үсүен теләмиләр, күрәсең.

Бишенчедән, аспирантура аша ономастика белгечләре буенча мөмкин кадәр күбрәк югары квалификацияле фәнни кадрлар әзерләү ифрат мөһим һәм зарур. Моны бүгенге чынбарлык, тормыш үзе сорый, үзе катгый рәвештә таләп итә.

(Ахыры киләсе санда).

Кая барасың син, татар баласы?

Без, татарлар, элек-электән урыс изүе астында яшәп, милли горурлык хисен генә югалтып калмыйча, иман дигән нәрсәгә дә хыянәт итүдән тартынмый башладык кебек. Әйтик, 1979 елда совет гаскәрләре Әфганстанга бәреп кергәндә, анда Татарстан егетләренең дә күп булуы моңа бик ачык бер мисал була ала. Чынлыкта безнең балаларыбызның да күрше дәүләттә вәхшилекләр кылуы турында әллә нинди калын китаплар язарга мөмкин. Заманында ошбу явызлыкларны фаш иткән академик А.Сахаров СССР халык депутатлары съездында иллә дә каты мәсхәрә ителеп, вакытыннан алда йөрәк өянәгеннән үлеп китте. Ә белорус әдибәсе Светлана Алексевич үзенең «Цинковые мальчики» дигән китабы өчен хөкемгә тартылды. Бу хурлыклы сугыш нәтиҗәсендә 1 миллионнан артык әфган кешесе һәм 25 мең урыс һәлак булды. Никадәр генә кызганыч булмасын, без урыс дип атаган әнә шул «каһарманнар»ның байтак өлеше татарларга туры килә. Әлеге хурлык тамгасын юып төшерү турында кайгыртасы урында, без, мөселман халкы, Казан каласының бик матур бер урынында каһарман-интернационалистлар истәлегенә һәйкәл сала башладык. Бу үзенә күрә ярага тоз салу кебек тоела миңа. Юкса, әлеге һәйкәл ташына: «Кичер безне, Әфган җире, синең барча кайгы-хәсрәтләреңдә безнең — татарларның да гаебе зур», — дигән сүзләр чокып язарга кирәк иде.

Уйлап карагыз әле, ул сугышта үтерелгән һәр совет солдаты өчен 40 әфган кешесе үтерелде бит. Шулай булгач, безнең анда «интернациональ бурыч»ыбызны үтәдек дип, мактанырлык хакыбыз да юк.

Юк, Әфганстан җирен генә бәхетсез итмәдек без. Африкадагы күп кенә мөселман илләренең рәнҗеше дә төшмәгәе совет солдатына.

Хәзер инде менә «Аэростан» компаниясе дә Әфганстан хөкүмәтенә каршы сугыш хәрәкәтләре алып баручы «Талибан» ислам оппозициясенә сугыш кораллары ташый башлаган. Совет гаскәрләре Әфганстанны канга батырып кайтып киткәннән соң анда гражданнар сугышы башланып китте. Кем әйтмешли, бусы да безнең «интернациональ ярдәм» җимеше инде.

Әгәр шушы елның 3 августында «Аэростан» авиакомпаниясенең Ил-26 самолетын «Талибан» истребительләре Кандагарга төшереп утыртмаган булсалар, Татарстанның Раббани хөкүмәтенә корал ташуы турында берәү дә белмәс иде. Хәер, бу самолет үзенең бурычын үтәде инде. Ундүрт рейс бик аз түгел ләбаса. Дөрес, Кабул әлеге коралны Албаниядән сатып алган. Ләкин нигә дип әле безнең Татарстан самолеты чит илгә корал ташу белән шөгыльләнә? Кызык бит, яңа заман килде, хәзер корал арадашчы илләр аша озатыла. Уңайлы да, хәвефсез дә.

Татарстан Президенты «Талибан» җитәкчеләренә самолет экипажын азат итүне үтенеп мөрәҗәгать итте. Ә 25 августта «Аэростан» авиакомпаниясе, Татарстан Министрлар Кабинеты һәм дин әһелләре Талипләр белән сөйләшүләр алып бару өчен Кандагарга юл тоттылар. Мөрәҗәгать итүләр, сөйләшүләр... Алар дәвам итә.

Моңсу да, кызганыч та. Татарның йөзе тагын корымга буялды. Шундый мескен халыктыр инде без. Хәтерегезгә төшерегез әле, урыс гаскәрләре Чечняның авыл-шәһәрләрен бомбага тоткан вакытта Татарстанда көн дә төрле бәйрәмнәр үткәрелде. Алай гына да түгел, кулы канга буялган Мәскәүнең үзендә Татарстан көннәре оештыруны да кичектермәдек. Безгә бу очракта бөтен Русия патриархы Алексий Икенчедән үрнәк алырга кирәк иде. Ул, әнә, әллә кайдагы кабиләдәшләре — Босния сербларын да яклап сүз әйтә алды.

Тоткан юлыбыз сикәлтәле һәм болгавыр. Кая барасың син, татар баласы?

Локман ЗАКИР.

Мөнәсәбәт

Үз хәлеңне күршеләрдән сора

«Комсомольская правда», «Мәдәни җомга» һ.б. гәзитләрдә Равил Яһудин дигән бер татар кешесенең «Латвия законнарына түзә алмыйча» үзен-үзе үтерүгә барып җитүе турында август аенда гына берничә мәкалә басылды.

Аяныч хәл, әлбәттә. Бер яктан, күрәсең, ул ир сабырсызрак булган, икенче яктан, Латвия хакимиятчеләренә дә тел тидерми булмый. Алар. һичшиксез, кеше язмышына карата ваемсызлык күрсәткәннәр. Ләкин менә шул вакыйгага бәйләп латышларны шовинизмда, милләтчелектә гаепләү урынлы микән? Латышларның хәленә дә кереп карыйк.

Латышларның тулаем саны чама белән башкортларныкына тиң. Шундый аз санлы халык булуларына карамастан, алар арасыннан әллә никадәр данлыклы фән, сәнгать-әдәбият әһелләре, спортчылар, җәмәгать эшлеклеләре чыккан. Октябрь түнтәрелешенә кадәр латышлар Русия империясендә иң мәдәни халык була (татарлар икенче урында): җан башына нисбәтән матбугат, мәктәпләр һ.б. буенча алар исемлек башында тора. Латвиянең мөстәкыйль булып яшәгән елларында (1918-1940) латыш халкы зур уңышларга ирешә. Бу хәл урыс империясен тулысынча торгызырга теләүчеләрнең ачуын кабарта. Латвиягә каршы махсус коткы тарату кампаниясе алып барыла. В.Маяковскийның «Теодор Неттега — пароходка һәм кешегә» дигән шигырендә «Россиясез һәм Латвиясез» бергә яшәү һәм, әлбәттә, урысча сөйләшү идеал итеп куела. Шул елларда безнең М.Максуд «Төрмәдән Ленин иленә»дигән нәсерендә Латвияне тоташ төрмә итеп тасвирлый (ул чорларда чит илләр турында берни белмәсән дә, алар тормышыннан әсәрләр язу мөмкин санала иде). Бу агитация-пропаганда Латвияне — Балтыйк диңгезенең ачык капкасын басып алуга идеологик хәзерлек ролен үти. Икенче Бөтендөнья сугышы чорында латышлар коточкыч бәла-казаларга дучар булды. Латыш халкы шактый кимеде. Сугыштан соңгы елларда күп латышлар туган илләреннән читкә сөрелде, Латвияне урыслар һәм урыс теллеләр белән «сыеклату» сәясәте алып барылды.

Нәтиҗәдә латышлар үз республикаларында нибары 53 процентка калдылар.

Латышларны тоташ ассимиляцияләнүдән бары тик Аллаһы Тәгалә генә коткарып калды, дисәк тә ялгышмабыз. Әгәр дә бишьеллыкларның бер-икесендә Рига шәһәрен тоташ портка әверелдерү планы тормышка ашса, латышларның хәленә кызыгырлык булмас иде.

Латвиянең тагын урыслар кулына эләгү хәвефе хәзер дә юк түгел. Шуңа күрә, үзләрен милләт буларак саклап калу, мөстәкыйльлекләрен ныгыту өчен латышлар шактый кискен, катгый чаралар күрергә мәҗбүр. Һәрбер халыкның үзен саклап калу өчен тиешле чаралар күрергә хакы бар. Бу чараларны гамәлгә кертү процессында бүтән халыкларга уңайсызлык килүе бик мөмкин.

Кыскасы, без Равил Яһудинның үлеме уңаеннан туган коллизияләрне дөрес бәяләргә тиешбез.

Әлеге мәкаләләрдә «Латвия — латышлар өчен», «Эстония — эстоннар өчен» дигән шигарьләр яманлана. Әлбәттә, андый шигарьләр ямьсез, урынсыз, алар кискен хәрәкәтләргә этәрә. Ләкин, уйлап карагыз, телдән әйтелмәсә дә, Русия урыслар өчен түгелмени? Урысларның һәм урыс түгелләрнең мәнфәгатьләре кисешкән һәр очракта безләр урыска юл бирергә тиеш бит! Шулай булды һәм асылда шулай булып кала да. Һәр очракта диярлек, урысларга зыян килмәсен, башкаларга зыян килсә дә ярый... Урысларга уңайлы булсын, башкаларга уңайсызрак булса — була бирсен...

Татарстанда да бу кагыйдәдән чигенеш юк әле. Татарстанда татар халкының үзсаклану механизмын булдыру хәтта максат итеп тә куелмый.

Равил Яһудин белән баглы язмаларда еш кына безне кыеклатып кисәтәләр: үзсаклануны максат итә күрмәгез — әнә нинди әшәкелекләр килеп чыга, имеш.

Рәсми чыгышларда безнең җитәкчеләр корчек ташы итеп «халыклар дуслыгы», «халыкара мөнәсәбәтләрдә иминлекне» куялар. Ләкин ул иминлек «урысларга һәр җирдә уңайлык» принцибы белән үз мәнфәгатьләреңне корбан итеп килешү исәбенә төзелгән бит! Һәрбер иминлек вә тынычлык та үзен аклый дип әйтеп булмый. Тымызык күл кортлы була, диләр... «Дус булыйк» сүзенең безнең вазгыятьтәге төп мәгънәсе «урысларны ачуландырмыйк» булып кала икән, моны сокланырлык күренеш дип бәяләргә ярый микән? Күпмилләтлелекне мактау — ул урыслаштыру өчен уңайлы шартларны куәтләү түгелмени?

Бу хакта күп сөйләргә мөмкин. Миңа бигрәк тә «Мәдәни җомга»ның 5 нче санындагы «Әни, гафу ит, мин башкача яши алмыйм» дигән мәкаләгә (әлеге Р.Яһудинга бәйләнешле) редакциянең искәрмәсе ошады: «И, тәңрем, аерма шул татарыңны туган җирләреннән!».

Рифгать ӘХМӘТЬЯН.

Җаваһирә СӘЛӘХОВА:

«Иртән сөенәм, кичен көенәм ...»

— **Юбилеегызны нинди кәеф белән каршылыйсыз, Җаваһирә ханым?**

— Иртән сөенәм, кичен көенәм...

— **Кайчан җырлый башладыгыз?**

— Бакча яшеннән. Мәктәптә минсез концерт үткәнен хәтерләмим.

— **Ничек профессионал булып киттегез?**

— Музыка училищесының вокал бүлегендә, Мәрьям Рахманкулова классында укыдым. Училищены тәмамлар-тәмамламастан, бригада төзеп, безне гастрольгә чыгарып җибәрделәр. Бригадабызда — Гани Вәлиев, Рәшит Ваһапов һәм мин. Бөек Ватан сугышы бара...

— **Сезгә дә сугыш булган якларга барып чыгарга туры килгәндер инде...**

— Килмәгән кая! 1943 ел. Ун кешелек бригада. Татарлардан Гани Вәлиев тә мин. Брянски фронтына дип җибәргәннәр иде, ул Курски юнәлешенә әйләнде. Өч ай буе алгы сызыкта, атып торган җирдә, концерт куеп, җырлап йөрдек. Иң авыры — концерт барганда солдатларны ут эченә алып кереп китәләр иде. Анда күрмәгәннәр калмады. Тик мине сугышта катнашучы дип санамыйлар, шунысы рәнҗетә...

— **Кайсы композиторның җырларын аеруча яратып җырлый идегез?**

— Мин бит инде халык җырларын яратам. Лирик җырлар Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин, Сара апа җырлары.

— **Хәзерге музыкага, башкаручыларга мөнәсәбәтегез ничек?**

— Хәзерге җырчыларның фонограммага җырлаганын белгәч исләрем-акылларым китте. Беренчедән, бу — бик җиңел кәсеп, икенчедән, алар бит булган тавышларын да бетерәләр җырламыйча. Ә музыкага килгәндә...

— **Иң нык исегездә калган очрашу кайда булды?**

— Кореяда. Җәүдәт Фәйзи җитәкчебез иде. Илчелектә безнең хөрмәткә кунаклар кабул иттеләр: корееләр, Ким Ир Сен үзе, безнекеләр, башка кунаклар. Милли

киемнәрдән Илчелектә безне озатып йөрүче бар. Мин шунда авырып киттем. Ә үзем җырларга тиеш. Авырсам да, барыбер җырлаттылар. Бик күп җырладым. Чыккач, хәлдән таеп кешe кулына аудым. Шуннан илчелегебез вәкиле килеп миңа:

— Знаете, что Вы заработали?! — диде.

Минем яңадан хәлем китте. Нишләдем икән, бернинди ярамаган җыр җырламадым, бернинди ярамаган сүз сөйләмәдем бит югыйсә дип уйлыйм. Цензура ул чакта шундый көчле, алардан үткәрмичә бернинди җыр җырлап булмый.

Ниһаять

— Ким Ир Сен тагын сорый сезнең җырлавыгызны — диделәр.

Өстемнән тау төшкәндәй булды...

— **Бенефисыгыз кайчан була?**

— Декабрь урталарында.

— **Химаячегез кем?**

— Улым.

— **Үз гомерегездә үкенечкә калган эшегез булдымы?**

— Консерватория ачылу белән Нәҗип Җиһанов укырга чакырды. Ирем Гани Вәлиев миңа үзе эшләп ашый торган хатын кирәк, диде. Ә безнең ул чакта инде балабыз да бар иде. Шуңа күрә укый алмадым. Шул үкенечкә калды. Ә минем хыялым опера җырчысы булу иде. Театрга опера тыңларга барсам, җылап кайта идем...

Әңгәмәне
Саимә ИБРАҺИМОВА
оештырды.

Насыйп ярлар кайта көзләрен

Кая китә бу татар, дибез. Беркая да китми, без үзебезне үзебез бетерәбез. Әйтик, өебездә теле ачылып кына килә башлаган балабыз белән, үзебез рәтләп белмәсәк тә, урысча сөйләшкән булабыз. Шулай үзебезне «образауный»рак итеп күрсәтергә азапланабыз.

Урыс телен белмәгән кеше югары уку йортларына керә, ындыр артыннан ерак китә алмый, дигән фикер белән дә килешеп килми. Тирә-безгә күз салыйк: әле дә булса урыс телен камил белмәүче күпме югары җитәкчеләр, галимнәр бар! Укыганнар, кеше булганнар, урыс телен яхшы белмәүләре һич кенә дә юлларына киртә куймаган.

... Казанның Маяковский урамындагы сәт кибетендә бер ханым болай дип мактана. «...Татар ул мәңге монгол булып калачак. Үземнең әтием татар булса да, мин аларны хөрмәт итмим. Чөнки аның әти-әнисе минем әниемне санлап яшәмәгән, «марҗа» дип кенә йөрткәннәр. Ә әнием ягында әтигә «син татар» дип ник бер сүз әйтсеннәр. Аны гел «сынок» дип кенә йөрттеләр...» Ә мин түземәдем, аларның сүзенә кысылып: «Әгәр синең әниең килен булып төшкән көннән аларга татарчалап «әти, әни» дип дәшсә, алар телендә сөйләшергә өйрәнгән булса — аңа да «кызым» дип кенә йөргән булырлар иде. Әтиең дә үз телендә сөйләшүне хуп күрсә, сезне татарча өйрәтергә тырышса, бәлки әтиеңә дә караш икенче булыр иде. Минемчә, әтиегез сезнең гаиләдә кол гына булган, үз телендә бер сүз әйтергә коты очып яшәгән. Әгәр шулай булмаса, сез әтиегезгә дошман итеп карамас идегез...» — дидем.

Әйе, безнең татар егетләренең кайберләре урыс кызларына өйләнеп, үз телләрен, үз диннәрен, хәтта ата-аналарын оныттылар. Дөрес аңлагыз, мин монда һич кенә дә урыс яки башка милләт халкын гаепләргә җыенмыйм. Сүз фәкать бик күп татар егетләренең милли горурлыкларын югалтулары хакында гына бара. Шәһәрнекеләрне әйтмим дә инде, авыл егетләренә исең китәрлек. Армиягә киткәндә кавышырга вәгъдәләшкән күпме егет урыс кызына өйләнеп кайта... Һәм хатынына ияреп яшәргә читкә китә. Гайбәт итеп түгел, гыйбрәт итеп Мәскәүдәге бер гаилә тормышын искә төшерәм. Ир — мөселман, хатыны — христиан диненнән. Яшь чакларында менә дигән яшәделәр, ә менә балалары үсеп таралгач, икесе ике тормышка күчтә. Берсе мәчеткә, икенчесе чиркәүгә йөри. Хәзер аларның яшәү рәвеше фатирдашларныкы кебек кенә. Берсе пешергән ризыкны икенчесе ашамый, һәркемнәрсә аерым, түбә генә уртак. Ә балаларында?.. Аларга әниләре ягы гына кардәш. Әти ягын белмиләр дә.

Әлбәттә, ирен бик яраткан хатыннар да бар. Алар ирләрен читкә сөйрәп алып чыгып китмиләр. Аның әти-әнисен, туганнарын хөрмәт итеп, телен өйрәнеп, хәтта динен алыштырып яшиләр. Безнең Ямурза авылында (Әгерҗе районы) Нәҗметдин абый шулай армиядән өйләнеп кайтты. Хатыны Надежда татар түгел иде. Әмма ул менә диган итеп татарча сөйләшергә өйрәнде. Гомере буе Нәҗметдин абыйның төп нигезендә (ирә үлгәч тә) арбаның иң авырына җигелеп тартты. Хәзер инде ул пенсиядә, чын татар рухында тәрбияләп үстергән ул-кызларының тормышына куанып, әле дә булса хәленнән килгәнчә аларга ярдәм итеп яши. Аны безнең авыл халкы беркайчан да чит итмәде. Киресенчә үзенең тырышлыгы, кешелеклелеге белән ул һәркемнең ихтирамын яулады.

Әлбәттә, андыйлар бар, әмма алар йөзгә-меңгә бер генә шул.

Миңа калса, аңлы мәгърифәтле татар кызы башка милләт егетенә кияүгә чыга икән (очрый бит ул тормышта андый олы мәхәббәтләр), бу әле милләтнең кимүе өчен алай ук куркыныч түгел. Өйдә төп тәрбияче барыбер әни кеше. Бүгенге заманда ул балаларын үз рухында тәрбияли ала. Ә урыс хатыны белән гомер иткән әтиләрнең меңнән берсе генә аны булдыра ала. Безнең татар ирләренең тыйнаклыгы башка халыкны хөрмәт итүемә бу әлләә мөнсезлеге курккакыгымы? Баланы үз рухында, үз телендә тәрбияләргә хәленнән килмәгәч ник өйләнергә?.. Ә бит олы саф мәхәббәт белән аларны кәтеп, милләтебезнең күпме кызлары ялгыз калды.

Дөньяны әхлак тота

Бүген без тагын бер хакыйкатьнең шаһитыбыз: дин нигезләреннән башка без балаларыбызда әдәп, намус кебек әхлакый сыйфатларны тәрбияли алмыйбыз икән. Моңа хәзер җәмгыятьчелек инанды. Телен белмәүче мөселман кешесе үзе дә, аның баласы да диннән ерак яши. Ул хәтта, күңеленнән булса да, «бисмилла» дип тә әйтә алмый. Ә бит, халкыбызда шундый әйтем бар: «Телсез кеше — динсез кеше, динсез кеше — денсез кеше, аннан иман-шәфкать көтмә». Димәк, тел белмәгән мөселман кардәшләребез иманга килә алмый гомер кичерәчәк, йә булмаса, чиркәүгә йөри башлаячак. Чөнки әле мәчет-чиркәүләргә халык ничектер куркыбрак, кыенсынып йөри (70 ел буе биздерүгә карамастан йөрүчеләр бар бит!), киләчәктә исә дин тотмаучыларга кеше арасында читен булачак...

Ходай язган язмышлардан узмышлар юк шул! Кайчандыр өйләнеп читкә киткән күпме ирләр кайта хәзер Казанга, Татарстанга. Яшьлек узган, сөешүләр гузган — хатыннары ияреп кайтмый шул андыйларның берсенең дә. Аллага шөкер, безнең Татарстанда кеше хокукларының милләтенә карап чикләнгәне юк әле. Димәк, яратулары да шулай гына булган...

Ә менә безнең гомер көзләренә чаклы сабыр гына үз тиңен, үз ярын көтеп яшәгән инсафлы кызларыбыз бүген аларның хәлен аңлап ярдәмгә киләләр. Бик олы мәхәббәтләр өмет итмиләр билгеле, шулай да яшьнәп яшәгән яшьлекләрендә бәхетле парларга соклап, хыялында йөрткән ярларыдай аларга ишекләрен ачалар. Узара ярәгышып матур гына яшәп китүчеләр шактый. Арада килешә алмаучылар да бар билгеле. Нишлисең, яшьлектәгедәй мәхәббәтләр узган шул инде. Житмәсә эчеп акылыннан ычкына торган гадәте дә булса, ул ирне җәлләп кенә яшәп булмый. бала хакына да түзәсе юк. Хәер андыйлар гуктап калмый «ярын» эзләп тагын китә. Чөнки күбесенең яшәр-торыр урыны юк. Менә яшә син читтәге бәхеткә ышанып. Яшьлегеңдә үз илеңдә үз тиңеңә (бусы башка халыкларга да карый) өйләнеп нигез корырга ни җитә!

Язилә АБДУЛКАДЫЙРОВА.
Казан

Тыңлагыз, Казан радиосы сөйли!

Моннан ике ел чамасы элек мәркәзебез Казан каласының үз радиосы кы иде әле Хәзер Аллага шөкер. безнең мондый радиобыз бар Дәрес иң еүвәпе аның тапшырулары урыс телендә алып барылды Узган елның 4 сентябреннән һәр атнаның дүшәмбе сишәмбе һәм пәнҗешәмбе көннәрендә кичке 17 сәгать 5 минутта татарча тапшырулар да яңгырый башлады Гаҗәп. Казан радиосын Татарстан радиосы белән дә буташтыргалыйлар һәм моны аңларга да мөмкин. Ник дигәндә. аның тапшыруларын профессиональ яктан өлгергән һәм тәҗрибәле журналистлар оештыра. Әйтик. урыс тапшырулары редакциясен Татарстан радиосында эшләп. зур тәҗрибә туплаган Айдар Сәгыйтов җитәкли Дикторлар Ирина Курнева һәм Елена Крайнова да үзләренең сөйләм телләрен һәрдаим камилләштерү белән шөгыльләнәләр.

● Казан шәһәре радиотрансляция челтәре начальнигы Альберт Минһажев.

● Кабель цехы начальнигы Борис Горшинин.

Ә инде татар тапшырулары редакциясенә килсәк, анда да «азаулы» журналистлар эшли. Мөхәррир Заһид Мөхмүди. мәсәлән. Татарстан радиосының балалар тапшырулары редакциясендә эшләп, нарасыйлар күңеленә, «Фантастлар радиоклубы», «Тылсымлы каләм», «Көмеш кыңгырау» дигән матур-матур тапшырулары белән кереп калган кеше. Диктор Эльс Гадел исә һәркемгә яхшы мәгълүмдер. Аның белән бер микрофон артында тапшыруларны алып баручы Наҗия Сибат та инде каләмен шактый чарлаган журналист. Ул әле дә булса «Татар иле» гәзитендә эшли. шул ук вакытта тапшыруларны оештырырга да ярдәм итә.

Берәүләр. Татарстан радиосы булгач, Казан радиосы нигә кирәк икән, диярләр. Тыңлаучылар шуны аңласыннар иде. Казан радиосының максаты башлыча шәһәр тормышын яктыртудан, казанлылар мәнфәгатен яклаудан гыйбарәт.

Ниһаять, мәркәзебез
Казан каласының татар
тапшырулары редакциясенә дә
бер яшь туды. Анда эшләүче
барча хезмәткәрләргә дә иҗади
уңышлар телән калам.
Казан радиосының гомере озын
булыр, дип ышанасы килә.

/Альберт Минһаж/

● Казан радиосы хәбәрчесе Елена Крайнова.

Тыңлагыз, сөенегез, Казан каласының үз радиосы бар! Аны сез челтәрле радио аша беренче программа буенча тыңлый аласыз.

Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА.


● Режиссер Ринат Басыйр.


● Тавыш операторы Сергей Арискин.

МОСАФИР СӘФӘРДӘН КАЙТТЫ

Безнең моңга болгарлар да гашыйк

Республикабызның юбилей көннәре алдыннан Зәй шәһәренең «Октябрь» мәдәният сарае һәм Балтач мәдәният йорты үзешчәннәре Болгариягә — Бургас шәһәрендә узган халыкара фольклор фестивален барды Бу фестиваль инде 30 ел буе уздырыла килсә дә, Татарстан Республикасы Кипр, Греция, Болгария, Словакия, Украина, Грузия. Румыния белән тигез дәрәҗәдә халыкара фестивальгә үз фольклор коллективлары иҗатын беренче тапкыр тәкъдим итте. Дүрт көн буе шәһәрнең чәчәкле ачык мәйданнарында, меңләгән тамашачылар алдында концертлар барды Татарстан үзешчәннәре тамашачыларга «Кичкә уеннар» (Русия һәм Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Котдүсә Хөсәенова тарафыннан куелган) программасын күрсәтте.

Фестиваль Бургас шәһәренең үзәк урамында фольклор ансамбльләренең парады белән ачылып китте һәр ил делегациясе өстендә дәүләт флагы җилферди Шулар арасында яшел, кызыл, ак төстәге Татарстан флагының да җилфердәве күңелләрдә олы горурлык тойгысы уятты һәр фольклор ансамбле аерым-аерым үз программасын күрсәтте. Безнең делегация татар халкының җырлы биюләрен алып килгән иде. Ул биюләргә йөзләгән тамашачылар кушылып китте. Халыкара фестиваль Кара диңгез ярындагы җәйге театрда ачылды Нинди генә телләрдә сөйләшмиләр иде монда! Оештыру комитеты рәисе профессор Живков фестиваль флагын күтәргәч, сәхнәгә фольклор ансамбльләре чыкты. Безнекеләр Грузия, Румыния һәм Болгария белән бер төркемдә чыгыш ясады. Милли киемнәр кигән Татарстан үзешчәннәре биек баскычлардан курай һәм гармуннар уйнап сәхнәгә — тамашачы каршына төште һәм «Кичкә уеннар»ны башлап җибәрде. Зал хәйран калды, аягүрә басып, безне алкышларга тотынды. Тамаша ахырында бер артистыбыз сәхнәдән тамашачылар арасына төшеп, татар биюенә катнашырга чакырды. Андый кыю тамашачы да табылды, ул сәхнәгә менеп биеп алгач, аңа ансамбль исеменнән чиккән түбәтәй бүләк иттеләр Тамашачы аһ итте, янә алкышлаулар башланды, «Афәрин!» дигән сүзләр ишетелде.

Татарстан үзешчәннәре Бургасның Диңгез паркында да концерт куйды. Фестивальгә йомгак ясаган гала-концертта да безнең фольклор осталары уңышлы чыгыш ясады.

Концерт программаларын Болгария телевидениесеннән даими күрсәтеп бардылар һәм, шулай итеп, татар фольклор сәнгате белән бөтен Болгария халкы танышты, дисәк тә була.

Әлбәттә, Болгариядә без музейларда булырга да вакыт таптык. Төбәкне өйрәнү музеенда әлегә фольклор фестивальләренең тарихын яктырткан стендлар да бар иде. Димәк, Татарстан фольклорчыларының да иҗаты бу музейда мәгълүм дәрәҗәдә урын алачак, дип ышанып әйтергә мөмкин. Шәһәр хакимнәре белән очрашу вакытында без шәһәр музеена Татарстан турындагы китаплар, альбомнар бүләк иттек, алар да безгә истәлекле бүләкләр тапшырды. Болгариядән без диплом һәм истәлекле фестиваль медале алып кайттык.

Без Татарстан йөзенә кызыллык китермәдек, һәм бу күңелле сәфәрне оештырган кешеләргә ихлас рәхмәтебезне ирештерәбез!

Гали ГАБДРАХМАНОВ,
Татарстанның халык иҗаты үзәге директоры.

Атналык манзара TV

Дүшәмбе

2 октябрь

«Татарстан»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.35 Мультфильм. 18.45 Балалар өчен «Тамчы». 19.00 «Татарстан». 19.30 Хоккей. МХЛ кубогы. «СКА» — «Ак барс» (Казан). 2 нче һәм 3 нче периодлар. («Петербург» телевидениесе трансляциясе). 20.45 «Әлли-бәлли-бәү». 20.50 «Түгәрәк өстәл». Реформалар программасы: ул нинди булырга тиеш? 21.30 Хөснул Вәлиуллин җырлары. 21.55 Тапшырулар программасы.

«Эфир»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Волшебник Изумрудного города». 10 нчы серия. 7.30 «КиноМеню». 8.00 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 8.15, 11.00 — «Юл патруле». Атналык йомгак. 8.30, 14.45 «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан!» (MTV). 9.20, 13.00 «90х60х90». 9.40 Диск-канал. 10.00 «Канун» (православие чиркәве цигезләре турында әңгәмә). 10.30 Рей Бредбери. «Конвектор Тойнби». 11.15 Атна фаразлары. 11.45 «Валюта бәясе». 11.50 Балалар өчен сериал: «Неоновый всадник». 12.40 Кино музыкасы: «Марина Ладынина». 13.15 Нәфис фильм: «Джентльмены удачи». 15.00 Телесериал: «Флиппер». 16.00 «Фитиль» 16.15 Ток-шоу. «Минем кино»: Галина Волчек. 16.55. 18.20 А.Габриловичның документаль фильмы: «Дворы нашего детства». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 17.45 Ток-шоу: «Минем тарих». 19.25 «Эфирда — музыка». 19.30 «Видеомода». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 23.35 «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Лариса» яңалыклары. 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Нәфис фильм: «Страшная месть Брюса Ли» (Гонконг). 23.05 «Криминаль хроника тележурналы». 0.00 Триллер: «Чужой кровью».

1 нче канал

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 18.00 «Яңалыклар». 9.10 «Есенин көннәре». «Тальянка». Т.Доронина башкара. 9.15 Телесериал: «Тропиканка» 10.05 «Могҗизалар кыры». 10.55 «Кеше һәм закон» 11.20 Мультфильм 11.30 Телеуен: «Көен таны». 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 Сериал: «Шерлок Холмс и доктор Ватсон»: «Знакомство». 1 нче серия 14.05 «Кумирлар, кумирлар...» 14.53 «Есенин көннәре». 15.15 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь» 15.45 «Марафон-15». 16.00 «Йолдызлар сәгате». 16.35 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.30 «Джем». 17.30 «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.50 Фантастик детектив: «Багз» (Бөекбритания). 1 нче серия 22.50 Документаль фильм Сергей Есенин. 23.30 «Твин Пикс» сериалында Лора Палмерны үтерү сере.

«Русия»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 «Хәбәрләр». 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 Нәфис фильм: «Гоголь-моголь». 10.30 «Төп мизгел». 10.40 Илче янында иртәнге аш. 10.55 «1995 ел укытучысы» конкурсы 11.20 Милиция хроникасы. 11.30 «Телегазета». 11.35 Мульти-пульти. 12.05 Мини-футбол Русия кубогы финалы. 12.15, 17.20 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «РОСТ» компасы. 17.50 «Алыргамы-алмаскамы». 18.00 Сергей Есенин турында миф. 18.25, 22.50 «Клип-антракт». 18.30 «Коткару-911». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 «Дүшәмбе саен детектив». «Инспектор Морс» сериалыннан нәфис фильм: «Адская змея» (Бөекбритания). 21.40 Репортер. 22.00 «Хакыйкать мизгеле». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Нәфис фильм: «Берлин. Александр Платц».

«Санкт-Петербург»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 9.40 «Күңел». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.40 «ТВ мәгълүматлары». 13.10 «Яшәү стиле». 13.25 «Музыка мизгеле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Мультфильм: «Доктор Айболит». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.40 Безнең кино. «Даталарсыз хатирәләр». 17.15 ТВ мәгълүматлары. Европа калейдоскобы. 17.45 «Буй-буй кит». 21.35 «Иминлек телехезмәте». 21.45 «Шәһәр эшләре». 22.00 «Рязань-95» телевизион программалар фестивале. 22.25 «Кумарейки» фольклор программасы. 23.00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Музыкаль шоу: «Телекомпакт». 0.15 Нәфис телефильм: «Валентина» (Италия).

Сишәмбе

3 октябрь

«Татарстан»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 17.30 Баскетбол буенча Русия чемпионаты. Югары лига. «УНИКС» (Казан) — «Арсенал» (Тула). 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.35 Измирдагы (Төркия) халыкара ярминкәдә. 20.05 «Әлли-бәлли-бәү». 20.15 «Тукталыш». 20.30 Күп сериялe нәфис фильм премьерасы: «Тарзан». 16 нчы һәм 17 нче серияләр (Мексика — Канада — Франция). 21.15 Усман Әлмиевнең иҗат кичәсе. 22.20 Тапшырулар программасы.

«Эфир»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 Мультфильм: «Жил-был Савушкин». 1 нче серия. 7.30, 20.20, 0.45 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (2 октябрь тапшыруын кабатлау). 8.15, 11.00 «Юл патруле». 8.30 «Даруханә». 8.40 Диск-канал: «Сул аяктан!». 9.20, 13.00 «90х60х90». 9.45 «Минем кино»: Галина Волчек. 10.30 Юмористик сериал: «Один к десяти». 1 нче серия. 11.10 «Атна һәлакәтләре». 11.40 «Валюта бәясе». 11.45 Нәфис фильм: «Добро пожаловать, или Посторонним вход воспрещен» 13.20 Нәфис фильм: «Командир счастливой «Щуки». 15.00 «Тегеләр, кемнәр...»: «Святослав Федоров». 1 нче көн. 15.25 «Музыка һәм матбугат». «Каләм осталары» МСМ телеканалы. Фрасуа Телье. 16.15 И.Смоктуновский Горький исемендәге Мәскәү сәнгать академия театры куйган «Иванов» спектаклендә. 18.55 Сериал: «Против течения». 5 нче серия. 19.45, 21.05 «Эфирда — музыка». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Коммерция әйләнмәсе». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Туры эфирда уен: «Кичке яңгыраш». 22.15 Документаль фильм: «Личное дело Анны Ахматовой». 23.20 Русия киносы көне. Нәфис фильм: «Алиса и Букинист».

1 нче канал

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 18.00 «Яңалыклар». 9.10, 14.55 Есенин көннәре. 9.15 Телесериал: «Тропиканка». 10.05 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 10.45 «Ак попугай» клубы. 11.30 Телеуен: «Көен таны». 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 Сериал: «Шерлок Холмс и доктор Ватсон». 14.00 Сериал: «Ставка больше, чем жизнь». 15.15 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь». 15.45 «Күңелле квампания» кварьетесы. 15.55 «Мультитроллия». 16.10 «Тылсымлы дөнья, яки Синема». 16.35 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.00 «16 яшькәчә һәм өлкәнрәкләр өчен». 17.30, 1.30 «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.50 «Тарихи мелодрама». «Яр». С.Есенин повесте буенча. 23.30 «Мәскәү-Кремль». 23.50 Эстрада программасы: «Төсләр карнавалы». 0.45 Сериал: «Твин Пикс» 2.00 Телесериал: «Ставка больше, чем жизнь».

«Русия»

